
1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ИЮНЬ № 6

СӨЮМБИКӘ

«АК ЧӘЧӘКЛӘР»
кадрга сыймаганнар

ЧЫГАРСЫҢМЫ КАРШЫ АЛЫРГА?
моңлы язмыш

ФИЛҮС КАҺИРОВ СЫЙЛЫЙ
баскча пешерелгән тавык

Дамира БАЯЗИТОВА:

«АШЫГЫЧ ЯРДӘМ ФЕЛЬДШЕРДАН БАШЛАНА»





70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

Мәрьям РӘФИКОВА фронтка 1942 елның март башында, Чистай фельдшерлар мәктәбен тәмамлагач, унсигезе дә тулмаган килеш китә. Төньяк-көнбатыш фронтта сугышкан 27 нче артиллерия дивизиясе белән Калинин, Новгород, Ленинград, Псков өлкәләрендә, Балтыйк буенда данлы сугыш юлы үткән. Сугышчыларны ут эченнән алып чыкканы, үлемнән коткарганы өчен Мәрьямгә командование берничә мәртәбә рәхмәт белдерә. Аның турында дивизия газетасына язалар, «Кызыл Йолдыз» ордены, медальләр белән бүләклиләр. Бәрелешләр тынып торган чакларда Мәрьям концертларда катнаша, татар, украин, лезгин биюләрен башкара, «Иркәм», «Сагыну» көйләрен җырлый... Сугыштан соң Мәрьям Рәфикова-Әнлиуллина Алабуга шәһәрендә яши, 12 нче балалар бакчасында фельдшер булып эшли. Дүрт бала үстерә.

С фронта всем родным и знакомым

В день 24 годовщины Красной Армии шлю Вам свой боев...

«Әти һәм әни! Сезгә сагынып сәлам язып, сезгә озын гомерләр теләп калам. Әти 25/Хдә язган хатыгызны алдым. Посылка салган икәнсез бик рәхмәт инде сезгә. Мин акча салдым 200 сум. Декабрь аенда алсагыз, языгыз. Ипи хаклары ничек тора, әти? Тананы күпмегә сатырга уйлыйсың? Әгәр сатмаган булсаң яз, мин тагын акча җыеп салырмын. Мин исән әлегә, бездә каты сугышлар бара әле, пехота бик аз алга бара, авыр. Тора-бара ничек булыр. Абыйлардан хат аласызмы, исәннәрме алар? Сезнең исәнлек ничек? Әнинең исәнлеге? Хат көтәм. 23/ XII-42».

«Апа! Сиңа сагынып сәлам язам, исән яшәвеңне теләп калам. Апа, сиңа госпитальдән хат салырга биргән идем, алгансыңдыр инде. Мин .... киткәч авырып яттым. ...... Мин тегендә 25 тә эшләдем, инде хәзер лыжный полкта, күчермәсәләр. ...... күрмәгәнем калмады дисәм дә ярый.»

«Әти һәм әни! Сезнең барыгызга сагынып сәлам язып калам. Бүген Әминә ападан хат алдым. Апаем мине ачуланыбрак язган иде. Имеш, мин сиңа үпкәләгән, әти, мин сезгә хат салмыйм. Кажется, көн саен хат салам, тик моннан 20 көн элек бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәнгә күрә язарга туры килмәде. Мин сезне онытырга теләгәнем юк. Рәхмәт, сез мине үстердегез, тәрбияләдегез, хәзер сезнең 19 яшьлек кызыгыз сугышта курыкмыйча көрәшеп ята.»

«Әти һәм әни! 3 нче хат язам, алдыгызмы, юкмы? Үзем Иваново өлкәсендәге полкта эшлим. Әмма без тиздән китәбез. Мин сездән озак вакытлар хат ала алмам инде. Тик шуны языгыз телеграмма белән: акча аласызмы әле, юкмы? Фронт хәлләре сезгә билгеле инде. Северо-западный фронтта күптән түгел наступление булды безнең. Берничә авылны алдылар. Немецлар 16 мәртәбә контратакага килделәр. Ләкин у нас укрепления хорошо было. Көн саен .... атып маташа. Но зыяны зур түгел. Безнең артиллерия көчле. Башка сүз юк.

Ашау яхшы. Сез ничек торасыз? Печән җыеп беттеме? Яңа бәрәңге өлгермәдеме әле? Ашауга аптырамыйсызмы? Сыерның сөте бармы? Задание тулдымы? Ничә бәрән суйдыгыз? Итегез бармы? Барын да языгыз. Киемсалым яклары ничек? Сәлам белән Мәрьям. 15/VII.»

Хатлар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы фондында саклана, аларны 1983 елда Э. РӘФИКОВ тапшырган. Музей фондында Бөек Ватан сугышы темасына караган ике меңнән артык документ бар.



Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте





Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Дамира Баязитова
Фото: Алинә Батыргәрәева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академия урамы, 2

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 8.06.2015 ел.
Заказ О-1619.
Тираж 7349

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сатуда бәясе ирекле.


Балалар – теләсә кайсы җәмгыятьнең нигезе һәм киләчәге. Шуңа да балалар турында кайгырту җәмгыятьнең иң мөһим бурычларыннан берсе санала. Аеруча ата-ана каравыннан мәхрүм калганнарны. Дөньяның төрле илләрендә ятимлек ни хәлдә һәм бу мәсьәләнең ни өчен шулкадәр әһәмиятле икәнен ачыкларга булдык.



«АРТЫК БАЛАЛАР» КАЙДА АРТЫГРАК?

Ятимнәрне гаиләле итәргә әзер булу – җәмгыятьнең иң ачык социаль активлык күрсәткече. Үз йортларын, кочакларын, йөрәкләрен әти-әни җылысыннан мәхрүм балаларга ачучы гаиләләр бездә дә күп булуга карамастан, илебезгә беренче урынга ерак шул әле. Монда хикмәт – дәүләт сәясәтендә түгел, ә безнең күңел киңлегендә. Һәркайсыбыз бу саннарга йогынты ясый ала. Волонтерлык хәрәкәтендә никадәр кеше шушы изге эш белән мәшгуль, алар сездән дә ярдәм көтә. Чит балалар булмый, шуны истән чыгармагыз!

Ятим балаларның саны (100 000 халык санына, 2014 ел)



Уллыкка (кызлыкка) чират торучы балалар саны (ятимнәрнең гомуми санына мөнәсәбәтле рәвештә, 2014 ел)



Ятим балага яңа гаилә табуга төрле факторлар тәэсир итә. Гадәттә, төп проблема – юридик сораулар. Һиндстанда аларны чишү өчен социаль хезмәт күрсәтү җитми, ә менә Германиядә, киресенчә, яңа әти-әниләр эзләүгә бик җитди карыйлар, бу чиратка куелучы балалар санында да чагыла (һәр яклап тикшермичә, баланы башкаларга уллыкка тәкъдим итәргә ашыкмыйлар, ә менә чиратка куелганнан соң ятимнәрне гаиләләргә бик тиз алып бетерәләр). Безнең халык исә ятимне, бигрәк тә авыруны аякка бастыру хәлдән килмәс дип уйлый.

Уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны (уллыкка алынырга чират торучы балаларның гомуми санына мөнәсәбәтле рәвештә, 2014 ел)



Татарстанда ятим бала алган гаиләләргә зур ташламалар һәм матди ярдәм каралган. Әйтик, мәктәпкәчә яшьтәге балага ай саен хөкүмәт тарафыннан 7 116 сум, мәктәп яшендәгесенә 8 208 сум күчерелә. Дарулар өчен һәр балага 241 сум акча бирелә. Моннан тыш, ятим бала тәрбияләүче әниләргә (опекага алу очрагы булмаганда) ай саен 3 000 сум акча биреп барыла. Әлбәттә, бала үстерү кыйммәткәрәк төшә. Әмма мәрхәмәтнең әҗере, савабы акча белән үлчәнми бит.

Биш ел чамасы элек балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чын-чынлап ыгы-зыгы купты. Дөньякүләм йолдызлар кырылып уллыкка (кызлыкка) бала ала башлады – төп сәбәпләрнең берсе шул. Мондый «йолдызлы» үрнәк кайбер илләрдә балалар алуны 25% ка арттырды.



Һиндстан кебек социаль яктан артта калган илдә Америкага караганда ике генә тапкырга күбрәк ятимнәр яши. Бу аңлашыла – Һиндстанда, ярлы булсаң да, бала калдыру гадәте юк. Шуңа охшаш сәбәп Кытайны да түбән күрсәткечле итә. Анда балаларны ерак туганнарга булса да уллыкка (кызлыкка) бирү ягын карыйлар.

2000 елда Татарстанда 16900 ятим исәпләнгән, 2014 елда аларның гомуми саны 12 000 калган. Бүгенге көндә республиканың опека һәм попечительлек органнарында 11 960 бала исәптә тора. Шуларның 11 192 се гаиләләрдә яши.



Антон Семенович Макаренконың хезмәт лагерьларында тәрбиягә иң авыр бирелә торганнар да социальләшә торган булган. Кызганыч, хәзерге балалар йортларына ерак әле ул күрсәткечләргә җитәргә! Биредә тәрбияләнүчеләрнең тормышка яраклаша алганнары 20% тан да күп түгел. Гаилә җылысын бернәрсә дә алыштыра алмауның ачык дәлиле бу.





2012 елда № 272-ФЗ законы яки, икенче төрле, «Дима Яковлев законы» кабул ителә. Әлеге закон АКШ гражданнарына Россия балаларын уллыкка (кызлыкка) алуны тыя. Закон проекты ике яшьлек Россия малае истәлегенә шулай атала. Диманы уллыкка алган Америка гаиләсе эссе көнне аны ябык машинада онытып калдыра, баланың үлеменә шул сәбәпче була. Әмма суд әти-әнине аклый. Закон җәмгыятьтә көчле шау-шу, аерым очраклар гына баланы өметтән мәхрүм итәргә сәбәп була алмый дигән бәхәсләр кузгата. Шушы катгый законнан соң, чит ил кешеләренең Россиядән уллыкка (кызлыкка) бала алулары ике тапкырга кими.

Каюм НАСЫЙРИ

И газиз бала! Белеп тор...

Әй угыл, әйткән сүз аткан ук кебекдер. Һәрбер сүзне уйлап сөйләшергә кирәк, авызыңнан чыккан кире кайтмас. Гөнаһлы була торып та, тәүбәгә ашыкмаган кеше – гөнаһсын кечкенә булмаса да зурга әйләндерер.

* * *

...Әй угыл, кешегә мәнфәгать итәргә кулыңнан килмәй икән, бары зарарыңны ирешдермә. Ачык йөзле, татлы сүзле бул, дустың күп булыр.

* * *

Һәр эшнең ахырын фикер кыйлып вә уйлап эш кыйлган кеше бәла вә кайгыдан имин булыр вә сәламәт калыр. Уйламаенча, ашыгып эш кыйлган кеше һичбер... үкенеч тартмай калмас.

* * *

Һәрбер сереңне дустыңа әйтмә, чөнки кайдан беләсең, бервакыт дошман булып китәр. Дошманыңа, кулыңнан килсә, зарар итмә, бәлки, бервакытны үзеңә дус булыр. Дустыңның дустына да ышаныч юк, аң бул. Әмма ике дошман арасында сүз сөйләсәң, белеп сөйлә: әгәр дуслансалар, үзеңә оят килмәсен.

* * *

Һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма. Адәмнең җанына тия торган сүз әйтмә. Каты сүзле булма. Яхшы вә йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китә.

* * *

Әй угыл, гәрчә тугры сөйләмәк ачыдыр, әмма тугры сөйлә. Әгәр дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә, дошманыңа барып әйтмәсен.
Олугларны олуг ит, кечеләргә шәфкатьле бул. Бер эшне ике мәртәбә эшләмә.

* * *

Әй угыл, угырланган нәрсәне алмактан бик саклана күр. Кирәк үзең угырла, кирәк белә торып угырланган нәрсәне ал – икесе бәрабәрдер. Очраклы рәвештә угырланган нәрсә кулыңа керсә, иясенә тапшыра күр.

* * *

Бер хәким балаларга шуйлә нәсыйхәт бирде ки: «Әй җаннарым, угланнарым, нәсыйхәтне ишетегез – һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас. Алтын-көмеш – сәфәр кешесенә хәтәрдер; вә йорт-җир кешесенә дәхи хәтәре бар: йә угры алып китәр, яки утка янып китәр. Әмма һөнәр – бер агым судыр вә ышанычлы дәүләтдер.

* * *

И газиз бала! Белеп тор, адәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лязем нәрсә – гыйлемдер. Вә гыйлем дигәнемез – белмәгән нәрсәне үгрәнеп вә сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнемез – белмәклеге тиешле булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер вә хайван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр.

* * *

Кешедән көтәргә нәрсә алып, бурычлы булма. Кешегә бурычлы булдың – аның колы булдың. Ахмак вә наданнар эшенә катышма, чөнки алар үзеңне кимсетерләр. Вә алар белән бәхәс кыйлышма, сүз көрәштермә...

* * *

Халыкка икмәк-тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Тереклек белән сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар.

* * *

Берәүгә бер яхшылыгың тисә – сөйләп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң – фаш кыйл, онытма.

* * *

...Кеше... үзеннән-үзе белмидер, белсә дә, остазсыз өйрәнгән һөнәр ул кадәр файдалы булмыйдыр. Һәрбер гыйлемгә бер остаз кирәк. Гыйлем һөнәре, уку һөнәре кебек, һәр һөнәрне бер камил остаздан өйрәнмәк лаектыр... Һөнәр иясе бай булмыйдыр, әмма бай булмаса да, мохтаҗ булмыйдыр. Һөнәрсезлек – начар эштер.



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







18

ДАМИРА БИТ УЛ!
М. Кашапова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ 


8

ЯРАТТЫРА АЛСАҢ ГЫНА...
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ 

22

БЕРГӘЛЕК!
А. Юнысова



12

ЙОЛДЫЗЛАР КАБЫНГАНДА



26

ЧИГҮЛЕ ЮЛ
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



38

ГӨЛЧӘЧӘК
Ф. Садриев


ЯШӘЕШ 



48

ОНЫТМА, КЕШЕЛЕК!
Ф. Бәширова

54



ХАШИМИД ПАТШАЛЫГЫ
Р. Кашапова

ШУЛАЙ УК: 

16 ГҮЗӘЛ АЙТИШНИКЛАР
Ф. Мостафина

28 АК ГӨЛЛӘРДӘ – ҖАН ҖЫЛЫСЫ...
Э. Закирова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58

ЧӘЧӘКЛЕ БЕРЕТ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КЫЗ БАЛА... ТӨРМӘДӘ. Милләттәш

Алсу Хәсәнова. ЙОЛА. Хикәя

«ЯРАТТЫРАСЫМ КИЛӘ». Җыр тарихы

СОҢГЫ ХЫЯНӘТ. Булган хәл

КАБАКТАН... «ТОРТ» Мастер-класс





Бу язмам абыем Сөләйманов Сәүбән Ногман улы турында. Ул 1926 елда Чистай районы Татар Талкашы авылында туган. Аны 1943 елны сугышка алалар. Кечкенә генә буйлы, ябык гәүдәле улларын озату әти-әнигә бик авыр булгандыр.

Гражданнар сугышыннан яраланып кайткан 43 яшьлек әтиемне дә хезмәт армиясенә алалар. Әти-әниемнең сугышка кадәр алты балалары булган, сугыштан соң янә дүртәү туган. Без биш ир бала, биш кыз бала үстек. Әнием «Герой ана» данына лаек булды. «Сәүбәнем, йөрәк парәм», – дип өзгәләнә иде ул, абыйны сагынып. Абыем елдан артык Сослангерда хәрби әзерлек үтә. Аннан 25 нче танк бригадасында автоматчы-десантчы булып Смоленск, Орел, Минск, Варшава шәһәрләрен дошманнан азат итүдә катнаша. Бик күп үлемнәр күрә, сугышчан дусларын югалта. Үзе дә берничә тапкыр яраланып, хәрби госпитальләрдә дәвалана. Яраларын «ямый-ямый» Берлинга кадәр барып җитә. Авылга ул җиде елдан соң гына кайтып төшә. Күкрәгендә – «Кызыл Йолдыз» ордены, «Батырлык өчен», «Берлинны алган өчен» медальләре балкый. Сугыштан соң машина йөртүче булып эшләде абыем. Берничә чакырылыш рәттән депутат булып сайланды. 1956 елда гаилә корып җибәрде. Тормыш иптәше – укытучы Маһирә апа белән ике кыз үстерделәр, оныклар сөю бәхетенә ирештеләр. Бүгенге көндә абыем Мәскәү шәһәрендә яши.

Фәрвизә СӨЛӘЙМАНОВА.
Чистай.

Абыемның 1946 елның 5 мартында Германиядә төшкән фотосы.

Сугыш башланганда миңа 11 яшь иде.

Бала гына булсак та, нинди генә эшләр башкарырга туры килмәде. Ул чаклар искә төшсә, әле дә елыйсы килә.

Бишенче сыйныфны тәмамлагач, яшелчә бакчасына эшкә билгеләделәр. Инештән су ташый-ташый, кичкә иңбашлары әрни торган иде. Аеруча иртәнге сәгать дүрттән торып кәбестәләргә су сибүе бер җәфа булыр иде. Бригадирлар тау башыннан кемнең ничә көянтә су ташыганын санап торырлар иде. Кәбестәләр дүрт яфракка җиткәч, бер яфракны сиздерми генә өзеп ашый идек. Ашау начар иде шул. Бар булганы – кычыткан шулпасы. Әле кычытканны таба алсаң! Ашарга яраклы бөтен үләнне ашап бетереп барды авыл халкы. Яз көне бәрәңге басуына өшегән бәрәңге җыярга бара торган идек. Әни аларны төеп, он ясый, кабартмалар пешерә.

Гаиләдә биш бала үстек. Абый Тәтештә агрономлыкка укыды. Аны тәмамлауга, сугышка алдылар. Миннән кечкенә энем белән сеңлем батырып эшләрлек яшьтә түгел, бар авырлык әни белән икебезгә төште. Өйдә аяксыз әти белән авыру әби ята. Әти кышкы салкында кырга саламга дип киткән җиреннән аягын өшетеп кайткан иде. Бераздан ул аягы каралып чыкты. Аны бездән җиде чакрымдагы Олы Тархан хастаханәсенә салдылар. Мин, көн саен диярлек, ашарына илтә идем. Әтинең сызланудан, күзеннән яшь акканын күреп, йөрәгем әрни торган иде.

Әнием Маһирә Кече Тархан авылыннан. Ул – биш ир бала янында үскән бердәнбер кыз. 60 яшьлек Шәрифҗан һәм гарип Зәки абыйлардан кала, әнинең барлык туганнары да сугышта иде. Зәки абый хатыны, балалары белән ачтан үлделәр.

Нурислам абый хәбәрсез югалды. Ә Шәрәфислам абый тәмам йончып Бакырчыга кайтып төште. Аны уфалла арбасына утыртып, 12 чакрымдагы Кызыл Тарханга илткәнем әле дә күз алларымда. Миңа 15 яшьләр булгандыр. Шәрәфислам абый бераз утырып бара да, аннан җәяү атлый.

Сугышка 1945 елның гыйнварында киткән Равил абыем исә җиде елдан соң гына кайтты. Шәйморза авылы егете белән бергә киткән иде алар. Мылтыктан атарга өйрәтеп торганнардырмы, юкмы, аларны Украинага – Бандерачыларга каршы ташлаганнар. Шунда якын дустын – сугышка бергә киткән Шәйморза

егетен югалта. Бандерачыларны эзләп өй түбәсенә менгәндә була бу аяныч хәл. Баскычтан менәменешли үк абый кулына шуып кына төшә теге егет. Шәйморза авылы мулласының бердәнбер улы була ул. Әнкәй үзе дә шунда укыткан кеше, аның әти-әнисен яхшы белә. Абыйдан хәбәр килгәч, дөм сукыр әнкәй, энебез Әмирне җитәкләп, 30 чакрымдагы Шәйморзага авыр хәбәр илтә китә.

Абыем сугыштан үзе дә яртылаш сукыраеп кайтты. Сугышта җиде ел йөреп кайтса да, аны сугыш ветераны исемлегенә кертмәделәр. Имеш, ул сугышмаган, ә илне дошманнардан чистартуда гына катнашкан. Барлык ветераннарны Җиңү бәйрәме белән котлаганда ул читтә кала иде. Бөек Җиңүнең 55 еллыгы алдыннан, бик күп хатлар язганнан соң гына бирделәр аңа ветеран исемен. Кызганыч, ветеран булып абый ике генә ел яшәп калды.

Әнә шулай итеп, сугышның ачысы барыбызга да эләкте. Олыны да кечене дә аямады ул. Энем Әмиргә дә, 7 яшеннән сыер җигеп, камыл тырнап йөрергә туры килде. Шул вакыттагы бер вакыйганы гел искә төшерә иде ул. Бервакыт сыерны җигеп, Олы Тарханга коры-сары җыярга китә ул. Кайтырга чыкканда инде караңгы төшкән була. Безнең авылга кадәр җиде чакрым кайтасы бар, җитмәсә, зур гына ике чокыр аша үтәсе. Теге чокырларның берсенә килеп җитәрәк, энем кыстала да, сыерны туктатып тормый гына, йомышын йомышлый. Инде сыерны куып җитим дисә, сыер бер җирдә дә юк. Елый-елый юл буйлап йөгергәндә күзенә кара шәүлә чалынгандай була. Сукаланган җир өстеннән шунда таба чаба. Барып җитсә, сыерыбыз эскерттән салам күшәп тора. Сыерның башыннан кочаклап ала да, шатлыгыннан әй үбә, әй үбә энем. «Хатын-кызны да шуның кадәр үпкәнем булмады», – дип, шаярып искә ала иде ул бу вакыйганы.

Сугыш чоры булса да, яшьлек үзенекен итә икән. Эш күп булып, тәмам талчыксак та, кичләрен уенга чыга торган идек. Бервакыт бездә Куйбышев районы Әҗмәр авылыннан әтиле-уллы ике ир-ат һәм унлап хатын-кыз яшәп алды. Аларны Чурапан белән Чыгылдым авыллары арасына окоп казырга җибәргәннәр. Әле дә уйлап йөрим, ул бичараларны нигә шул авылларга гына урнаштырмаганнардыр инде? Ачлы-туклы көе окоп казыганнан соң, тагын ничә чакрым җәяү кайта иде бу апалар. Шулай бервакыт иптәш кызларымны кич утырырга алып кайттым. Окоп казучы апалар инде идәнгә тезелешеп йокларга ятканнар икән. Без керүгә, тиз генә сикерешеп тордылар да, безнең белән җырлап-биеп күңел ача башладылар. Әй күңелле булып истә калган иде шул кич.

Без җиденче сыйныфны тәмамлаганда сугыш бетте. Әни мине Казанга «Спартак» берләшмәсенең ФЗӨсенә алып килеп урнаштырды. Әле ул заманда да ачлык бетмәгән иде. Икмәкне карточка белән генә бирәләр. Сатып алырга акча юк. Без, кызлар белән базардан йон сатып алып, оекбаш, бияләй бәйләп сата идек. Әнә шулай итеп җан асрадык.

Шундый авырлыклар күреп тә, Аллага шөкер, 85 яшемне тутырып киләм. Бар теләгем: без күргәнне балалар, оныклар күрмәсен.

Зөбәйдә ЧИПЧИКОВА.
Тәтеш районы
Олы Тархан авылы.

Мин сугыш алдыннан туганмын. Әтием яу кырыннан кайтмады. 26 яшьтә тол калган әни безне ялгыз үстерде. Әтием Газизов Шакир Закир улы 1934 елда Буадагы ветеринария техникумын тәмамлагач, райком тәкъдиме белән Яңа Шалты авылына эшкә кайта. Монда аңа яшәргә йорт бирәләр.

Шулай бәхетле генә яшәп ятканда сугыш башлана. Әтине сугышка шунда ук җибәрмиләр әле. Китәсе кеше китеп беткәч, ул үзе теләп китә. Тиз генә әйләнеп кайтырбыз дисә дә, бу мәңгегә аерылышу була шул. Әти урынына эшкә икенче кеше килә. Әнигә яшәгән өен бушатырга кушалар. Әни, мескенем, февраль аенда өч баласын чанага утыртып, сыерын чана артына бәйләп, Баулыдагы әбиләргә кузгала. Юлда кайтканда сыерыбыз салкыннан туңып үлә. Әбиемнәр үзләре дә сигез җан кечкенә генә өйдә яшиләр иде. Без кушылгач, уникe кеше булдык. Әнием, абыйсы ярдәме белән бер йорт сатып алды.

Ачлык, ялангачлык хакында язмыйм, ул хакта инде күп яздылар. Без дә басудан өшегән бәрәңге җыя идек. Шул бәрәңгене көянтә-чиләк белән иңгә асып, ике-өч чакрым язгы пычракны изеп алып кайта торган идек. Сугыш беткәч, кибетләрдә азык-төлек күренә башлады. Аларны фронтовикларга аерып саталар иде. Кибет киштәсенә сөялеп, нәүмиз генә бер читтә торабыз да, кибетче апа: «Сезгә юк шул», – дигәч, моңаеп кайтып китәбез. Әни: «Әй балалар! Әтиегез кайтса, сезгә дә булыр иде дә, кайта алмады шул әткәгез», – дип, бер көрсенер дә, баштан сөеп юатыр иде. Әни үзе 91 яшендә үлде. Бер рәхәт күрмәде инде ул бу дөньяда. Әле ул вакытта фронтовик хатыны, тыл ветераны дигән исемнәр юк иде шул. Инде минем үземә дә тиздән 80 яшь тула. Барлык туганнарым арасыннан бер мин генә калдым. Әле дә күңелем әтиемне көтә. Ул исәндер, кайта алмый гына йөридер кебек тоела. Мондый кайгыларны яшьләр күрмәсен иде дип телим. Туган балалар әтиләре-әниләре белән үссен. Ачлыкны, ялангачлыкны татымасын. Ачлык бик куркыныч нәрсә. Тыныч, тук тормышның кадерен белеп яшик.

Роза НАСЫЙРОВА.
Баулы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



Бала белән уртак тел табу, мөнәсәбәтләрне көйләү җиңел эш түгел. Гаиләгә алынган ятим белән бигрәк тә... «Үсентесен сакламасаң, агачын күрмәссең...» Шундый шигарь белән «Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге һәм «Сердәш» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге белән берлектә алып барылган проектның максаты — социаль ятимлекне кисәтү, гаиләләргә авыр хәлдән чыгу юлын күрсәтү.

Фото интернеттан алынды

ЯРАТТЫРА АЛСАҢ ГЫНА...



Мәдинә АВЗАЛОВА

Бу тема, бу проблемалар миңа яхшы таныш. Балалар йортлары, анда тәрбияләнүче ятим балалар, бусаганы атлап керүгә каршыга йөгереп килгән нәни кыз һәм малайлар... Алар күзләрен тутырып сиңа карый, синнән нидер өмет итә. «Әни!» – диләр алар килгән бер ят кешегә. Әни әзли алар, әниләрен. Югалган, юкка чыккан әниләрен. Әйе, без күп йөрдек, күпне күрдек. Башка төбәкләрдә ятимнәр ничек яши икән дип, Мәскәү янында гына урнашкан Томилинодагы балалар авылына да, Пушкинога да барып кайттык. «Бала гаиләдә яшәргә тиеш!» дигән фикер безгә дә тынгылык бирмәде. Ә хәзер менә балалар йортлары, гомумән дә, булмаска тиеш дип сөйлиләр әнә. Бирсен Ходай! Ятимне үзеңнекe итә алган изге бәндәләргә рәхмәттән башка сүз юк анысы. Шулаен шулай да... Тик күңелгә тынгылык бирмәгән, борчып торган сораулар да җитәрлек. Дөресен әйткәндә, күп вакыт газиз балаң белән дә уртак тел табуы авыр. Ә биредә... сиңа сагаеп, шикләнеп караган, үзен бу гаиләдә чит тойган, язмыш кыерсыткан бәхетсез бала. Аны яратуыңа ничек ышандырырга менә?! Ә ярата алмасаң? Кире кайтару очраклары азмы? Безнең әниләр барысына да әзерме? Күп җирләрдә «әни» булырга җыенучылар белән озак вакытлар психологлар, педиатрлар, хәтта психиатрлар эшли. Опека һәм иганәче бүлеге хезмәткәрләре оештырган андый укулар бездә дә бар. Тик тәҗрибәдән күренгәнчә, бу гына аз. Бәлкем, шуңадыр да, ана белән бала мөнәсәбәтләрен җайларга алынган психологлар еш кына, хатаны кисәтәсе урында, тау булып өелгән бетмәс-төкәнмәс проблемаларны хәл итәргә, «Сердәш» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Наталья Анатольевна САБИРОВА әйткәнчә, «нәтиҗәсе белән эшләргә» мәҗбүр. Күптән борчыган сорауларга җавапны без аның белән бергәләшеп эзлибез.

«Кызганмагыз, ярдәм итегез!»

Психолог үзе күргәннәрне, үз башыннан кичкәннәрне сөйли. Тәрбиягә кыз белән малай алган гаиләдә кинәт кенә гаилә башлыгы үлеп китә. Әни кеше ике бала белән ялгызы кала. Малайга – алты, кызга – ундүрт яшь. Яшүсмерлек чорын педагоглар да, психологлар да «авыр чор» дип атыйлар. Бер караганда, балалыктан чыгып җитмәгән, икенче караганда, ул инде «зур» кеше, мөстәкыйль, ничек яшәргә кирәклеген үзе белә. Уйламыйча, ялгыш бер сүз ычкындырсаң, усал гына җавап та ишетәсең.

– Башта әни кеше малае белән генә килде, – дип дәвам итә психолог. – Ә кыз: «Минем тормышыма тыгылмагыз!» – дип кенә җибәргән. Ана балаларын кире Балалар йортына кайтару турында уйламый да. «Миңа нишләргә? Мин аларга әтиләрен алыштыра алырмынмы?» – ди. «Мине кызганмагыз, ярдәм итегез!» – ди. Кызгану кешене көчсезләндерә бит ул. Без аңа булышырга булдык. Алар өчәүләшеп (кыз да килеп кушылды) тәрбиягә бала алган әти-әниләргә ярдәм төркеменә йөри башладылар. Без мондый очрашуларны һәр атнаның ял көннәрендә үткәрәбез. Әти-әниләр тәҗрибә уртаклаша, баланың буш вакытын ничек итеп файдалырак оештыру хакында психологлар белән киңәшә. Алар өчен гаилә клубы эшләвен дә искәртәсем килә. Әти-әнисен югалткан балаларга игътибарыбыз аеруча зур. Психолог аларга эмоция һәм хис-кичерешләрне чагылдыруга юнәлдерелгән уеннар тәкъдим итә. Бала бу очрашудан үз-үзенә ышанып, тынычланып китәргә тиеш. «Иң мөһиме – проблеманы яшермәскә, аннан качмаска, бергәләшеп чишү юлларын табарга», – ди бу өлкәдә унбиш еллык эш тәҗрибәсе булган әңгәмәдәшем.

Әйтергәме, әйтмәскәме?!

Үзенең дүрт баласы янына тәрбиягә тагын җиде бала алып, гөрләшеп, матур-дус гаилә булып яшәп яткан әнидән: «Балалар үз әниләрен беләләрме?» – дип сорага期ным бар. «Беләләр генә түгел, мин аларга әниегезне онытмагыз, дип, туктаусыз кабатлап торам», – дигәч, гаҗәпләнгән идем. Баласын язмыш кочагына ташлап киткән әнидән нинди яхшылык көтәргә мөмкин?! Бәлкем, ул хаклыдыр да. Ләкин закон буенча, әйтик, уллыкка-кызлыкка алу очрагы булганда, сер итеп сакланырга тиеш. Дөрес, ул күбрәк бишектән алып тәрбияләнгән балага кагыла. Шулай да, бала көннәрдән бер көнне барыбер ул серне беләчәк. Әйтәчәкләр аңа.

– Шушы көннәрдә генә бер ханым белән очраштык, – дип дәвам итә сүзен Наталья Анатольевна. – Хәсрәте чиктән ашкан, үзе елап беткән. Кемдер балага үз әти-әнисе түгеллеген «тишкән». Бүлмәсенә кереп бикләнгән дә, сөйләшми ди. Мондый хәлдә баланы ялгыз калдырырга ярамый. Аның белән сөйләшергә кирәк икән, ә бәлкем, кочаклашып елашырга, әнисенең фотосы сакланган булса, аны алып күрсәтергә, бер сүз белән әйткәндә, кризисны бергәләп кичерергә... Шулай дидем. Ул сезне гафу итәр, һичшиксез аңлар, дидем.

«Шыксыз үрдәк бәбкәсе»

Мәктәп таләпләренә яраклашу, аның кагыйдәләре белән яшәү, сыйныфташлары, укытучылар белән аралашу гаиләгә алынган бала өчен, чын мәгънәсендә, авыр, җитди сынауга әверелә. Андый бала, гадәттә, өлгереш һәм тәртибе белән яшьтәшләре арасында аерылып тора. Укытучы моны аңларга тиеш. Чөнки баланың үз-үзен тотышы бу очракта бары педагогка бәйле. Әйтик, сыйныфташлары белән мөнәсәбәтләрдә киеренкелек килеп чыга калганда, укытучы: «Син миңа бик ошыйсың. Син – молодец!» – дип, укучылар алдында аны мактап, үсендереп алса, балалар да аңа «шыксыз үрдәк бәбкәсе»дәй карамаслар иде.

Билгеле, үзләрен гел гаепле хис иткән, нидәндер гел куркып торган андый балаларның саклагыч реакцияләре гадәттән тыш көчле була. Алар ярсуларын тыеп кала алмый. Көтелмәгән күңелсезлекләр килеп чыкмасын өчен укытучы бала ту-



«Сердәш» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Наталья Анатольевна САБИРОВА

Әңгәмәдәшем «Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы килешүе кысаларында башланып киткән әлеге чараларның тиктомалдан түгеллеген дәлилләүче саннар, фактлар китерә, сәбәпләрен ачыклый башлый.

– Безгә проектны эшләгән дүрт ай дәвамында ятимнәрне үз канаты астына сыендырган унике гаилә мөрәҗәгать итте, – дип сөйли Наталья Анатольевна. – Бу аз түгел. Кайсы баласы белән килә, кайсы үзе генә. Алар төрле, әмма һәркайсында бер бәла: бала күңеленә ачкыч таба алмыйлар. Һәр ата-анага бала тәрбияләүдә кагыйдә булырга тиешле сүзләрне кабатлыйбыз: балагызны беркайчан да беркем белән дә чагыштырмагыз, кычкырып, боерып сөйләшмәгез, аңа әйтәсе сүзегезне дөрес итеп аңлата белегез, дибез. Бу киңәшләр барлык ата-аналарга кагыла.

Ятим тәрбияләүче гаиләдә иң зур, иң җитди проблема бала мәктәпкә киткәч башлана. Ул начар укый, сыйныфташлары белән аралашмый. Өйдә дә, мәктәптә дә аннан үзен яхшы тотуны таләп итәләр. Ә бала булдыра алмый, шуңа да үзен бәхетсез хис итә. Шул чагында кирәк тә инде балага ата-ана ярдәме. Кызганычка каршы, ятимнән баш тарту очраклары нәкъ менә ул мәктәпкә киткәч, сабый җылы сүзгә, таянычка нык мохтаҗ вакытта күбәя.

рында барын да алдан белеп торырга, ә әти-әни проблеманы яшермичә сөйләп бирергә тиеш. Мәктәп һәм гаилә бала тәрбияләүдә бер сүздә торса, бер-беренә булышса, әлләниләр майтарырга була. Мөслим районында яшәүче Тәнзилә Касыймова сөйли:

– Балалар йортыннан алганда Динабызга унөч яшь иде. Кайткан көннәре әле дә күз алдымда. Һәр әйткән сүзне сагаеп кабул итә, ачылып китми. Аның – үз дөньясы, ул шунда кереп бикләнгән дә, мәңге чыкмас сыман. Икене икегә тапкырлый, Татарстан башкаласының исемен дә атый алмаган баланы укытучылар коррекция мәктәбенә бирергә тәкъдим иттеләр. Мин риза булмадым, шундук каршы чыктым. Һәм бала гадәти мәктәпкә – өченче сыйныфка укырга китте.

Психологлар әлегә күбрәк кисәтү эшләре белән түгел, килеп туган кыенлыкның нәтиҗәсе белән эшлиләр. Ләкин бу инде эш узгач, соңрак була.

Укытучысы шундук балаларга Динаның озак авыруы, шуңа дәрес калдыруы һәм алар белән укырга мәҗбүр булуы хакында әйтеп куйды. Баланы беренче партага утырттылар. Материал үзләштерү аңа башта бик кыенга туры килде. Без кызым белән бергәләп укыдык: тапкырлау таблицасын, кагыйдәләр өйрәндек, мәсьәләләр чиштек. Һәр текстны унышар мәртәбә укып чыга торган идек. Ник дигәндә, баланың хәтере начар, ул тиз оныта иде. Хәтерне яхшырту өчен нинди генә күнекмәләр кулланып карамадык. Дина әкренләп зур күләмле текстларны истә калдыра, «бишле» билгеләре ала башлады. Һәр уңышны гаиләдә зур бәйрәм буларак кабул иттек. Мәктәптә Динаны яраталар. Укытучылар аннан канәгать: өйгә бирелгән эшләрне үтәп килә, дәрестә актив. Август ахырында без аттестация узып, 5 нче сыйныфка күчтек. Бала нык үзгәрде, мәктәп чараларында да теләп катнаша. Аның дистәләгән мактау кәгазьләре бар. Хәзер кызны танымассың да, очып кына йөри. Ә мин аның белән горурланам: ул һәрьяктан җитлеккән көчле шәхескә әверелде.

Миңа кагылмый, димә...

«Сердәш» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү бүлегенә опекуннар, тәрбиягә бала алган әниләр генә йөрми. Анда баласы белән мөнәсәбәтләрне көйли алмаган, авыр хәлләрдә калган – гаиләдә низагтавышлар чыккан очракта башка әниләр дә килә. Җитәкченең әйтүенә караганда, октябрь, ноябрь, март, апрель айларында аена 20 шәр, 30 ар кеше мөрәҗәгать итә икән.

– Нинди сораулар белән? Арада психиатр ярдәменә мохтаҗ балалар очрыймы? Бу сорауны тикмәгә бирмибез. Соңгы вакытларда яшүсмерләр арасында үз-үзенә кул салу – суицид очраклары арта бара. Бу хакта инде язып чыкканыбыз булса да, сөйләшүне янә шул юнәлешкә борабыз.

– Баланы психиатрга алып барудан куркырга кирәкми, – дип куәтли сүзебезне Наталья Анатольевна. – Баласын «юләрләр рәтендә» күрәсе килмәү күп ананың аңын томалый. Уйламыйча әйтелгән кечкенә генә бер сүз дә ата-ананы аякка бастырырга тиеш. Бала: «Үләсем килә» яисә «үз-үземә кул салам», – дип ычкындыра, ә ата-ана моңа игътибар итми. Юкка. Казан шәһәре мәктәп-

Баланың төрлесе бар: кайсы бик әйбәт укый, кайсы укырга теләми, начар укый. Ачуланып, кимсетеп, тавыш яки кул күтәреп бала белән араны бозмагыз. Бала: «Начар укыйм икән, димәк, мин үзем начар, димәк мин әти-әниемә кирәк түгел», — дигән фикергә килмәсен. Имтиханнар чорында суицид очраклары күбәюе барыбызны да сагайтырга тиеш.

■ Белгечләргә мөрәҗәгать итәргә. Алар гына дөрес, төгәл итеп баланың үсеш мөмкинлеген билгели ала. Аң-белемен үстерә торган күнегүләр тәкъдим итә.

■ Гаиләдә баланы һәрьяклап камилләштерә торган мохит булдырырга, аның белән туктаусыз аралашырга, башлангычын хупларга, баланың шөгыле белән ихлас кызыксынырга.

■ Ятим баланың үсештә артта калуы, ихтимал, иң элек аңа наз-ярату җитмәгәнлектән булуын исегездә тотыгыз.

■ Балагызны башка балалар белән чагыштырмагыз. Бу юньлегә китерми. Үз-үзенә ышанычсызлык шуннан килә. Баланың һәркайсы – уникаль. Аның кимчелекле якларыннан башка уңай яклары да җитәрлек. Аны бары үзе белән генә чагыштырып карагыз: элек эшли алмый идең, хәзер әнә булдырасың, дип үсендерегез, мактагыз.

■ Сабыр булыгыз. Барысын да берьюлы һәм шундук гамәлгә ашыру мөмкин түгел. Бер генә бакчачы да чәчәге тизрәк ачылсын дип, бөресен әйләндереп куймый. Балагызга аның нерв системасы һәм интеллектуаль потенциалы күтәрә алырдай эшләрне генә кушыгыз. Төнгә кадәр дәрес хәзерләүләр уңай нәтиҗә бирми.

■ Балагызда һәрчак уңай якны гына күрегез. Беркемнең дә булдыра алмаган эшне эшлисе килми. Балагыз кечкенә генә уңышка да куана белсен.

■ Нәтиҗәсе өчен түгел, тырышканы өчен мактагыз. Баланы кыенлыкларны үтәргә өйрәтегез. Бу – иң мөһиме. Ятимнәргә ул авыррак бирелә. Беренчедән, ташланган булуы аның үз-үзенә ышанычын югалта. Ә бу – эзлеклелек һәм тырышлыкның нигезе. Икенчедән, үз әти-әнисендә булмаган көчне һәм сабырлыкны аларга үзләренә булдырырга туры киләчәк.

■ Белгечләргә түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итегез: Казан шәһәре, Годовиков урамы, 14 нче йорт, 2 нче подъезд. «Максимов урамы» тукталышы, «Авиатөзелеш» метро станциясе.
246-44-01 телефоны буенча «Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәгенә дә шалтырата аласыз. Ятим тәрбияләгән гаиләләр өчен хезмәт күрсәтүләр бушлай.

ләренең берсендә бер үк сыйныфта ике мәртәбә суицид очрагы булды.

– Ни өчен бер үк мәктәптә, бер үк сыйныфта шундый хәл? Сыйныф җитәкчесе, психолог ни карый? Мондый куркыныч кабатланулардан баланы ничек араларга?

– Ул мәктәптә көчле психолог эшли. Аңлыйсыздыр, балага тормыш кыйммәтләрен дөрес итеп аңлату бу очракта аеруча мөһим. Мисалга, «Ул инде беркайчан да әти-әнисе белән, сезнең белән була алмый» яки «Тормыш шундый матур, ә ул аның матурлыгын беркайчан да күрмәс инде», – дип әйтергә була. Балагыз: «Миңа бик авыр, бик куркыныч», – дип сөйләнә башлый икән, тыймагыз, туктатмагыз, сүзен әйтеп бетерсен, эмоциясен тышка чыгарсын. «Ике мәртәбә кабатланган», – дисез. Бу әле берни турында да сөйләми, бернигә ишарәләми. Шуны истән чыгармагыз, бер генә кеше дә моның ише куркыныч адымнан, афәттән хали түгел. Һәр бала – аерым шәхес, һәркайсы белән аерым эшләргә кирәк. Фаҗигане булдырмас өчен алдан чарасын күрергә: әлеге дә баягы психологка, психиатрга барырга, сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Педиатрның, терапевтның да роле зур биредә. Баланың үз-үзен тотышында сәерлек барлыгын алар тотып ала, алар чаң суга. «Мин сезгә ярдәм итә алмыйм, бәлкем, сезгә психиатрга күренергә кирәктер», – дип кенә әйтү дә җитә бит! Психологлар ярдәме җитмәгән очракларда психотерапевт белән берничә сеанс әңгәмә булыша ала.

Әти-әни вазыйфаларын үтәү җиңел түгел. Күбебез бу авыр һәм гаять җаваплы эшкә бернинди хәзерлексез алынабыз. Һәм шуның белән килеп кабабыз да. Ялгышулар, хаталар була... Сират күпере кичә-кичә тәҗрибә туплыйбыз. Бала үзен төрлечә тота: ул көлә, шаяра, сүзне тыңламый. Әмма баладагы тынгысызлык, шомлану, курку, агрессия һәм башка шуның ише сыйфатлар сезне сагайтырга тиеш. Әгәр дә инде кызыгыз йә улыгыз укырга теләми яки начар укый, өйдән чыгып китә, бертуктаусыз компьютер каршында утыра икән, бөтен эшегезне ташлагыз да, аны белгечкә алып барыгыз!

...НТВ каналында яшь тә тугыз айлык баласын калдырып, «эшкә чыгып киткән» җирдән берничә көн югалып торган 21 яшьлек яшь әнине күрсәтеп яталар. Башка сыймаслык хәлләр: «Мин бит идәнгә бер стакан сөт, печенье, алма куеп калдырдым. Үзе ашар, дигән идем. Кайтсам... үлгән», – ди әни кеше. Куркыныч булып китә. Баланы, бәләкәчне берничә көнгә түгел, бер сәгатькә дә ялгызын калдырырга ярамаганлыгын белмәгәнме?! Хәер, үзе дә балалар йортында үскән ятимәгә моны аңлату мөмкин булмаган эш булып чыкты. «Мин үземне гаепле санамыйм», – диде ул меңләгән тамашачыны хәйран калдырып.

«Бу миңа кагылмый...» – дияргә ярамый. Гамьсезлек фаҗигагә китерергә мөмкин!

Томилинодагы Балалар авылында үскән ятимнәр мөстәкыйль тормышка аяк басканчыга, 23 яшькә җиткәнчегә кадәр «әни»ләре – социаль хезмәткәрләр күзәтүе астында булалар. Әйтәсе килгәнем: балигъ булуга чыгардым да җибәрдем түгел, алга таба да аның өчен җаваплылык тоярлык булсаң гына, ярата, яраттыра белсәң генә ятимне кочагыңа ал. Психологлар шулай дип кисәтә.



БАЛАЛАР ХОСПИСЫ ЯРДӘМ СОРЫЙ!

(Хосписны оештыручы – Анжела Вавилова исемендәге фонд)

Безнең Хосписның девизы: баланы тулысынча сәламәтләндереп булмый икән, бу әле аңа ярдәм итәргә кирәкми дигән сүз түгел. Сез безнең кечкенә авыруларыбызга һәм аларның ата-аналарына ничек ярдәм итә аласыз?

- Авыртуларсыз яшәргә һәм һәрвакыт янәшәдә булырга тырышып.
- Ялгызлыктан, көчсезлектән һәм дәвалау өчен даими рәвештә акча эзләүдән котылу юлларын табып.
- Махсус туклану һәм дарулар алырга ярдәм итеп.
- Аякка басып йөрергә көч булмаганда, йөрү мөмкинлеге бирә торган җайланмалар булдырырга, уңайлы караватта ятарга, иркен итеп суларга мөмкинлек тудырып. Газаплануларны киметеп.

Ярдәм итүнең иң гади ысулы – 7715 номерына Анжела пробел сумма (Мәсәлән: Анжела 150) тексты белән СМС җибәрү.



Ярдәмнең башка ысуллары – www.angela-vavilova.ru сайтында
Хосписның кечкенә авырулары исеменнән Сезгә зур рәхмәт!

Анжела Вавилова исемендәге фонд идарәсе.



Анжела Вавилова исемендәге фондның реквизитлары:
420039, РТ, г.Казань, ул. Академика Королёва, д. 67,
р/сч. 4070 3810 6000 20000 198 в «Ак Барс» Банке,
к/сч. 301 018 100 000 000 008 05,
БИК 049205805, **ИНН** 1660064436, **КПП** 165801001.

Түләүнең максаты:
Благотворительное пожертвование для онкобольных детей – пациентов Детского Хосписа. НДС не облагается.











«ЙОЛДЫЗЛАР КАБЫНА ИКӘН, ДИМӘК, АЛАР КЕМГӘДЕР КИРӘК» ДИГӘН БИТ ШАГЫЙРЬ ДӘ.

Нәкъ шулай димәгән булса да, мәгънәсе шулай. Йолдызлар кабызу серен һәм йолдызларның кабынырга гына түгел, бәлки балкып янарга да тиешлеген Татарстанда моннан унбиш ел ук бик яхшы аңлап алалар.





ЙОЛДЫЗЛАР КАБЫНГАНДА

«Созвездие–Йолдызлык» фестиваленең йомгаклау гала-концерты шушы биниһая киң колачлы проект эчендә кайнаган кешеләр – оештыручылар, методистлар, хореографлар, вокал педагоглары, музыкантлар, ниһаять, талант ияләренең үзләре өчен генә дә түгел, бөтен халык бәйрәменә әверелә.

Йомгаклау турында исемнәре җиңүчеләр исәбендә аталсын өчен Татарстанның талантлы балалары сентябрьдән башлап апрель азагына кадәр бииләр, җырлыйлар, шигырь ятлыйлар – кыскасы осталыкларын чарлыйлар. Шул арада кызыклы концерт номерларының антуражы булырга тиешле хикмәтле костюмнар тегелә. Гомумән, «Йолдызлык» концертлары кием, төсләр бәйрәме дә бит әле ул.

Моннан унбиш ел элек 90 нчы еллар шаукымыннан чыгып килүче Россия дигән ил Татарстанның талантлы балаларын барларга керешүен читтән генә, беркадәр сәерсенеп күзәтте. Әмма «Йолдызлык» канатларын һаман киңрәк җәя башлагач, хәтта Мәскәүдә яшәп ятучы иҗат әһелләренең дә бу проект белән кызыксынуы артты. Читтән генә күзәтеп йөргән Александр Градский кебек мэтрлар «түгәрәк уртасына» төшкәннәрен сизми дә калдылар. Ә инде Динә Гарипова, Эльмира Кәлимуллина кебек кызларыбыз сәнгать дөньясының колакларын һәм күзләрен үз тарафларына борып куйгач, провинция кызларыннан Йолдыз-кызлар ясаучы «Йолдызлык» белән кызыксыну бермә-бер көчәйде. Бу «фабрика»дан үсеп чыккан «Дорога из города» кебек коллективларны да кинәт кенә һәм бик вакытлы искә төшерделәр.

Аерым мәктәпләрдә башланып, аннан районнарны, төбәкләрне биләп алган, бөтен республикага җәелгән, соңыннан Казанда җиңүчеләрен раслаткан фестиваль тора-бара супер фестивальгә үк әйләнеп китсен өчен нибары унбиш ел гомер җиткән. Шушы унбиш елда фестиваль Татарстан чиген атлап чыгып, татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә дә танылып өлгергән. «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узган супер финалда чыгыш ясаучылар арасында – Чиләбе, Әстерхан, Ульян өлкәләре, Удмуртия, Марий Иле, Мәскәү вәкилләре.

Супер-финалда сәхнә декорациясенең иң үзәгендә Җир шары моделе тору бик тә, бик тә символик иде. Фестивальгә шәрәфле кунак һәм шәрәфле жюри әгъзасы итеп чакырылган Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Михаил Борисов әлеге «Җир шары»на мөнәсәбәтен белдереп болай диде: «Мин бу сәхнәгә чыккан саен үземне Җир шары уртасында басып торган кебек хис итәм. Димәк, Үзәк бирedә – Казанда!» Әлеге сәнгать әһеленең тамаша залы халәтен бәяләве дә үзенчәлекле: «Минем әле беркайчан да балалар белән аралашудан, алар белән беравыздан хәрби-патриотик җырлар җырлаудан шулкадәр рәхәтлек кичергәнем юк иде».

Шушындый күңел кузгатырлык репертуар формалаштыруда жюриның өлеше, әлбәттә, зур булгандыр. Чөнки Татарстанның халык артисты Зилә Даян кызы Сөнгатуллина җитәкчелегендәге жюри әгъзаларына, мөгаен, бая без санап үткән төбәкләргә дә барып чыгарга туры килгәндер. 13-16 апрель көннәрендә «УНИКС» тамаша залында узган финал өчен сайлап алу концертларында жюри дүрт мең биш йөз баланың чыгышын карап бәяләде.

Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап уздырылган супер финалда җиңүчеләр исемлеге дә гадәттәгедән күбрәк иде. Быел лауреатлар һәм җиңүчеләр исемлегендә 156 бала күрсәтелде. Чөнки жюри һәр номинациядә, гран-прилардан тыш, берничә икенче һәм өченче урыннар билгеләгән икән.

Резюме күтелгәннән гадирәк: юк, «Йолдызлык» хәрәкәте ул «фабрика» гына түгел, нәкъ менә галәми йолдызлык!

Сабый балалар арасында вокал-соло номинациясендә Казан алдырса, үсканрәк балаларның таланты белән Ижау, Минзәлә, Чаллы, Яшел Үзән горурлана алды. Гомумән алганда, картина мондыйрак: җиңүче балалар Әлмәт, Чаллы, Мамадыш, Яшел Үзән, Актаныш районнарыннан күбрәк күренә. Әмма шулар арасында балкып китә алган талантлы балалар Балык Бистәсе, Ютазы, Арча, Питрәч, Баулы, Кукмара төбәгендә дә табылу сөендерә.

Талант тәрбияләү – алмаздан бриллиант кырлауга тиң хезмәт ул. Һәм ул күмәк хезмәт. Аңа ата-ана да, мәктәп тә, остаз да өлеш кертә. Шул ук вакытта җирле хакимиятнең бу изге эшкә хөрмәт белән каравы, матди яктан булышырга әзер торуы да бик зарур.

Гала-концерт ике блоктан торды. Бөек Җиңү хөрмәтенә махсус уйланылган җырлы-биюле композицияләр

күплеге быелгы бәйгенең үзенчәлеге иде. «Дорога из города» Казан бию театры каршындагы «Зөбәрҗәт шәһәр» төркеме биегән полька, «Шатлык» балалар төркеменең ут чыгарып биюе, Азнакайдан «Фантазия» вокал ансамбленең «Вася-Василек» җыры көчле алкышларга күмелде. Казан мәдәният һәм сәнгать университеты каршындагы «Кояш өе» бию коллективының «Ә таңнар тыныч иде» дигән композициясе сокландырды да, уйландырды да. Зәйдән «Мирас» төркеме чыгышы да сокландырган чыгышлар исәбендә булды.

Бер тенденция ачык күзәтелә: «Йолдызлык» балалар өчен генә булудан туктаган икән бит инде. Унбиш ел дәвамында фестиваль аша узган 750 бала, балалык чорын үтеп, яшьләр сафына кушылган, әмма сәнгатьтән китмәгән. Алай гынамы соң? Фестиваль хәрәкәте, хәзер зур бер Хәрәкәткә әверелеп, җитди кешеләрнең кадерле баласына, иң беренче бурычы кебек гамәленә әверелгән. «Йолдызлык»та катнашкан балалар өчен иң мөһиме җиңеп чыгу да, бүләк алу да түгел. Иң мөһиме – үзеңне зур, тату гаиләнең бер бәхетле әгъзасы итеп тою. Лауреатлар һәм фестивальдә җиңүчеләр өчен җәйге һәм кышкы иҗат яллары, осталык класслары, фестивальдә катнашучыларны видеоклипларга төшерүләр оештырыла. Алар өчен «Талант» Бөтенроссия журналы чыгарыла.

Бу уникаль проектта талантлы балалар, аларның остазлары кулга-кул тотынышып эшли.

Фестивальләр аша үткән сәләтле балаларның аеруча булдыклылары Татарстанның һәм Россиянең мәшһүр уку йортларына юллама алалар.

Фестиваль нәтиҗәләре буенча талантлы балаларның остазларына да мактаулы исемнәр бирелә. Быел дүрт педагог – Сарманнан Гөлназ Латыйпова, Чаллыдан Елена Акепсимова, Балык Бистәсеннән Елена Фәсхетдинова белән Әлфинур Шаһвәлиева атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булдылар. Фестивальдә үскән Рузил Гатин белән Айдар Сөләйманов «Татарстанның атказанган артисты» дигән исемгә лаек булдылар.

Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев конкурста җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендиясе булдырган иде. Беренче лауреатлар Рузил Гатин, Диләрә Ваһапова, Ирида Хөсәенова, Елена Соловьева, Елена Данилова һәм тагын берничә егет-кыз ГИТИСта уку бәхетенә ирештеләр. Рузил Гатин белән Айдар Сөләйманов фестивальнең интернет-сайтын булдырдылар. Алар ук, ГИТИСта укучы башка лауреатлар белән бергә, аз керемле гаиләләрдә үсүче талантлы балаларга ярдәм фонды оештырдылар. «Йолдызлык» шәкертләре Татарстан һәм Россия чиген атлап чыгып, халыкара иҗат ярышларында көч сынаша башладылар. Әйтик, алар Франциянең Канн шәһәрендә Россия сәнгате фестивалендә катнаштылар. Ә ил чикләрен атлап чыгу турындагы фикер 2009 елда фестивальнең гала-концертын Шанхай хезмәттәшлек оешмасына кергән илләрнең мәдәният министрлары каршында чыгыш ясаганнан соң килгән иде.

2000 елда «Йолдызлык» хәрәкәте башлангач, ябылган сәнгать мәктәпләре кабат ачыла башлады. Алай гына түгел, музыка мәктәпләре янәшәсендә хореография сыйныфлары пәйда булды. Татар милли киемнәренә игътибар артты. Хәтта жюриның даими әгъзалары да хезмәт бүлеште. Әйтик, Татарстан Президенты каршындагы мәдәнияткә ярдәм итү фондының башкарма директоры Нурия Һашимова – «Коткаручы», хореограф Раилә Гарипова – «Ут кабызучы», журналист Дмитрий Пивоваров – «Мәдәният индикаторы», фестивальнең башкаручы директоры Айдар Гайнетдинов – «Җиңү нигезе», жюри рәисе Зилә Сөнгатуллина – «Фестивальнең җаны», Диана Сәфәрова – «Иң объектив тәнкыйтьче».

Ә менә Дмитрий Тумановны фестивальнең атасы һәм «бозваткыч» дип атау дөрес булыр. Фестиваль аның җиңел кулыннан башланган иде ләбаса. Башы тулы идеяләр булган бу кеше үзе Татарстанның беренче Президентына һәм бүген Президент вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнехановка бик рәхмәтле. Чыннан да, Рөстәм Миңнеханов «Йолдызлык»ны балалар планетасы дип танып, дөньяда талантның иң дәрәҗәле тормыш критерие булуын исбатлауда аның ролен югары бәяләде. Хәтта Россия Президенты Владимир Путин да, Казанның меңьеллык бәйрәменә килгәч, яшь талантларның осталыгына хәйран калды. Гомумән, республика җитәкчелегенең үз балалары өчен шулай күп нәрсәләр эшләве бөтен дөньяда соклану уята.

Үз гимны булган һәм дәүләти статуска ирешкән хәрәкәтнең үз бинасы, үз телеканалы, үз тамаша залы булдырылса иде дигән хыял Дмитрий Тумановның гына хыялы түгел. Иң әһәмиятлесе: бу хыял-теләкне республика җитәкчеләре гадел теләк, урынлы хыял дип саный.

«Йолдызлык», Татарстан чикләрен атлап чыгып, тугандаш республикаларга да бәйрәм илтә. Әйтик, 1–18 июль көннәрендә Кырым Республикасында «Йолдызлык»ның икенче иҗади көннәре узачак.

P. S. «Созвездие–Йолдызлык» фестиваль хәрәкәте кысаларында уздырылган һәр чара елның иң әһәмиятле вакыйгасы булып санала. Халыкара балаларны яклау көнендә исә «Казан Кремле» музей-тыюлыгында узган бәйрәмдә фестиваль лауреатларына һәм җиңүчеләренә дәүләт стипендияләре бирү тантанасы узды. «Вокал-соло», «Вокаль ансамбльләр», «Бию», «Конферанс» номинацияләрендә җиңүчеләргә махсус стипендияләр билгеләнде – барысы 35 призлы урын. Президент вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов бу проектның уникаль булуын ассызыклады һәм «Йолдызлык» балаларының сәләтен чын профессионалларга көндәшлек тудырырдай дип бәяләде. «Киләчәгебез бүген балаларга нинди мөнәсәбәттә булуыбызга бәйле», – диде ул бүләкләр тапшырганда.

ҖӘМГЫЯТЬ

■ Татарстанда парламентаризм үсешенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш узды. Анда Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко, Россия Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары Александр Жуков, Татарстан Республикасы җитәкчеләре катнашты. Тантанага чакырылган 700 дән артык кунак арасында барлык чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутатлары, иҗтимагый оешмалар, сәяси партияләр вәкилләре, РФ Дәүләт Думасы депутатлары, Федерация Советы әгъзалары, Россия Федерациясенең башка субъектлары, чит илләр парламентлары бар иде. ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында 25 елда Татарстан Республикасы формалашу һәм аның уңышлары турында сөйләде. Әлеге тантанада беренче тапкыр «Парламентаризм үсешенә керткән өлеш өчен» Почет билгесе тапшырылды. Беренче бүләкләнүчеләр арасында — Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Индус Таһиров, Разил Вәлиев кебек күренекле шәхесләр. Рөстәм Миңнехановка шулай ук РФ Федераль Җыены Советының юбилее уңаеннан гамәлгә куелган «Федерация Советы. 20 ел» медале, ә Фәрит Мөхәммәтшинга Федерация Советының Рәхмәте тапшырылды.

■ Халыкара балаларны яклау көнендә ТР Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» Республика фонды Иганәчеләр шурасы рәисе Минтимер Шәймиев Борынгы Болгарга һәм Зөя утрау-шәһәрчегенә багышланган рәсем һәм иншалар республика конкурсында җиңүче балаларны бүләкләде. Дәүләт киңәшчесе конкурста тәкъдим ителгән эшләргә югары бәя бирде һәм бәйгедә катнашучыларны беренче карлыгачлар дип атады. «Бу эшләр һәммәсе балаларыбыз өчен горурлык хисләре уята, киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк», — дип хуплады ул бу яңа башлангычны.

■ Татарстан халкының Бөек Җиңүгә керткән өлеше турында Татарстан меценатлары җыйган акчага фильм төшерелде. Анда сугыш чоры фотолары һәм видеоархив материаллары файдаланылды. ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов фильмны үз Инстаграммына урнаштырды. 700 мең татарстанлы сугышка киткән, шуларның 10 меңнән артыгы — кызлар.

СӘЛАМӘТЛЕК



■ Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов Республика балалар клиник хастаханәсендә авыру балалар һәм аларның әти-әниләре белән аралашты, балаларга халыкара яклау көне уңаеннан бүләкләр тапшырды һәм тизрәк савыгып чыгуларын теләде. Авыру балалы гаиләләргә дәүләттән ярдәм күрсәтелергә тиешлеген ассызыклады. Соңыннан Рөстәм Миңнеханов балалар хастаханәләре җитәкчеләренә махсуслашкан 28 машина ачкычы тапшырды.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасын җитәкләүче Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы Россия Федерация Советының Рәхмәтенә ия булды. Мәртәбәле бүләкне аңа Совет рәисе Валентина Матвиенко Россия хатын-кызлар оешмасының 25 еллыгына багышланган тантанада тапшырды.

МӘДӘНИЯТ



■ Республика район һәм авылларында Сабан туйлары гөрләде. Бөтенроссия авыл Сабан туе исә Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылында узды. Анда Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Европа Сабан туен Германиянең Берлин шәһәрендә 18–21 июньнәрдә үткәрү күздә тотыла. 18 июльдә Красноярск өлкәсендә Федераль Сабантуйга җыелачаклар. Казан Сабан туе быел 1 августка билгеләнгән.


■ Казанда төрки халыкларның «Нәүрүз» XII халыкара театр фестивале узды. «Бу бәйрәм безнең халыкларны берләштерә, төрки халыклар арасында мәдәни элемтәләрне ныгытуга булыша», – диде үзенең сәламләү сүзендә ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин. Быелгы фестиваль Казакъстан Республикасы театр сәнгатенә багышланды. Алматы, Астана, Актау шәһәрләре театрлары тамашачыга казакъ сәнгате белән якыннан танышу мөмкинлеге тудырды. «Нәүрүз» фестивалендә быел Симферополь Кырымтатар музыкаль драма театры да катнашты.

СПОРТ

■ Татарстан спортчысы Алинә Фазылҗанова Стендка ату буенча 7 нче халыкара кубокта «алтын» яулады. Кубок Ориматтила шәһәрендә (Финляндия) уйнатылды.

■ Татарстан кызлары Швециянең Сундваль шәһәрендә узган ятып йөк күтәрү ярышыннан зур җиңү белән кайтты. Дөнья чемпионатында «57 кг һәм 52 кг кадәрге» авырлык үлчәмендә беренче урынны Лариса Коткова белән Виктория Штейнке яулады, ә Анна Микрюкова исә «72 кг кадәрге» авырлык үлчәмендә «көмеш» медаль иясе булды.





ГҮЗӘЛ АЙТИШНИКЛАР

АКЫЛЛЫ КЫЗЛАРНЫ ЕГЕТЛӘР ЯРАТМЫЙ ДИГӘН БУЛАЛАР ТАГЫН.

Фәнзилә МОСТАФИНА

Көннән-көн югарырак үрләр яулый барган IT-технологияләр өлкәсендә бизнес булдырып, өйдән чыкмый гына акча эшләү җаен тапкан гүзәл затларны кем яратмас?! «IT-парк»ның эшлекле идеяләр тормышка ашырыла торган Бизнес-инкубаторында, ир-атлардан бигрәк, үкчәле туфлиләре белән идәнгә керт-керт басып йөрүче ханым һәм туташлар күбрәк кебек тоелды миңа. Заманында «тимер ат»ны иярләгән гүзәл затлар мәгълүмати технологияләр өлкәсендә дә үз кеше булып беткәннәр икән инде.

IT-компанияләр һәм стартапларга (үсеш стадиясендә булган проектлар) уңайлы шартлар тудыру максатыннан Казанда 2009 елда IT-парк барлыкка килде. 2012 елда аның Чаллыда икенче мәйданчыгы ачылды. Биредә Дата-үзәк, бизнес-инкубатор, IT-коворкинг, конференц-сервис бар. IT-парк эшчәнлеге берничә юнәлештән тора.

■ Берсе – резидентлык. Эре IT-компанияләр IT-парк территориясендә эшли, анда аларның офислары урнашкан. Алар IT-паркның резидентлары исәплнә, үзара элемтәдә торалар.

■ Дата-үзәктә республикадагы бөтен электрон документ әйләнеше саклана. Мәсәлән, КамАЗның документациясе, бөтен официаль хатлар, кәгазьләр...

■ Бизнес-инкубаторда информацион технологияләр сферасына караган проектларга старт бирелә, тормышта кулланылырдай IT-карарлар кабул ителә. Моның өчен елга берничә тапкыр Бизнес-инкубаторда сайлап алулар уздырыла. Экспертлар, инвесторлар чакырыла. Алар иң яхшы дип табылган проектларга IT-паркның Бизнес-инкубаторында җитлегер өчен 9 ай вакыт һәм ярдәмчеләр бирелә. Теге яки бу процессны компьютерлаштыру идеясе булган һәр кеше үз проектын монда базарга чыгарырдай итеп үстерә ала. Башта ул үз программасын яза, командасын туплый, Бизнес-инкубаторга шул идеясе белән килә. Идеянең кирәклеген, эшне башкарып чыга алуларын исбатлый. Үзе һәм командасы өчен 3 эш урыны һәм юридик ярдәм алуга ирешә. Экспертлар аңа проектны бизнеска әйләндерергә, инвестицияләр табарга булышалар. Мастер-класслар, тренинглар, кызыклы кешеләр белән очрашулар яңа белем һәм тәҗрибә бирә.

■ IT-паркның Россия шәһәрләрендә стартаплар үткәрү буенча аерым проекты бар – Стартап Сабантуй. Быел ул халыкара проект буларак, Россиянең 10 шәһәреннән тыш, Сербия, Истанбул, Дубайда да узды.

■ Казанда да, Чаллыда да IT-парк уку-укыту юнәлешендә төрле эшләр алып бара. Балалар өчен робот техникасы, мультипликация буенча курслар оештыра, балалар өчен IT-лагерь эшләп килә.



■ «Кияүгә чыкканчы IT технологияләрне бар дип тә белми идем. Ирем бу «чир»не миңа да йоктырды», – телефон Алсуның көлгән тавышын китереп җиткерә. Аннары әңгәмәдәшем җитди итеп өстәп куя: «Дин кардәшләребезгә ярдәм итәсе килү теләге көчле бездә».



■ Ә менә Регина Фәсхиева тәкъдим иткән ClassFit проекты фитнес белән шөгыльләнергә яратучыларның көндәлегенә хуш киләчәк. Фитнесны да спорт төренә кертеп, дуслары алдында авыз тутырып: «Мин спорт белән дус», – диючеләр күп бит хәзер.

Мөселманнар өчен гид

Тәвәккәл ханымнар бер урында гына утырмый. «Хәләл гид» (Halal Guide) мобиль кушымтасының автордашы – Алсу Касыймова белән дә телефоннан гына элемтәгә керә алдык. Алар ире Айрат белән Мәскәүдә яшиләр, ике яшьлек кызлары Сәйдәне үстерәләр. Лаешта туып, Казан (Идел буе) федераль университетында татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлаган Алсу Мәскәүдә татар телен укыту турында хыяллана. Кирәкле курсларны белешеп тә куйган инде. Тик әлегә аңа кечкенә Сәйдә белән өйдә утырырга туры килә. Аның каруы, буш вакытын «Хәләл гид»ка багышлый ала.

– Әле без өйләнешкәнче үк ирем әлеге проект идеясе белән янып йөргән, – дип башлады сүзен Алсу. – Бервакыт Мәскәүдә намаз укырга урын таба алмаган ул. Шулчак башына: «Карале, минем кебек тилмереп эзләп йөрүчеләр күптер ул», дигән уй кергән, аларның яшәешен җиңеләйтү теләге барлыкка килгән. Гаилә коргач, иптәшемнең хыялын бергәләп тормышка ашыра башладык. 2012 елда «Хәләл гид» туды.

Мөселманнарга ярдәмлек буларак эшләнгән мобиль кушымта интерактив картадан гыйбарәт. Анда шәһәрдәге хәләл «нокталар» билгеләнгән: кибетләр, кафелар, мәчетләр, намаз уку урыннары. Ә «Хәләл гид»ның сайтында мөселманнарга кызыклы булган чаралар афишасы һәм намаз вакытларын табарга була. Россиядән кала, тагын 23 ил, барлыгы 1200 шәһәр өчен эшли ул. Касыймовларның бер дусты Франциядә дә намаз вакытларын «Хәләл гид»тан карап, гыйбадәтен вакытында кылып йөргән.

Алсу белән Айратның проектта икәү генә эшләгән чаклары артта калган. Бүген аларның зур командасы, Бизнес-инкубаторда җылы урыннары, бихисап идеяләре бар. Бүген «Хәләл гид»тан даими рәвештә 25 мең кеше файдалана инде. Ярдәм итүчеләр дә юк түгел икән. Күптән түгел Әзәрбайҗанда бер егет мобиль кушымтаны тулысынча үз телләренә күчереп чыккан! Тиздән әлеге ярдәм БДБ илләренә, Кытай һәм Япониягә дә барып җитәчәк – бу юнәлештә эш башланган инде.

IT-ның җенесе юк!


ClassFit – берьюлы берничә фитнес-клубка йөрү мөмкинлеге бирә торган универсаль абонемент. Мондый хезмәтне Казанда 40 үзәк күрсәтә. Айга билгеле бер сумманы түләп куясың да теләгән кадәр фитнеска йөрисең. Әйтик, иртән йогага, көндез биюгә, хәлең калса, кичен бассейнга да барырга мөмкинсең. Бер фитнес-клубка айга өч тапкыр гына барып була – шундый кечкенә генә чикләү бар.

Проект Санкт-Петербург белән Екатеринбургта да гамәлгә кергән. Шулай да аның таралу учагы һәм төп кулланучылары Казанда икән. Исәпләп тә чыгарганнар: универсаль абонементны алучыларның 60 проценты – яшь кызлар.

Белеме буенча җәмәгатьчелек белән элемтә белгече булган Регинадан әлеге проектка ничек килеп эләгүе турында сорашам. «Гадәттә, мин түгел, ә мине табалар», – дип елмая кыз. Гуманитар өлкә буенча укыса да, мәгълүмати технологияләр диңгезендә дә бик оста йөзә ул. Гомумән, Регина бу юнәлештә гүзәл затларның һичшиксез уңышка ирешәчәгенә ышана: «Дөньяның асты-өскә килгәнен исәпкә алсак, хатын-кызлар IT үрен дә яулый алыр».

Әлегә ClassFit командасында 6 гына кеше хезмәт куя. Табыш өчен түгел, проектны таныту өстендә эшлиләр. Киләчәктә команданы да зурайтырга, керемне дә бермә-бер арттырырга ниятлиләр.

■ Быелның 1 гыйнварына китерелгән мәгълүмат буенча, 158 компания IT-парк резидентлары булып санала, 3860 кешегә эш урыны булдырылган. Узган 2014 елда резидентларның гомуми кереме 8,7 млрд. сумны тәшкил иткән.
■ IT-парк карамагындагы Бизнес-инкубаторда бүген 55 проект тормышка ашырыла: 28 е – Казанда, 27 се – Чаллыда. Казандагы 7 проектның башлап йөрүчесе – хатын-кызлар.
■ Узган ел Чаллыда Россиядә беренче IT-йорт кулланылышка тапшырылды. Анда чит шәһәрләрдән килгән резидентлар фатир арендалап тора ала.



ДАМИРА БИТ УЛ!

АВЫЛ ХАЛКЫ ӨЧЕН УЛ ТЕРАПЕВТ ТА, ХИРУРГ ТА, ГИНЕКОЛОГ ТА... БАЛА-ЧАГА АНЫ ТИКМӘГӘ ГЕНӘ «ВРАЧ АПА» ДИП ЙӨРТМИ ИНДЕ.

Күтәрелеп килгән яшел басулар, юлның ике ягыннан безне озата барган усак-каен агачлары, чакрымнарга сузылган сирень куаклыклары... Табигатьнең җәйгә кереп барган иң гүзәл чагы хәзер. Күз иярмәс ерак-еракларга җәелгән Нократ елгасы да артта калды әнә. Мөслимгә якынлашабыз. Ике авыл арасыннан бормаланып аккан Мәллә елгасын без соңыннан күрербез.

Ә хәзергә... Ә хәзергә без иң шәп район хастаханәсенең иң шәп фельдшеры белән танышачакбыз. Бу якларга барып чыгуыбызның сәбәбе дә шул. Мөслимнең үзәк район хастаханәсе, андагы үзгәрешләр, зур яңалыклар турында ишетеп-белеп килгәнгә, иң беренче эш итеп хастаханәгә кереп чыгарга булабыз. Баш табиб Минхәт Сәфәров безне кабинетында озак тотмый. Ул, гомумән, кабинет кешесе түгел. Хан заманнарыннан калган бинаны ел эчендә әнә шулай заманча итеп, яңа җиһазлар, уңай урынлы палаталар белән шәһәрнекеннән кәттәрәк итеп эшләп куй әле! Иң яхшы хирург та диләр үзен. Аны тыңлаганда мөслимлеләр өчен куанып та куясың. Биредә УЗИ, эндоскопия үтү дә, операция дә бушлай. Бусы – баш табибның инанган сәясәте. Авыру кешедән акча сыгу дигәнне белмиләр монда.

– Хөкүмәт, спонсорлар ярдәме белән инде, – ди баш табиб, палатадан палатага хәйран калып йөрүебезне күреп. – Авылны яшәтер өчен бакча-мәктәпләр генә түгел, бөтен кирәге булган хастаханәләр, фельдшер-акушерлык пунктлары да кирәк.

Без аның белән килешәбез. Яңа фельдшер-акушерлык пунктлары бүгенге авыл кешесен куандырган могҗиза булды инде ул. «Эшкә дигәндә, фельдшерларыбыз да кимен куймый...» Баш табиб шулай ди дә, коридорга куелган урындыкларның берсендә утырып торган урта яшьләрдәге ханымга ымлап: «Әнә үзе дә...» – дип, елмаеп җибәрә.

Тойгелде табибы

Ул җәйнең үзе шикелле: яшел күлмәк, күк йөзе шикелле зәп-зәңгәр күзләр... Тойгелде халкы аның турында: «Көнебез дә, төнебез дә шул Дамира инде», – дияр. Ул безнең өчен ачылмаган, серле дөнья әлегә. Кем ул, нинди ул авыл фельдшеры, ниләр майтарып ята үзенең тынгысыз-мәшәкатьле дөньясында?! Эше нидән гыйбарәт? Хәер, эшенең нидән гыйбарәт булуын чамалыйбыз анысы. Ничек итеп, нинди шартларда менә?! Фельдшерның алыштыргысыз транспорты саналган арбалы, чаналы атлар заманы күптән инде моңсу истәлек булып артта калды. Гомер буе шушы авыр һәм җаваплы эшне үз җилкәсендә тарткан мәрхүм кайнанам белән булган хәл искә төшеп куя. Күз ачкысыз буранда 30 чакрымдагы авылга бер хатынны бәбәйләтергә алып барганда, ат ярсып китеп, чанадан төшеп калуын, адашуын, үзе дә шунда чактан гына исән калуын ул безгә һаман саен сөйләп ала торган иде. Хәзергедәй кесәңдә телефонның да юк, чакыртуга ук ялт итеп килеп җитә торган «Ашыгыч ярдәм» машинасы да юк. Заманаларны авыр дип зарлансак та, вакыт барыбер безнең ише гади халык файдасына эшли тора.

– Алайса, Тойгелдегә?! – ди үзен безнең белән Дамира Дамир кызы Баязитова дип таныштырган фельдшер ханым. Шул минуттан тулысынча без аның карамагында. Үзәктән ун чакрымдагы Тойгелде 610 лап халкы булган зур авыл икән. Шуның 118 е – унсигез яшькәчә булган балалар. Һәрхәлдә, картаюга барган бу авылда шәфкать туташына эш җитәрлек. Килә-килешли Тойгелдедән әлеге дә баягы Мәллә елгасы гына аерып торган «Игенче» авылының 2 миллион 600 мең сумга төшереп эшләткән яңа модульдәге фельдшер-акушерлык пунктын да карап чыктык. Әйе, беренче күрүебез түгел. Әмма күргәнебез барыбер тәэсирләндерә. Биредә авырулар өчен кирәк булганның бары да бар. «Мондый ФАПларга табиб кына җитми», – дип шаяртабыз. «Табибыбыз бар бит инде безнең, – диләр кайсы кан басымы үлчәтергә, кайсы укол ясатырга килгән апалар бертавыштан. – Дамира бит ул!»

Бәләкәй кыз һәм малайлар аны «врач апа» дип йөртә. «Еласаң, Дамира апаңа әйтәм, укол ясап китә хәзер үзеңә», – дип, минем белән куркыталар да әле», – дип көлә ул.

Ниятебезне белүгә, яныбызга халык җыела башлый.

Радик Гыйльфанов:

– Бервакыт битемә шеш чыкты. Дамира апа карады да, шундук диагноз куеп, дару язып бирде. «Барыбер белгечкә күрсәтеп, анализлар ясатып кайт», – дип киңәш бирде. Мин ул әйткәнчә эшләдем. Әле бер табибка керергә куштылар, әле икенчесенә. Йөри торгач, нәкъ шул Дамира апа әйткән даруга рецепт язып чыгарып җибәрделәр. Вәт шулай, белә ул, күпне белә.

Эльвира Фәйзуллина:

– Чаллыда яшәүче сеңлем өч игезәге белән авылга кайтты. Алар ул чагында икешәр айлык кына иделәр әле. Дамира гел алар янында булды. Прививка ясый, температураларын көн дә килеп үлчи, анализларын районга илтә. Аның өчен сезнеке, безнеке юк. Югыйсә читтән кайткан балалар бит. Хәзер аларга дүрт яшь. Әз генә чирли башладылармы, әни: «Кызым, Дамирага әйт әле, балалар чирли», – дип Чаллыдан шалтырата. «Шәһәреңдә табиблар беткәнмени?» – дим.

Илгизә апа Гарифуллина:

– Шулай, шулай... Былтыр җәй көне ялга кайткан оныгым авырып китте. Дамираны чакырттым. Ул килеп бер укол гына ясады, хәле шундук рәтләнде баланың».

Аның телефоны беркайчан да тынып тормый. Төн уртасында уятсалар да, чыгып йөгерергә әзер ул.

– Мактыйлар сине, Дамира...

Шулай дигәч, ул ягымлы итеп бер елмаеп кына куя. Кайчак авыруның хәл-әхвәлен сораштыру, бер җылы сүз әйтү дә җитә шул. «Син килсәң, җиңел булып китә, хәлем әйбәтләнә», – дип әйтүләре генә дә ни тора! Өйдә авыручыларның хәлен белүдән тыш та эш җитәрлек аңа. Ул көненә унике кеше кабул итәргә тиеш. Кайвакыт егермешәр кеше килә, күбрәк булган чаклары да бар. Норманы тутырдым дип утырыргамы хәзер?! Аннары... эшен бик ярата ул. Ә яраткач, вакыты да, көче дә табыла. Монысын инде Дамирадан гына сорагыз...

Эш сәгате нидән башланамы? Аның эш сәгате ятып авыручыларны караудан башлана. Тойгелде халкы да шулай дип әйтеп тора: «Эшенә барып җиткәнче, башта өйләрне

БЕЛЕШМӘ.



Республикада ел саен яңадан-яңа сәламәтлек саклау объектлары сафка баса. 2012 елда модульле ФАПлар белән беррәттән, беренче мәртәбә модульле амбулатория эшли башлады. 2013 елда модульле патологоанатомик бүлекчәләр барлыкка килде. 2015 елда гомумпрактика табиблары һәм участок педиатрлары өчен яңа микрорайон үзәкләренең беренче катларында халыкка амбулатор поликлиник ярдәм күрсәтү оештырылачак.
Яңа модульле ФАПлар төзелешенә, амбулаторияләргә, хастаханә участокларына капиталь ремонт үткәрүгә ел саен 330 миллион сум акча бүлеп бирелә. Бүгенге көндә 241 яңа модульле фельдшерлык-акушерлык пунктлары төзекләндерелде, 1128 ФАПка, 65 табиблык амбулаториясенә, 11 хастаханә участогына капиталь ремонт уздырылды. Быел 61 модульле ФАП салыначак, 7 табиблык амбулаториясенә, 5 хастаханә участогына, 237 ФАПка капиталь ремонт үткәреләчәк.





Үрнәк әни ул безнең, – ди Дамира. – Ул – авылның ветераннар советы рәисе. Әле дә булса «Рябинушка» халык ансамблендә җырлап йөри. Тик тормый, үзенә эш табып кына тора. Миңа да таба. Авыруларны, җитәкләп, өйгә алып кайтырга да мөмкин.

йөреп чыга», – ди. «Аннанмы?» Ул бераз уйланып тора. Дөресен әйткәндә, аның бер эш көне икенчесеннән әллә ни аерылып тормый. Шул ук иртәнге процедура: укол ясау, шикәрне, кан басымын үлчәү...

– Аннары, төшкә таба әниләр бәләкәчләрен чәчәк салдырырга алып килә башлыйлар, – дип аңлатырга керешә фельдшер. – Прививка ясаганда куркыта бераз.

«Авыру кеше «минеке», «синеке» була алмый. Ярдәм сорап киләләр икән, кемнең кем булуына карамастан, булышам».

Баланың төрлесе бар бит. Бер-бер хәл булса дим. Әкренләп халыкка диспансеризация, вакцинация үткәрәбез. Бәби табарга вакыты җиткән әниләрне «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, хастаханәгә озатам. Күп инде, күп эше. Районга үзебезгә беркетелгән табибка барып, дарулар яздырып кайтам. Гинекологларны, терапевтларны авылга чакырам. Шулай тиеш анысы. Әйе, көтелмәгән, гадәттән тыш хәлләр дә килеп чыгарга мөмкин. Менә тагын җәйләр килде. Кайсын корт чага да тыны кысыла башлый. Аллергия, димәк, кешедә. Кайсына талпан кадала. Кайсы кемнедер пәке белән җәрәхәтли. Сирәк булса да, андый хәлләр дә очраштыргалый. Велосипедтан балалар егыла, йә аларның башларына кызу каба.

«Үзең шулай өйрәттең, әни!»

Дамира Тойгелде авылында эшли, Михайловкада яши. Ике авыл арасы ун чакрым. Бару-кайту егерме чакрымга җыела. Дөрес, ул җәяү йөрми. «Минем такси – попутка», – дип шаярта ханым. Ире Әзһәр өйдә булганда, ул йөртә.

– Гомер буе Михайловкада яшәдек инде, – ди Дамираның әнисе Гөлҗиһан Латыйпова. – Нинди генә милләт халкы яшәми бездә: урысы, татары, удмурты, белорусы, мукшысы... Ирем Баланлы авылыннан минем. Заманында без шуннан күченеп килдек. Табиблар, авырга узгач, гел малай була, диделәр. «Менә ни өчен гомерем буе хәрби булырга хыялланганмын мин, – дип кыстырып куя Дамира. – Малай көткәнгә!»

– Малай булмаса да, ул холкы-кыяфәте белән гел әтисе, – дип дәвам итә Гөлҗиһан апа. – Ирем дә кешегә бик ярдәмчел иде. Кызганыч, 38 яшендә вафат булды. Әйе, бик иртә китеп барды. Миңа да ул чагында 36 гына иде. Ике бала белән утырып калдым шулай. Башка кияүгә чыкмадым. Сорамадылар дип әйтә алмыйм. Сорап килделәр. Әмма мин чыкмадым. Балаларымны кагарлар дип курыктым. Андый хәлләрне дә күргән кеше мин.

Алар бүген бергә – зур-тату гаилә булып яши. «Иртән кайсы кая таралыша, – ди әниләре. – Улым Данияр белән киявем Әзһәр Әлмәткә чыгып китә. Алар шунда эшли. Дамира – Тойгелдегә. Улымның малайлары – оныкларым – мәктәптә. Мин алар өчен әни дә, әби дә...»

– Әниләре бардыр ич...

– Бар, әмма ул аларны ташлап чыгып китте. Суд карары белән балалар бездә калды. Кайчандыр киленне әнисе ташлаган, хәзер менә монысы шулай. Килми дә, балаларының хәлен дә белешми. Аңа, миңа калса, барыбер. Андый әнинең булуыннан булмавы хәерлерәк, бер уйласаң. Ә малайлар алар үсә, икесе дә әйбәт укый. Әниләре исләренә дә керми. Аңлыйлар бугай.

«Үземнеке, үз оныкларым», – ди Гөлҗиһан апа. Апасы үлеп, ике кызын тәрбиягә алганда да «үземнекеләр» дигән ул. Ятим булмасыннар дигән. Алай дисәң, мөслимләләр үз туганыныкын түгел, чит баланы да үземнеке дип үстерә.

– Михайловканың үз фельдшеры бар барын, – ди кызының сүзен җөпләгәндәй итеп әнисе. – Тик аның телефоны гел сүнгән була. Шуңа Дамирага шалтыраталар. Минем авырулар түгел, дип тормый. Ял көне буламы, төн уртасымы – чыгып

йөгерә. Ярый әле шундый чакларда кияү булыша.

– «Инде машинага Кызыл хач гына куясы калды», – дип әйтә ул, әни... – Без көлешеп алабыз. – Әзһәр шундый булмаса, бу эштә эшли дә алмас идем. Ул миңа нык ярдәм итә. Гозерләп килгән кешене кире борырга ярамый диде ич, әни!

«Матурым!» дип кенә дәшә

– Ирем миңа исемем белән дә дәшми. «Матурым» гына ди. Чирек гасыр яшәп, ачуланышканны, үпкәләшкәнне хәтерләмим. Вак-төяге тиз онытыла. Без икебез дә тиз кайтып төшүчән, көннәр, атналар буе бер-беребезгә үпкә саклап йөрмибез. Балалар да шундый тәрбия алып үсте. Улыбыз Динар Чаллыда яши. Киленебез Регина белән алар икесе дә – мал табиблары. Икесе дә Казанда ветеринария академиясен тәмамлады. Без Әзһәр белән – әби белән бабай булдык инде.

Ул, үткәненә кайтып, үзенең урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, авылда калмас өчен, шәһәргә китеп, медицина көллиятенә укырга керүен, шәфкать туташы белгечлеге алып, Михайловкага кайтуга, аны бераздан янә лаборантлыкка укырга җибәрүләрен, укып кайткач, 20 елга якын үзен шул һөнәргә багышлавын һәм, ниһаять, хастаханә участогы ябылганнан соң, Тойгелдегә фельдшер булып килүен исенә төшереп ала.

– Җәйге ял вакытларында кайда буласыз? – дигән соравыбызга Дамира Баязитова: «Авылдан беркая чыгып китәсе килми, без гел өйдә, бакчада», – дип җавап бирә.

«Авылда калмас өчен» дип башланган гамәл аны мәңгегә туган туфрагына бәйләп куйган. Монда барысы да кадерле-якын аның өчен: әнисе, ире, балалары, көн дә бер зары белән килгән абый-апалары, әби-бабайлары, хәтта борын канатып кергән шук малайларына кадәр кадерле. Авылдашлары аның хакында: «Гомере генә булсын. Ходай биргән аны безгә», – диләр. Хезмәтеңә иң зур, иң олы бәя шул түгелме?!

Мәдинә КАШАПОВА.
Фото: Алинә Батыргәрәева.



ҮЗГӘРЕШЛӘР АЛГА ИЛТӘ

Мөслим үзәк район хастаханәсе баш табибы Минхәт СӘФӘРОВ:

– Хастаханә бинасына салып куйганнан бирле бер генә мәртәбә дә капиталь ремонтның үткәрелгәне булмаган. Без бу эшләрне былтырның февраль аенда башлап җибәргән идек. Ә инде быелның мартында төзекләндерү эшләрен төгәлләп тә куйдык. Хөкүмәтебез моңа 50 миллион сум акча бүлеп бирде. Ремонт барганда авыруларны кабул итүне, дәвалауны бер генә көнгә дә туктатып тормадык. Пациентларга уңайлыклар тудыру өчен барын да эшләдек. Стационарда моңарчы булмаган физиотерапия кабинеты, Бөек Җиңү уңаеннан ветераннарга яңа җиһазлар куелган палаталар ачтык. Хастаханәгә районыбыз эшмәкәрләре ярдәме белән ФГДС үткәрү аппараты, УЗИ кайтарттык. Гомумән, диагностика кую һәм авыруларны дәвалау өчен дистәләгән яңа медицина аппаратлары алдык. Без 21 меңләп кешегә хезмәт күрсәтәбез. Ел саен стационарда 5,5 мең кеше дәвалана. Ел дәвамында 660 лап кешегә операция ясала. Коллективта үз эшенә бирелгән белгечләр эшли: 41 табибыбыз, 181 шәфкать туташыбыз, 46 санитаркабыз бар.
Яшь белгечләрне авыл җирләренә эшкә кайтару максатында эшли башлаган программа ярдәмендә соңгы өч елда гына да коллективка 7 яшь белгеч килде. 14 кешегә йорт җиткерү, фатир сатып алу өчен шушы программа нигезендә берешәр миллион сум акча бирелде. Башка регионнардан килгән белгечләргә дә 500 мең сум акча каралган.
Районда 53 фельдшер-акушерлык пункты эшли. Соңгы дүрт елда алты яңа модульдәге пункт ачтык. Аларның кайсылары хәзергә мәктәп, кайсылары мәдәният йорты бинасында урнашкан. Тик без аларны әкренләп яңага алыштырачакбыз. Бүгенге көндә бу максатка 20 миллион сум акча тотылды. Соңгы елларда авыл халкына медицина хезмәте күрсәтүне тагын да яхшырту өчен күп эшләнә. Татарстанда югары технологияле медицина булган өч үзәк бар: Казанда, Әлмәттә һәм Чаллыда. Без Чаллы үзәге белән эшлибез. Баш мие имгәнүләре, баш мие үзгәрешләре, инфаркт булганда, пациентларыбызны шунда күчерәбез. Ә калганын үзебез дә булдырабыз аны.











Асия ЮНЫСОВА

БЕРГӘЛЕК!

МАЙ АХЫРЫНДА ТӨРКИ ДӨНЬЯ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ КАЗАНДА ИКЕНЧЕ КОРЫЛТАЙДА ОЧРАШТЫ.

Корылтай кунаклары бер-берләренең мәдәнияте белән якыннанрак танышу максатыннан, Казан Кремлен, Зөя утравын, Шәһри Болгардагы изге урыннарны карап кайттылар, КФУда галим Мирза Казыймбәккә истәлек тактасы куюда катнаштылар.

Бу очрашу гади генә кунак төшерү түгел иде. Төрки дөнья журналистлары монннан ике ел элек Төркиянең Иске Шәһәрендә беренче корылтайларында очрашканнар иде инде. Менә шул чагында алар икенче очрашу Казанда булыр дип килештеләр. Елдан-ел матурлана барган шәһәребезнең даны ымсындырган икән аларны. Андый ният барын белгәч, Татарстан җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов бу кайтавазлы гамәлгә һәртөрле ярдәм булачагын вәгъдә итте һәм сүзендә торды.

Дөньяның 18 иленнән килгән 50 кунак – Төркия, Англия, Гыйрак, Нидерланд, Сүрия, Молдова, Румыния, Болгария, Греция, Иран, Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кипр, Венгрия (саныйсы да саныйсы килеп тора) арасында әле Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникованың, «Татмедиа» Республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зариповның катнашуы җыенны тагын да дәрәҗәле итте.

Каләм ияләре өйләренә фәкать уңай тәэсирләр генә алып китәрлек итеп оештырылган иде корылтай. Әмма иң мөһиме – сөйләшү тирән мәгънәле, нәтиҗәле булырга тиеш! Журналист халкы күп йөри, күп белә һәм бик тә гамьле халык. Шуңа күрә Татарстан ягыннан сүз алып, икенче корылтайны ачып җибәргән җитәкчеләребез, биредә җыелган эш кешеләренең тугандаш халыклар булуына, төркиләрнең уртак тарихына басым ясап, зур сөйләшүгә юнәлеш бирергә тырыштылар. Корылтайда төрки дәүләтләрнең вазыйфаи шәхесләре – Төрки дөнья муниципалитетлары берләшмәсе генераль секретаре Фәхри Сулак, Әзәрбайҗан Матбугат шурасы җитәкчесе Әфләтун Амаш, Төрки дөнья журналистлар берлеге рәисе Шәмсетдин Күсеҗе, Төркиянең Татарстандагы консулы Турхан Дилмач кебек дәрәҗәле кунаклар катнашты.

Корылтайга юнәлешне исә моннан йөз ел элек үк мәшһүр Исмәгыйль Гаспралы биргән иде. Аның: «Телдә, фикердә, диндә бергәлек!» дигән шигаре корылтайның да шигаренә әверелде. Әле безнең үз максатыбыз да бар иде. Ул да булса, Татарстан Республикасын дөньяда тагын да ныграк таныту. Бу җәһәттән журналистларны илче дип әйт-









Фото: Солтан Исхаков

сәң дә була. Бүген Казанда күргән чын дөреслекне иртәгә Иранда яки Кипрда кайтып сөйләячәк илчеләр безгә бик кирәк. Эшләү бер нәрсә, эшләгәнеңне күрсәтә белү дә кирәк. Галимнәребез Индус Таһиров, Рафаэль Хәкимов, Васил Гарифуллин чыгышлары Татарстанның мәгълүмат дөньясын 110 еллык юлы барлыгын искәртте.

Корылтайга килгән кунаклар арасында төрки дөнья өчен мәртәбәле исемнәр шактый яңгырады. Без аларның кайберләрен шәрәфле Президиумда да күрдек. Халыкара төрки телле журналистлар ассоциациясенең президенты Мәндәрәс Демир (Тимер), аның ярдәмчесе Исмаил Каһраман, идарә әгъзалары – Окан Чалышкан, Нәҗми Пишкин Төрки дөнья журналистлары федерациясенең төп максатын бәян иткәннән соңра иң нык эстәгән хыялларын да ачып салдылар. Төрки дөнья журналистларының бердәм «Хәбәр үзәге»н булдырып, үзара отышлы шартларда хәбәрләр алмашуны оештырсак иде, диде алар. Хәбәрләр генә түгел, бәлки, технологияләр, тәҗрибә алмашу да мөмкин булыр иде. Әйе, максатлар бар, һәм алар уртак, әмма менә кайчандыр төрки дөньяда аралашу теле булган татар теле позицияләрен бирә бара. Төрек теле дә һәммә җирдә дә тамыр җибәрә алмады. Корылтай утырышларында әле рус, әле төрек теленә өстенлек бирелү, ә татар теленең икенче планга күчә баруы күңелдә борчылу уятты. Мөгаен, алга таба, гомумән дә, инглиз теле төп аралашу теле булып китәр. Чөнки динебез уртак булганга күрә төркиләргә тартылган Иран, Гарәп илләре халыклары өчен төрки телләр аңлаешсыз.

Димәк, Корылтай Декларациясендә игълан ителгәнчә, медиа-аралашу үзәге булдыру уртак аралашу теле булдыруны да зарур итәчәк. Исмәгыйль Гаспралының өч нәрсәне – телне, динне, фикер бердәмлеген шарт итеп куюында никадәр алдан күрүчәнлек булган. Төрки дөнья янәдән шундый бер Гаспралыга, шундый бер «Тәрҗеман» «газетасы»на мохтаҗ. Бу җәһәттән, хыялдагы бердәм гаммәви мәгълүмат агентлыгы – «Хәбәр үзәге» көн саен 100 яңалык, 50 фотосурәт, һәм 10 видео биреп барып, төрки дөньяны әйбәт кенә яктырта алыр иде. Бер-береңнең уй-ниятләрен белү, аңлау өчен хәбәрдарлык бик тә кирәк шул.

Фойеда урнаштырылган күргәзмә мәгълүмат армиясенең никадәр куәтле булуын раслады. Аннары матбугат елъязмасы тегеге яки бу илнең үсеш адымнарын ачык күзалларга да ярдәм итә. Әйтик, «Аваз» ТРТ вәкиле Мурат Аккоч Татарстанның соңгы ун елда бик нык алга китүен шатланып хәбәр итте. Бу газета-журналларыбыздан да күренә. «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтовның горурлыгы аңлашыла – эчтәлек ягыннан да, сыйфат ягыннан да безнең басмаларыбыз бер дә ким түгел!

Корылтай 14 маддәдән торган Резолюция кабул итте. Аерым алганда, анда Төркия телеканалы нигезендә бердәм мәгълүмати канал яки агентлык булдыру, моның өчен уртак алфавит эшләү; сүз иреген тәэмин итү; Татарстан белән Төркия журналистларының уртак корылтаен үткәрү каралды. Төрки дөньяның яшь журналистлары берлеге оешу турында игълан ителде. Һәм корылтайда катнашучыларның кайберләре аңа әгъза итеп алынды.

Мәндәрәс Демир быел корылтайны үзендә кабул иткән Татарстанга, чараны югары дәрәҗәдә оештыруга зур өлеш керткән «Татмедиа» агентлыгына рәхмәт белдерде. Корылтайның төп максаты, төрки дөнья журналистларын берләштерүдән тыш, иң беренче чиратта, – халыкка хезмәт итү. «Журналист хезмәтенең төп асылы да шунда», – диде ул.











Фото: Шамил Абдюшев, Булат Ибраһимов

ЧӘКЧӘК ҖЫЕНЫ

(*Ахыры. Башы журналыбызның 2015 елның 5 нче санында.*)



Лилия ГӘРӘЕВА

«ТӘМЛЕ ҖЫЕН»НЫҢ ИКЕНЧЕ КӨНЕ. БҮГЕН ӨЛЕШ, ПӘХЛӘВӘ, ТУТЫРГАН ТАВЫК ҺӘМ ТАГЫН ИКЕ ТӨРЛЕ ГӨБӘДИЯ ПЕШЕРЕРГӘ ӨЙРӘТӘЧӘКЛӘР. ГӨБӘДИЯ ӨЧЕН КОРТ ТА КАЙНАТЫРБЫЗ.

Пәхләвә һәм өлеш пешерү серен «Хөррият» кафесында эшләүче **Резеда АРСЛАНОВА** ача.

Пәхләвә

45-50 данә өчен ярты литр сөткә аз гына шикәр комы, тоз, 4 йомырка, бик аз гына коры чүпрә салып, камыр басабыз. Китаплардагы рецепт буенча, ул каты булырга тиеш, һәм чүпрә дә салынмый. Резеда ханым чүпрәне йомшаклык өчен сала, камырны да артык каты итеп басмый.

Болардан тыш, 350 г сары май, 600 г чистартылган әстерхан чикләвеге, 300 г шикәр комы һәм 600 г бал да кирәк. Вакланган чикләвекне коры табада кыздырып, шикәр комы белән катнаштырып әзерләп куябыз.

Камырны үзләнгәнче баскач, 7-8 өлешкә бүләбез. Бер өлешне зуррак итәбез. Анысы – пәхләвәнең беренче катына. Беренче катны таба читенә чыгып калырлык итеп җәябез. Ул юка булырга тиеш.

Зур табаны майлап, беренче җәймәне салабыз. Камыр өстенә 3 аш кашыгы эретелгән сары май, аннан соң шикәрле чикләвек сибелә. Камырның калган өлешләре нәкъ таба үлчәмендә җәелә. Һәрбер катлам арасына май белән чикләвек сибелә. Соңгы катын салгач, табадан чыгып калган камырны пәхләвә өстенә кайтарып салабыз. Иң өскә май белән чикләвек сибәбез һәм 10 минут-

ка 200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз. Мичтән алгач, пәхләвәне пычак очы белән кыек шакмаклап кисеп чыгабыз. Иң аскы катын кисмәскә кирәк, бал таба төбенә агып чыкмасын. Балны эретеп, шакмак араларына агызабыз да, кабат мичкә тыгып, өсте кызарганчы тотабыз. Мичтән алып, пычак эзе буйлап тагын бер кат кисәбез һәм янә бал агызабыз.

Өлеш пешерү

1 кап маргарин яки акмайны он белән уабыз. Шуңа 2 йомырка сытып, барысын бергә туглыйбыз.

Ул арада 1 стакан сөткә бер чеметем тоз, 1 уч шикәр комы һәм бик аз гына чүпрә салып (кипкәне дә ярый), чүпрәгә чак кына «җан кертеп» алабыз. Он белән уылган май янына шушы сөтне һәм 200 г кибет каймагын салып, йомшак кына итеп камыр басабыз. Камыр ярты сәгать чамасы «ял иткән» арада, өлешнең эчлеген ясыйк. Тавык түшен, бәрәңге белән суганны ваклап турыйбыз. Коры булмасын өчен, бераз гына акмай кушабыз. Өлеш бәлеш рәвешендә ясала. Аскы ягына – 60 г, капкачына 10 г камыр алына.

Өйләдән соң мастер-классларны «Тәмле булсын» ресторанында дәвам итәбез. Аш-су дәресен ресторанның хуҗабикәсе **Резеда ХӨСӘЕНОВА** үзе үткәрә. Күпләргә ул «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалындагы «Тәмле булсын» сәхифәсенең авторы буларак та таныш.

Резеда ханым иң элек безне корт ясарга өйрәтте.

1 кг корт ясау өчен: 1 кг эремчек, 1 л сөт, 500 г кибет каймагы, 1 аш кашыгы үсемлек мае, 1 литр кибет катыгы кирәк.

Кәстрүлгә бер-бер артлы сөт, эремчек, катык, каймак, май салып, көчле утка кайнатырга куябыз. Кайнап чыккач, сүрән утта 5-6 сәгать тотабыз. Болгатмыйбыз. Корт кызара башлагач, шикәр комы өстибез. Шикәр комын һәр кеше үзе теләгәнчә өсти. Корт куе каймак рәвешенә кергәч, табага бушатып, мичкә тыгабыз. Максатыбыз – кортны бераз кипшертү.

Корт әзер, инде гөбәдиягә керешсәк тә була. Резеда ханым рецепты белән әзерләнгән гөбәдия бик тәмле булырга охшаган. Ресторанга килгән кунакларга да шушы рецепт белән пешкән гөбәдияне чыгаралар икән.

Ярты литр сөтне җылытып, 50 г шикәр комы, 10 г чүпрә, тәменчә тоз, 2 йомырка, 200 г эреткән маргарин яки акмай салабыз. Он белән изгәч, 100 г үсемлек мае салып, камырны яхшылап басып бетерәбез. Камырның кабарганын көтәргә кирәк түгел. Шушы камырдан өч таба гөбәдия чыга.

Уртача зурлыктагы гөбәдиянең төбенә – 350 г, капкачына 150 г камыр алына. Гөбәдиянең төбен табадан чыгып калырлык итеп җәябез.

Бер гөбәдиягә 350 г корт салына. Аның өстенә, тәм өчен, 2 аш кашыгы шикәр комы сибәбез.

300 г дөгене юып, кайнап торган тозлы суда бөрттереп алабыз. Бөрткән дөгене чиста салкын су белән бик яхшылап чайкатабыз. Дөгенең ятрысын корт өстенә салып, калган яртысына 200 г юылган йөзем җимеше кушып болгатабыз һәм дөге өстенә түшибез. Дүрт җиргә берәр каражимеш төртәбез. Йөзем өстенә 4 йомырка уып салабыз, аз гына тоз сибеп җибәрәбез. 250 г акмайны эретеп, гөбәдия өстенә сибәбез. Гөбәдиянең эчлеген салып бетергәч, Резеда ханым кулына уклау алды. Нишләр икән, дисәк, уклау белән таба өстеннән тәгәрәтеп, таба читеннән салынып торган камырны кисеп төшерде. Күп кеше бу артык камырны гөбәдияне бөргән чакта яшереп бетерә. Дөреслектә, менә ничек кирәк икән! Гөбәдия өстенә сибү өчен 5-6 г акмай, он һәм шикәр комыннан валчык ясала.

Бәләкәй гөбәдияне дә шушы рецепт белән пешерәләр. Кунак табыны өчен кулай икән ул.

Кечкенә гөбәдиянең астына – 60 г, өстенә 10 г камыр җитә. Корт 25 г алына. Дөгене йөзем һәм май белән болгатабыз. 1 йомырканы 4 гөбәдиягә җиткерәбез. Бәлеш кебек үк ясап, капкачына валчык сибәбез.

Гөбәдиянең өсте тигез булып пешсен өчен, майны эретеп салырга кирәк.

Гөбәдияне мичкә «озаткач», чират тутырган тавыкка да җитте. Тутырган тавык хакында ишеткән булсак та, моңа кадәр авыз иткән юк иде әле. Аны Резеда ханым «Тәмле булсын» ресторанының шеф повары **Айрат ХӨСНЕТДИНОВ** белән бергәләп пешерде.

Авыл тавыгы тутырыр өчен яраклы түгел икән. Сәбәбе – тавыкның йонын йолкыганда, кайнар су белән тиресе пешкән була, ертылып китә. Хәер, пар өстендә тотып пешекләнсә, авыл тавыгын да тутырырга мөмкин.

Кибеттән алганда да, тавыкның муенлысын сайлап алырга кирәк, җеп белән бәйләрлек җире булсын! Артык зур тавык та ярамый. 1,5 килолысы бик җиткән.

Юып, чистартылган тавыкның тире астына кашык сабын тыгып, сак кына тирене иттән аерабыз. Муенын җеп белән кысып бәйлибез.

1 тавыкны тутыру өчен 4 йомырка кирәк булачак. Йомырканы савытка сытып, ваклап туралган укроп кушабыз, тоз-борыч сибәбез. Барысын бергә яхшылап туглыйбыз. (Укроп урынына лимон кабыгын кырып салсаң да тәмле була.) Йомыркага 100 г сөт, 1-2 аш кашыгы үсемлек мае салына. Барысын бергә болгатып, бүрәнкә аша тавыкның тиресе белән ите арасына агызабыз. «Тәмле булсын»да бер серне ачтылар. Алар тавыкны корсак ягыннан тутыралар. Тутырып бетергәч, корсак куышлыгын җеп белән тегеп, йә булмаса, агач таякчыклар белән кадап куясы. Эчлеге агып чыгарлык булмасын.

Тавыкны чиста марляга төреп, кайнап торган суга тыгып пешерәбез (аяклары өскә карап торсын!). Ул сәгать ярымнан әзер була. Кайнар килеш тавыкны кисүе бик кыен, шуңа күрә чак кына суынганын көтәргә кирәк. Табынга чыгарганда исә кайнарлатып алалар.

Ике көнгә сузылган мастер-класслар шуның белән тәмам. Әлегә саубуллашмыйбыз. Киләчәктә безнә тагын бер кызыклы чара – читек чигү эшенә багышланган яңа мастер-класслар көтә.

ТҮРЛӘМӘ, ТӘРӘЗ АРАЛАРЫ, КАШАГАЛАР, ӨЛЕНГЕЛӘР, КАРАВАТ ЯПМАЛАРЫ, МЕНДӘР ТЫШЛАРЫ, СӨЛГЕЛӘР...

Рәүфә үскәндә әнисенең бирнә сандыгы белән килгән хәзинәләре бар да исән була әле. Авыл өенең күрке, матурлыгы, яме...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

ЧИГҮЛЕ ЮЛ

«Тыныч тормыш, якты киләчәк! 1964 ел.» дип, төсле җепләр белән чиккән тәрәз арасы бигрәк тә истә калган. Әнисенең килен булып төшкән елы бу. Буй җиткән кызның үз-үзенә, булачак гаиләсенә теләгән теләкләре, өметләре, хыяллары чигелгән булгандыр ак бүзгә. Яшь килен ул чигүләрне килгән нигезенең бүрәнә ярыкларын яшерү өчен генә элмәгәндер...

Вакыт бернәрсәне дә аямый. Тик әнисе чиккән мендәр тышлары, сөлгеләрнең төсләре юа-юа уңса да, мәңге тузмас кебек тоелган бүзләр сизерәсә дә, алар әле дә бар! Дөрес, Түбән Кама районының Түбән Уратма авылындагы төп нигез бүген буш инде. Әнисенең чиккән әйберләре төенчеккә төйнәп куелган. «Оста чигүче булган әнкәй! Мич өсләре, почмак яклар, ишек башлары бар да түрләмә белән капланган иде. Шуларның һәммәсен авыл музеена – Имәнлебашка алып кайтып тапшырмакчы булам», – ди Рәүфә.

Музей дип... Чигүне, чиккән әйберләрне бөтенләй музей түренә үк кертеп куярга иртәрәк бугай әле. Рәүфә әнә соңгы вакытта алган заказларын саный:

– Биш өстәл япкычы сораганнар иде... Берсе генә әзер, тагын дүртне чигәсем бар. Күрше авылдан – Аксардан: «Җиткән кызыбыз бар, мендәр тышы чигәрсең әле», – дип әйтеп киттеләр. Ашыгыч димәделәр диюен. Шепкәдән берәүләр: «Сөлге кирәк», – дигәннәр иде. Эшсез торганым юк минем – вакыт җиткерә алмыйм!

Чигәргә ярату аңа, әлбәттә, әнисеннән күчкән. Кая барса да, үзе дә сизмәстән, чигү үрнәкләре эзли башлый һәм гел көтмәгән җирләрдә таба да аларны Рәүфә: кемнеңдер тәрәзәгә элгән челтәрендә, юрган тышларында, тукымаларда... Обойдагы бизәкләрнең мендәргә төрле төсләр белән күчкән чаклары да бар. Аннан, әлбәттә, интернет ярдәмгә килә.

– Без укыганда мәктәптә дә чигәргә өйрәтәләр иде бит әле. Тирә-күрше егетләрне, классташларны армиягә озатканда кулъяулык чигеп бирү гадәте бар иде. Без дә чиктек... Ә алъяпкычларга тотынганга әле ун ел гына. Башта, билгеле, үзем өчен генә тегеп, чигеп карадым. Имәнлебашка килен булып төшкәч, алъяпкычларны «Җәүһәр» ансамбленә йөрүчеләргә чигеп бирдем. Безнең авыл элек-электән җыр-бию яраткан. Кайнатам да клубта эшләгән, спектакльләр куеп йөргән. Ирем дә спектакльләрдә уйнады. Клуб хезмәткәре булгач, мин дә шул чараларның эчендә кайныйм... Буш вакытларымда исә кулымда гел чигү. Бер кешегә нидер чигеп бирсәң, аннан күреп икенчесе сорый, өченчесе... Кемгә нәрсә чиккәнне кайдан хәтерләп бетерәсең? Иш янына куш булыр дим дә, берәүгә дә каршы килмим.

Хәтерләмим дисә дә... Авылдашы Нәҗия апаның Түбән Кама районы Түбән Чаллы авылында яшәүче туга-

ны: «Тәрәзә өленгеләре кирәк иде», – дип мөрәҗәгать итә. Биш тәрәзәгә биш пар өленгә чигә Рәүфә. Авыл өйләре шәһәрнекеннән аерылмый хәзер – мондый заказны көн саен бирмиләр: өленгеләр чиктергән ул хуҗабикә шуңа истә калган. Шәһәрнеке дигәннән, өстәл япкычларын иң күп сораучылар кала халкы икән. Заманча техника белән шыплап тулган кухняларда Рәүфәнең чәчәкле япкычларын күз алдына китерәм... Тамырлар беребезне дә үзеннән ерак җибәрми!

Үзе чиккән алъяпкычларның санын белми Рәүфә. Әмма күрше авылдан – Югары Шепкәдән Флюра апаның ничә алъяпкыч алуын онытмый ул. Абыстай ике ел рәттән Үзбәкстанга кунакка барган, һәр баруында күчтәнәчкә 6-7 алъяпкыч алып киткән.

Шәһәр мәктәпләрендә эшләүче авылдашлары, якташлары, аларның таныш-белешләре Рәүфәдән чиктереп алган сөлге, кулъяулык, ашъяулыкларны саный китсәң-ме?! Аларны күреп, күпме укучы халкыбызның буыннан-буынга күчеп килгән кул эшләренә сокланган-дыр...

Ә мендәр тышлары... Аларын сорап күбрәк әниләр килә: «Кызым буй җитте... Мендәр тышлары кирәк булыр инде, Рәүфә! Кияүгә чыгам дисә, әзер торсын». Хәер, дәү әниләр-әбиләр дә оныкларының никах туена күбрәк пар мендәр бүләк итә. Быел кышны гына да өч-дүрт әбигә мендәр тышлары чигеп биргән Рәүфә. Кызларыма, киленнәремә, дип, Фатыйма апа өч пар мендәр тышы, алты алъяпкыч алган. Гайшә апа да: «Балаларга миннән истәлек булыр», – дип алъяпкычлар, мендәр тышлары чиктергән.

«Бер пар мендәр тышы чигү өчен ике атна вакыт кирәк, – ди Рәүфә. – Дөрес, ныгытып тотынсаң, бер атнада да чигәргә мөмкин. Мин бит кичләрен генә утырам. Кайсы вакыт башлаган чигүең белән шулкадәр мавыгып китәсең, ашка бәрәңге кырып салып, аның пешкәнен көткән арада да, бер яфрак булса да чигеп куясың. Кызыклы китап укый башлагач, тизрәк азагына җитәсе килә бит, бу да шуның кебек. Ә кичен, телевизор караганда кул буш торса, бөтенләй рәхәт түгел».

Чигүчегә килгән халык артык сайланып тормый, миңа шундый-шундый чәчәкләр төшер, күбрәк шундыйрак төсләр куш, дими. Мендәр тышларының үлчәмен генә әйтә дә... Калганы барысы да Рәүфәнең үз ихтыярында. Мендәр тышлары өчен күбрәк роза чәчәкләре матур, ди ул. Чәчәкләрне башта Рәүфә клеенкага төшерә, аннан – мендәр тышына. Пар чәчәк чигәсе булганда гел шулай: тигез китереп чыгарып булмас дип, кулдан ясарга җөрьәт итми. Ә алъяпкычларда чәчәкләр берәм-берәм генә чигелә, анда кулдан ясарга да мөмкин.

Ә төсләргә килгәндә, аның үзенә зәңгәрсу төсләр күбрәк ошый. Халык исә чекерәеп, кычкырып – «менә мин» дип торган төсләрне ярата.

– Әнкәй гел әйтә, элек бер мулинедә төрле-төрле төсләр булган. Чәчәкләр шуңа матуррак чыккан. Хәзер сатуда андый мулине бөтенләй юк.

Чигү җепләре турында сүз – аерым. «Бүгенге мулинеләргә ышану кыен», – ди Рәүфә. Чөнки кибетләрдә буялган мулине еш очрый икән. Ялгыш андыйга тап булсаң, күз нурларыңны түгеп, ничәмә-ничә төннәр утырган хезмәтең юкка чыгып куярга да мөмкин. Рәүфә дә шуңа күрә күбрәк чигү җебе өчен йон шәлләрне сүтә. Беренчедән, шәл җебенең төсе чыкмый – ул яктан җаның тыныч. Икенчедән, шәл җебе белән чиккәндә бигрәк тә мендәр тышындагы чәчәкләр матуррак килеп чыга, кабарып тора. Аннан шәл җебе кебек җете мулинеләрне табу да бик кыен. Дөрес, мулинедән бөтенләй баш тартмый ул, аны да катыштыра. Мулине – нечкә, ул чигешкә нәфислек өсти.

– Мин кая барсам да, гел шәлләр карап йөрим. Безнең әбиләр аның ниндиен генә бәйләми?! Төсләренә кызыгып, сорап, салдырып аласы килгән чаклар бар... Базарда мондый шәлләр гел булмый – тиз алып бетерәләр. Хәзер чигү белән шөгыльләнүчеләр аз дисәк тә, шәл дип барсаң, базарда сатучының сиңа иң беренче соравы: «Нәрсәгә кирәк? Чигәргәме?» – була.

Чигү тынычландыра, җанга рәхәтлек бирә. Кәефсез чагыңда борчуларыңны оныттыра.

Килгән-килгән бәяләрне дә белеп китәсе килә, билгеле... Бер пар мендәр тышын моңарчы Рәүфә 700-800 сумга саткан, материаллар кыйммәтләнгәч, әле яңа гына аның хакын 900-1000 сумга күтәргән. (Кама Аланында, мәсәлән, мендәр тышлары күптән мең ярым-ике мең сум икән инде). Алъяпкыч, өстәл япкычлар чиктерү 400 сумга төшә. Җебен дә, тукымасын да үзе сатып ала – бүзнең иң яхшысын, калынын, кыйммәтлесен сайлый. Тегүен дә үзе тегә. Бер төн эчендә бер өстәл япкычы чигеп бетергәне бар, ә мендәр тышын берничек тә алай ашыгып өлгертеп булмый. Чигүне кулына, әлбәттә, кышын күбрәк ала: бәрәңгеләр алгач тотына һәм майда гына туктый. Тоташ ике сәгать чиккәннән соң, ял итеп алырга тырыша: югыйсә бертөсле утырганлыктан гәүдә авырта, гел текәлеп эшләгәнлектән күзләр арый. Түземлелегең булмаса, чигүгә тотына алмыйсың!

– Кызыңа, Гөлиягә дигән мендәр тышларың әзердер инде, Рәүфә? – дим.

Ә ул соравыма сорау белән көлеп җавап бирә:

– Читекченең читеге булганын күргәнегез бармыни? – Аннан җитди итеп дәвам итә: – Әллә күңелемә бик ошаган чәчәк үрнәге очраганы юк инде... Әйе, шулайдыр, кызыма дигән, янып торган чәчәк әле табылмагандыр. Гөлия яшь бит, унҗидедә генә, бәлки шуңа ашыкмыймдыр. Үзенең дә чигәргә бик теләге бар. Абыйсы Нәфис армиягә киткәндә аңа кулъяулык чигеп бирде.

Рәүфә Гәрәеваның мәдәният йортында оештырган «Чигүчеләр» түгәрәгенә дә күбрәк мәктәп балалары йөри. Өйрәнсеннәр! Килен төшәсе өйләргә иң элек шау чәчәкле пар мендәрләр керсен, туй көнне аш-су тирәсендә кайнашкан җиңгиләр бүләккә чиккән алъяпкыч алсын, бала-чага чиккән кулъяулыкка куансын...

Зәй районы.

Фото: Энҗе Әхмәтҗанова



АК ГӨЛЛӘРДӘ – ҖАН ҖЫЛЫСЫ...

60 НЧЫ ЕЛЛАР. ХИСЛӘР – ИХЛАС, ЯРАТУЛАР – ЧЫН, ТАБИБЛАР – ДӨНЬЯНЫҢ ИҢ СОКЛАНГЫЧ КЕШЕЛӘРЕ. АЛАР – ИЛАҺИ ЗАТЛАР, АЛАРДАН ҖЫЛЫЛЫК, ЯКТЫ НУР БӨРКЕЛӘ...

Эльмира ЗАКИРОВА

Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын бер тынга кабул итәләр шулай. Медицина дөньясы, авырулар алдында тирән җаваплылык, Гөлшәһидә–Мансур мөнәсәбәтләре, романтика, хыял, эчкерсез мәхәббәт... Вакыйгалар эчендә кайнап, әсәр геройлары белән яшәп, күпләр шул тормышны идеал итеп тоя башлый хәтта. «Ак чәчәкләр» тәэсирендә күпме яшьләр 70 нче елларда медицина институтын сайлый! Күпме кызлар Гөлшәһидә кебек булырга хыяллана! Аларның үз Мансурларын очратасы килә! Казанга укырга килү белән Федосеев дамбасын, Фукс бакчасын эзләп чабулар, Гөлшәһидәнең прототибы кем икән дип кызыксынулар, Габдрахман Әпсәләмовның үзен күрер өчен язучыларның Тукай клубына ашыгулар, китап кибетендә чират торып «Ак чәчәкләр»не кулга төшерү, дусларга бүләк итүләр... «Ак чәчәкләр» бестселлерга, күпләрнең өстәл китабына әйләнә! «Их, «Ак чәчәкләр»нең киносы да булсын иде ул!» – дип тә хыяллаңалар ул чакта...

Һәм, ниһаять!.. Роман язылуга 50 ел тулганда «Яңа гасыр» каналы «Ак чәчәкләр» фильмын төшерә», – дигән хәбәр алгысытып куйды. Миләүшә исемле кечкенә кызның үз өйләренә күрше генә урнашкан телевидение-

дә 1967 елда «Ак чәчәкләр» телефильмын төшерүләрен күрүе, Нәҗибә Ихсанова, Шәүкәт Биктимеров, Әзһәр Шакиров, Равил Шәрәфиевләрнең уйнауларына соклануы, шуның тәэсирендә табиб булырга хыялланулары моңа сәбәп булгандыр. Ә бәлки кызның журналистиканы сайлавы, телевидениегә кереп китүе, «Татарстан–Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директор урынбасары Миләүшә Ләбиб кызы Айтуганова булып, фильмның идея авторы һәм продюсеры дәрәҗәсенә җитешүе кирәк булгандыр?

Әсәрнең тәэсир көче һаман шул икән! Көзен төшерелә башлап, бу көннәрдә соңгы серияләре эшләнеп яткан фильмның, ун серияле булып, сентябрьдә тамашачыга тәкъдим ителәсен инде беләләр, зарыгып премьераны көтәләр. Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча телләр турындагы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тарафыннан әзерләнгән фильм тәрбияви яктан да әһәмиятле.

«Ак чәчәкләр»гә багышланган тәкъдим итү кичәсе меңнәрне җыйган иде. Фильмнан өзекләр, актерлар, яңа җырлар – бар да рәхәт бер дулкында тибрәтте. Ә сораулар артканнан-арта гына. Фильмның режиссеры, сценарий авторы кем? Кайсы артистлар катнаша? Гөлшәһидә белән Мансур ролендә кемнәр? Кайларда төшергәннәр?

Кайбер серләрне инде чишсәк тә буладыр. Әйдәгез, экран артына күчеп, шул сорауларга җавап табыйк. Оператор-куючылар, режиссер ярдәмчеләре, тавыш режиссерлары пульты, камералар күзгә чалынып кала. Соңгы штрихлар... Камера! Мотор! Башладык!..

Кадр эчендә яшәү

Актерлар белән эшләргә талантлы режиссер Ринат Әюповны чакыралар. Аның психологик типажлары аеруча уңышлы килеп чыга. «Миңа актерларны кадр эчендә ихлас яшәргә өйрәтергә туры килде, – ди Ринат Әюпов. – Беренче айларда кинога төшү кытыршы килеп чыга иде әле. Кычкырып, пафос белән сөйләшүләр, диалоглар ясалма. Кабат-кабат исләренә төшереп, тавышларын басарга тырыштым».

Күбесе 70 нче, 80 нче елларда туган артистларны режиссер совет чорындагыча сөйләшергә дә өйрәтә. Социалистик система тудырган куркуны, сүзләрне үлчәп әйтүне, сагаюны чагылдырырга кирәк сөйләмдә. Татарларда бу аеруча күзгә ташлана. Табиблар дөньясында да сизелә ул. Тагын бер әйбер: 60 нчы елларда халык мәрхәмәтле, шәфкатьле булган, авыруларга, ярдәмчесез калганнарга булышырга әзер торган. Чир белән бергә кешенең күңелен дә дәвалаганнар. Шуны камера аша тамашачыга, бигрәк тә яшь буынга җиткерергә тырышалар. «Әдәбият һәрвакыт театрны коткара. Мин рәхәтләнеп, яратып эшләдем, – дип искә төшерә Ринат Мирзахәсән улы. – Төшерә башлавыбызга 9 ай булды. Карында тугыз ай йөрткән бала ничек газиз һәм кадерле булса, экраннарга чыгасы фильмыбыз да шулай ук кадерле, көтеп алынган иде. Виртуаль күренеш килеп чыксын өчен утны, төсләрне, яктылыкны кора белү, ут һәм эчке кичерешләр белән панорамалы кадрлар төшерү, күзләр, детальләр... артистның кичерешләрен техника ярдәмендә тагын да көчәйтеп бирү... Нәфис фильмда иң мөһиме кадрның эчке ритмы бит! Әлбәттә, романның бөтен эпизодларын ала алмадык, бу мөмкин дә түгел! Гөлшәһидә, Мансур, Әбүзәр Гиреевичләрнең кешеләргә мәхәббәте, авыруларны үз итеп, аларның җанын, күңелен дәвалавы беренче планга чыкты».

Тормышчан әсәргә, татар телендәге фильмга халык шулкадәр сусаган икән!

Әсәрдә идеологиягә бәйле нәрсәләр күп, ә фильмда мәхәббәт тарихын һәм Әбүзәр Таһиров образы аша чын табибның нинди булырга тиешлеген күрсәтергә телиләр. Вакыйгалар күбесенчә тимерьюлчылар хастаханәсендә бара. Андагы авырулар ак халатлы артистларны баштарак табиблар дип кабул итә хәтта! Тора-бара алар бик теләп эпизодик рольләрдә төшә. Габдрахман Әпсәләмовның Боровое Матюшинодагы дачасы, Нәҗип Җиһановның музей-фатиры, 60 нчы еллар Казаны сакланып калган Белинский, Гагарин, Фәтхуллин урамнары, Авиатөзелеш районындагы 12 нче хастаханә, парклар, Ленин һәйкәлләре кадрга кереп китә. «Локомотив» пляжы тирәсе Федосеев дамбасын алыштыра. Биектау районы Көек авылын Акъярга әйләндерәләр, андагы фельдшерлык пункты нәкъ шул еллардагыча сакланып калган. «Гөлшәһидә җыры» Флера Сөләйманова башкаруында радиодан яңгырап тора... Ә Вил Усманов фильм өчен махсус җырлар яза! Гөлшәһидә, Мансур, Асия җырлары. Сценарий авторы Айгөл Әхмәтгалиева шигыренә язылган «Ак чәчәкләр» җыры исә хитка әйләнә. Фильмның буеннан-буена шул музыка, шул җыр күңелнең иң нечкә кылларына бәрелә: «Ак гөлләрдән җан җылысы алып / Күңелләргә саласы иде»... Әнә, фильмның администраторы Алия Сәлимҗанова



«Ак чәчәкләр»дә төшкән актерларның телефон номерларын яздыра. «Иртәгә Мансур «проходка»да төшә», «Гөлшәһидә, Диләфрүз, Юматшаларны театрда күреп була», «Причалда күрешербез – соңгы сериянең съемкасында»... Әсәрнең эчтәлеген белгәннәр администратор ни әйтергә теләгәнне шундук аңлап ала. Беренче серияне төшерүне махсус май уртасына калдыралар: алмагачлар, шомыртлар ак чәчәккә күмелеп утырган чакка. Ә юл башы сентябрьдә иде...

Фильмның максаты да табиб һөнәренең дәрәҗәсен күтәрү ләбаса!


Гөлшәһидә

Бу рольне К. Тинчурин исемендәге театр артисты Резедә Сәләхова башкара. Үзе миңа нәрсәләр сөйли:

– Миңа башта... Илһамия ролен тәкъдим иттеләр. Тик тамашачы күңеленә һич кенә дә Илһамия булып кереп каласы килми бит! Алайса, Диләфрүз, диләр. Анысы инде бөтенләй башка! Минем эчке дөньяма бик тә тәңгәл килеп тора. Җиңел, җитез, хисчән... Шундук ризалаштым! Ә икенче көнне телевизордан сюжет бара. «Ак чәчәкләр»гә төшерү башлана, Гөлшәһидә роленә актриса эзлиләр, бүген беренче кастинг узды», – дигән хәбәр никтер тынычлыгымны алды. Ә нигә сынап карамаска! Берничә көннән кастингка чакырдылар! Шактый кыз җыелдык анда. Тинчурин, Әлмәт, Әтнә театрларыннан, Татар яшьләр театрыннан... Гөлшәһидә роленә – Айгөл Хәйри, Мансур роленә Эмиль Талипов билгеләнгән. Беренче сериядә генә Гөлшәһидә белән Мансур бергә, аннары җиде серия буена Гөлшәһидә Мансур дип үлеп йөри. Беренче сериядәге шундый чиста, саф мәхәббәтне яңадан җиде серия буена сузып барырлык итеп күрсәтергә кирәк – таләп шундый: саф мәхәббәт, идеаль пар, экрандагы егет белән кыз да идеаль күренергә тиеш... Тик беренче тандем барып чыкмады. Яңа кастинг игълан иттеләр. Пар-пар итеп диалог уйнарга чакыралар: «Артем белән Резедә керсен!», «Резедә белән Илфак керсен!» Гримеркага кертеп, бизәндереп тә карадылар, 60 нчы еллардагыча, күзләремә уклар сызалар. Килешәме-юкмы, янәсе. Тагын камерага карыйлар, алай итәләр, болай итәләр... Берничә көннән Миләүшә Ләбибовна шалтырата, актерлар, режиссерлар җыелабыз, ди. «Гөлшәһидә – син бит инде, сине сайладык!» – димәсенме! «Ә кем Мансур?» – дип кызыксынам. Әлмәт театрыннан Динар Хөснетдинов икән. Алдан ук таныш булмасак, Мансур-Динар белән, бәлки, читенрәк тә булыр иде. Без училищеда бер тирәдә укыдык, бөтенебез бер гаилә кебек: исәнләшеп, сәлам бирешеп йөри идек.

Шулай да театр артистларына кинода төшү җиңел булмады. Чөнки без, соңгы рәтләргәчә ишетелсен дип, күкрәк тавышы белән сөйләшәбез, мимикаларыбызны күрсәтергә тырышабыз – театрда барыбер дә берникадәр арттыру бар. Ә монда тормыштагыча табигый булырга кирәк. Шуңа күрә дә беренче көннәрдә режиссерның: «Театральлекне ташла! Күзләреңне уйнатма! Кашыңны җыерма!» – дигән командалары яңгырап торды. Бик күп дубльләрдә төшәргә туры килде. Гөлшәһидә роле бик зур җаваплылык сорый! Текстны кулга алуга, режиссер Ринат абый Әюпов белән башта тикшерәбез: фраза белән нәрсә әйтмәкче була ул партнерына? Нинди мәгънә салып? Шул мәгънәне эзлибез. Театрда уйнаган драматик рольләрем Гөлшәһидәне ачарга ярдәм итте. Ә медиклар тормышы болай да таныш миңа: әнием фармацевт-провизор. Кинога төшү барышында шприцлардан һава чыгарып укол ясарга да, жгут салырга да өйрәндем... Гөлшәһидәне матурлык алиһәсе итеп күз алдына китерәләр. Матурлык бит ул шундый төшенчә: артист табигый уйнаса, тамашачы аны барыбер кабул итә. Чәченең кара түгеллеген дә гафу итә. Юкса Гөлшәһидәнең чәчләре кара булган, буярга кирәк, диючеләр дә булды. Гөлшәһидә белән күңелләребез, холкыбыз охшаш безнең.

Кино төшергәндә кызык хәлләр дә чыгып куя иде. Артем (артист Артем Пискунов – Резедәнең ире – *Э. З.*) белән никахлашканнан соң бер өч көн үткәндер, съемкалар башланды. Кадрда Гөлшәһидә белән Мансур үбешергә тиеш. Башта шикләнделәр инде. Бөтен төшерү төркеме карап тора, менә хәзер Резедә баш тартачак, дип. Сценарий буенча шулай кирәк булгач, нишләп карышыйм? Артемга башта әйтмичә йөрдем. Бер-ике ай үткәч кенә җаен туры китереп әйттем. Үзе дә артист бит, көнләшү авыруы белән авырмый ул. Ә Динар, партнер буларак, җайлы. Гел киңәшләшеп, бер-беребезнең сүзенә колак салып эшләдек. Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев, Ирек Баһманов, Хәлимә Искәндәрова, Рамил Төхфәтуллин кебек артистлар белән кайчан бергә уйнар идек әле! Хәния апа Фәрхи иң якын кешем – Сәхипҗамал җиңги ролендә иде. Безне модельер Ләйсән Хаҗиева «киендерде», күлмәкләрне ул сайлады. Үземнең дә берничә күлмәгем кинода төшеп, тарихка кереп калды. Туй күлмәге чыннан да шул чорныкы иде: администратор Алиянең апасының күлмәген кидем.



Мансур

Мансур роленә актерны шулай ук озак эзлиләр. Режиссер Ринат Әюпов ул рольгә пластика ягыннан көчле, эмоцияләргә бай Әлмәт драма театры артисты Динар Хөснетдиновны тәкъдим итә.

– «Ак чәчәкләр» белән беренче тапкыр унынчы сыйныфта таныштым. Ул чакта алай ук тәэсир итмәгән иде. Кастингтан соң кат-кат укыдым. Укыган саен, роман яңача ачыла барды. Табиб һөнәренә башкача карый башладым. Балачакта ук укыган булсам, бәлки, шул һөнәрне сайлаган булыр идем. Бер туганыбыз шулай ук табиб, ул – хирург. Шул абыемның киңәшләренә дә колак салдым. Халык ышанырмы, кабул итәрме дигән эчке бер борчылу белән яшәдем. Минемчә, табиблар йомшак, чиста күңелле була, алардан якты нур бөркелә. Мансур образы шәхсән үземнең тормыштан, минем холкымнан күчереп алынган кебек. Мин шулай ук эзләнүчән, нәрсәгәдер өметләнеп яшим, кыенлыкларны җиңәргә омтылам. Рольне уйнаганда Мансурга Динар сыйфатларын да өстәдем. Мансурның кызы Гөлчәчәкне кем уйнар дип йөргән идем. Баланы кинога төшерү сабырлык, түземлек сорый. «Абыемның кызы Мәрьям, бәлки, туры килер», – дип әйттем. Шулай итеп, Мәрьям минем кызым булып уйнады. Уен барышында, үз ролемнән бигрәк, аның өчен борчыла идем. Башкарып чыга алырмы? Югалып калмасмы? Аның әнисе Илмираны тамашачыга яшьләр тапшырулары аша таныш Венера Иванова уйнады.

Студиягә ашкынып килә идем. Әлмәттән иртәнге өч-дүртләрдә чыгып китәм дә, бөтенесеннән алда – 8 дә үк килеп утырам. Төнлә кайтып китәргә кирәк. Казанның шул чорга туры килгән урамнарында, табигатьтә төшү, хис-кичерешләрне, уйларны, эчке дөньяңны ачарга булыша торган җырлар, саундтреклар, соңгы сериядә Идел буйлап Чишмәгә китеп барулар... Бик ошады миңа!

Профессор Әбүзәр Таһиров

«Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда йөрәк авырулары буенча иң зур белгечләрнең берсе санала. Аңа күренер өчен төрле шәһәрләрдән һәм авыллардан йөзләрчә кешеләр килә. Халык арасында аның абруе, дан-шөһрәте бик зур. Ягымлы, игътибарлы булуы һәм сәләте турында хәтта легендалар йөри. «Әбүзәр абзый әле безнең бабайны да яки әткәйне, әнкәйне дә дәвалаган», дип сөйләүчеләр аз түгел иде. Аны еш кына «Мәңгелек доктор» диләр. Татарстанда һәм күрше республикаларда аның меңләгән шәкертләре эшли».

Әбүзәр Таһиров табиб кына түгел, кеше буларак та иң матур яклары белән ачыла. Аңа карап, чын табиб нәкъ менә шундый булырга тиештер дип куясың. Табиб авырулар белән ничек аралашырга, аларны ничек дәваларга тиеш – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров аны нәкъ шулай итеп, җиренә җиткереп уйный. Хәер, ул уйнамый, ул кадрда яши.

– Табибларга зур истәлек калдырасым килде минем. Чын табиб булса, менә шундый булсын ул дип, үземне дәвалаган, үзем белән аралашкан бик күп табибларның, профессорларның кайбер сыйфатларын, чалымнарын күрсәтергә теләдем. «Шундый табиблар да бар бит арабызда!» – дип горурланып, сокланып карарлык булсыннар. Ул заманда чын табиб булу, минемчә, кешенең укымышлы, талантлы, зыялы булуын күрсәтә. Әбүзәр Таһиров образына кергәндә әсәрнең прототибы атаклы профессор Әбүбәкер Терегулов, аның язмышы, гаиләсе турында да күп белә идем инде. Бу ролем белән табиб һөнәренә мәхәббәт, ихтирам уятасым килде.

«Сүзнең кадерен һәм көчен язучылар белән шагыйрьләр генә түгел, врачлар да белергә тиеш. Чөнки врачлар да кеше белән, аның күңеле белән эш итәләр...»

Әбүзәр Таһиров сүзләре Әзһәр Шакиров сөйләвендә аеруча үтемле, ышандырырлык яңгырый. Һәм ул фильмның буеннан-буена көчәеп, ярату, сагыну, көтә белү хисләре белән кайнарланып, җаннарны сафландыра.

Без «Ак чәчәкләр» дөньясында яшәдек.

P. S. Юк әле, юк, моның белән генә бетми икән! «Ак чәчәкләр» фильмының идея авторы һәм продюсеры Миләүшә Айтуганова Халыкара мөселман кинофестивалендә күрсәтер өчен сериалдан 3 сәгатьлек версия төшерүләрен сөйләде:

– Фильмда вакыйгалар бүгенге көнгә үк килеп җитә. Инде үзгәргән, яңарган Казан, медицинадагы зур казанышларыбыз, заманча җиһазландырылган, терминал итеп үзгәртелгән 7 нче хастаханә. «Ашыгыч ярдәм» машиналары тыз-быз чаба, ыгы-зыгы, шау-шу... Төп герой – профессор Әбүзәр Таһиров. Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек сыйфатлары фильмда беренче планга чыга. Әбүзәр Гиреевич атаклы табиб та, башкаларга игътибарлы, нечкә күңелле олпат зат та, Мансур өчен кайгыртучан әти дә, Гөлшәһидәнең алыштыргысыз остазы да... Әзһәр Шакиров аны әнә шулай киңкырлы итеп ача. Ә Нәҗибә Ихсанова өлкәнәйгән Гөлшәһидәне уйнаячак. Гөлшәһидәнең прототибы профессор Рәйсә Габдрахманова да заманында шушы хастаханәдә эшләгән. 85 яшенә кадәр биредә консультацияләр үткәрә торган булган. Бу хакта ревматология бүлеге мөдире, Татарстан Республикасының атказанган табибы Равия Гаяз кызы Мухина сөйләде... Кабинетта Гөлшәһидә-Нәҗибә апа ялгызы уйланып утыра. Өстәлендәге вазада умырзая чәчәге һәм профессорның фотосы. Ул, Әбүзәр Таһировның шәкерте, мондый зур дәрәҗәләргә ирешүе белән остазына чиксез рәхмәтле. Умырзая чәчәге аны ерак үткәнгә алып китә, хатирәләрен яңарта. Профессор Таһиров та «Умырзая»ны яратып җырлый торган була бит. Аны соңгы юлга озатканда талгын гына шул җыр агыла... Умырзая – сафлык, пакьлек, чисталык символы. Кыска гына гомерендә дә күпләрне сөендерергә өлгерә, яшәүгә өмет уята, күңелләрне сафландыра ул нәфис чәчәк. Умырзая җаннарны дәвалый. Ул – табиблар чәчәге. Әнә шундый тирән символик мәгънә салынган аңа!..

Җиңү паркы – Казандагы иң яшь паркларның берсе. Ул башкалабызның Бондаренко урамы белән Ямашев проспекты кисешкән урында урнашкан. Мәйданы – 50 гектар чамасы. Парк XX гасырның 70 нче елларында төзелә башлый. 1995 елда монда Бөек Ватан сугышы каһарманнары истәлегенә мемориаль комплекс төзелә. Парк рәвешендә ул 2005 елда – Бөек Җиңүнең 60 еллыгы уңаеннан ачыла. Парк быел кабат яңартылды. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына аны төзекләндерүдә «Челтәр компаниясе» ААҖнең генераль директоры – Җиңү Паркының иганәчеләр шурасы рәисе Илшат Фәрдиевнең өлеше зур.
Паркны яңартуны вакытында һәм җиренә җиткереп башкарып чыккан өчен аңа Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Казан мэры Илсур Метшин рәхмәт белдерделәр.



ҖИҢҮ ПАРКЫ










Мемориал уртасында Мәңгелек ут яна. Аның тирәли куелган мәрмәр такталарда Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган 200 татарстанлының һәм 29 Дан ордены кавалерының исемнәре мәңгеләштерелгән. Республикабызда формалашкан 7 нче укчы дивизиянең мемориал билгесе макеты да янәшәдә генә.
Паркка керү юлында ук куелган Җиңү стеласының биеклеге 42 метр. Аның постаментында кулына кылыч тоткан Сугышчы һәм күкрәгенә сабыен кыскан Ана басып тора.







Парк ачык һавада урнашкан хәрби техника музее белән дә ял итүчеләрне үзенә җәлеп итеп тора. Монда фашистларның котын алып торган атаклы «Төн пәриләре» очкан ПО-2 самолеты да бар. Сугыш елларында Казан заводы шундый 11331 очкыч эшләп чыгара. ПЕ-2 бомбардировщигы да – Казаныбыз горурлыгы. Авиация заводында көн саен шундый җиде-сигез очкыч ясала торган булган. Казанлылар фронтка ун мең бомбардировщик озата. Сафтан чыккан хәрби техника да биредә ремонтланган. Ватылган техниканы төзәтү өчен хәрби белгечләр үзләре дә әледән-әле алгы сызыкка барып торганнар.
Паркта мәшһүр Т-34 танкын да күрергә мөмкин. Бөтен фронтларны кичеп, Берлинны штурмлауда катнашкан бу танклардан әле бүген дә көч-куәт бөркелеп тора шикелле.
Постаментларга мәңгерелгән «Катюша», броньлы хәрби күзәтү машинасы, БТР-1, БТР-2, десант машиналары, танкларга каршы торучы артиллерия туплары, үзйөрешле артиллерия җайланмалары, очкычлар һәм башка техника – кызыксынган кешегә Җиңү паркында экспонатлар җитәрлек.



Паркның берничә аллеясы бар. Алар аерым каһарманнарга, төрле гаскәрләргә, тол калган хатын-кызларга, сугышта һәлак булган солдатларның аналарына багышланган аллеялар. Быелдан паркка ял итәргә килүчеләр электрон Хәтер китабыннан да файдалана алачаклар. Һәр елны Бөек Җиңү көне уңаеннан паркта бәйрәм чаралары уздырыла, Мәңгелек ут янына һәм ирләре сугышта һәлак булган тол хатыннар хөрмәтенә куелган һәйкәлгә чәчәкләр салына. Җиңү паркында йөргәндә күңелдә һәрвакыт горурлык хисе уяна. Сугыш чорында яшәгән, сугышта катнашкан һәр кешенең батырлыгы алдында баш иеп рәхмәт әйтәсе килә. Тыныч күгебез, бәхетле тормышыбыз өчен гомерләрен биреп, һәлак булганнарны исебездән чыгармыйча яшисе, киләчәктә сугыш афәте булмасын өчен кулыбыздан килгәннең барысын да эшлисе иде.

Сәхифәне Татарстан Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.

ДӘФТӘРЛЕ ТАБИБ

ВЕРОНИКА ТУШНОВА МОҢЛЫ КЫЛЛЫ ШИГЫРЬЛӘРЕ БЕЛӘН КҮПЛӘР ЙӨРӘГЕН УЯТА АЛГАН ШАГЫЙРӘ.











Аның тәрҗемәи хәленә багышланган язмаларда туган елы 1915 ел дип күрсәтелә. Димәк, аның быел 100 яшьлек юбилее буласы булган. Ләкин икенче чыганакларда Вероника Михайловнаның 1911 елда Казан ветеринария институты профессоры Михаил Тушнов гаиләсендә туганлыгы турында дәлилле мәгълүматлар бар. 1928 елда кызның Казан университетының медицина факультетына укырга кергәнлеген ачыклаганнан соң, икенче датаның дөреслеккә ныграк туры килүе ышандыра.

Шагыйрәнең биографиясеннән азмы-күпме мәгълүмат ирештерүдән зыян булмас. Тушновлар башта Зур Кызыл урамында, аннары Миславский исемен йөрткән урамда яшиләр.

Вероникaның анасы Мәскәүдәге Бестужев исемендәге Хатын-кызлар өчен югары курсларны тәмамлаган ханым була. Укымышлы гаиләдә үскән Вероникaның җәйләре Идел буенда – Шелангада үтә. Әнә шул Идел киңлекләре шагыйрәнең иҗатын гомер буе сугарып торачак. Җәнлекләрне, чәчәкләрне ярату кадәресе һәр кыз баланың нечкә урыны инде ул.

Кыз Радищев исемендәге телләрне тирәнтен өйрәтә торган 14 нче мәктәптә укыган. Шуңа күрә инглиз һәм француз телләрендә иркен сөйләшә алган. Әдәбиятка тартылуы көчле булса да, кыз, әтисенең киңәшен тотып, медицина юнәлешен сайлый. 1931 елда гаиләләре Ленинградка күченгәч тә, Вероника укуын мединститутта дәвам итә. Ә менә Мәскәүгә күчеп килгәч, Вероника рәсем сәнгате, поэзия белән мавыга башлый. 1938 елда табиб-психиатр Юрий Розинскийга кияүгә чыга. Шул ук елны матбугатта аның беренче шигырьләре дөнья күрә.

1941 елда, шагыйрә Вера Инбер киңәшен тотып, А. М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга керә. Ләкин Бөек Ватан сугышы башланып китү сәбәпле, әнисе һәм нәни кызы белән Казанга кайтып китә. Медицина белемле яшь ханымны хәрби госпитальдә биш куллап кабул итәләр. Госпитальдә аны «Дәфтәрле табиб» дип йөртәләр. Яралы сугышчыларны ул Казанда 1943 елга кадәр дәвалый. Яралыларны тормышка кайтару өчен аяусыз көрәштән бушаган арада табибә, ыңгырашкан авазларга колак сала-сала, дәфтәрен алып сукыр лампа ышыгына килеп утыра.

1943 елны ул Мәскәүгә күчә һәм табиблык эшен шунда дәвам итә. Шул ук елны ире белән аерылыша.

1944 елда «Новый мир» журналында тәҗрибәле хирургка багышланган шигыре басыла. Шул ук елны «Комсомольская правда» газетасында «Кызыма» дигән шигырьләр шәлкеме дөнья күрә. Укучылар бу шәлкемне бик җылы кабул итә. Шулай иҗат итә торгач, 1945 елда шагыйрәнең беренче җыентыгы – «Беренче китап» әзер була.

Танылган актер – аның да язмышы Казан белән бәйләнгән – Василий Качалов шагыйрәнең иҗаты белән бик нык кызыксына. Актер кунакларына, дус-ишләренә гел Вероника Тушнова шигырьләрен укый торган була.

Танылу озак көттерми. Вероника Тушнова 1947 елда яшь язучыларның беренче Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнаша. 1954 елда шагыйрәнең «Юллар-юллар» дигән икенче җыентыгы дөнья күрә. Шуннан соң

китә инде... Шагыйрәнең һәр нәрсәгә сизгер йөрәге «Йөрәк хәтере» (1958), «Йөз сәгать бәхет» (1965) исемле җыентыкларда теркәлгән шигырьләрдә ачыла. Шагыйрә фәкать аңа гына хас сизгерлек белән нечкә хисләр тукымасын тукый.

Вероника Тушнова үзенең иҗатында тәрҗемәгә дә урын бирә. Аның тәрҗемәсендә Рабиндранат Тагор, Габдулла Тукай әсәрләре русча яңгырый. Юлъязма шигырьләре – иҗатының кызыклы бер сәхифәсе.

Вероника Тушнова иҗаты еллар узу белән тагын да көчлерәк яңгыраш ала бара. Аның сүзләренә композиторлар һаман ешрак мөрәҗәгать итә. 1944 елда ук язылган «Яраткан-нан ваз кичмиләр» («Не отрекаются любя») дигән шигыренә Марк Минков язган җыр-романс 1977 елда Алла Пугачеваның хитына әйләнде.

Аның сүзләренә язылган җырлар байтак. Аларны Алла Пугачева гына түгел, бәлки, София Ротару, Ирина Аллегрова, Татьяна Буланова, Александр Градскийлар да бик яратып җырладылар. Ә бит иҗатының башлангыч чорында Вероника Тушнова лирик буяуларны чамасыз күп кулланган өчен тәнкыйтьләнә. Югыйсә шагыйрә хатын-кыз йөрәге лирикасыз тибә алмый лабаса.

Бу тормыштан яшьли (54 яшендә) киткән шагыйрә безгә сигез шигырь җыентыгы калдырган. Сигез китаптан торган Мәхәббәтнамә бу.

Шагыйрә үзе дә – тормышта мәхәббәт касәсенең баш әйләндергеч шәрабын татыган кеше. Дөрес, гаилә бәхете аңа аз эләгеп кала. Икенче ире – «Детский мир» нәшриятының баш редакторы Юрий Трифонов белән дә никахы кыска гомерле булып чыга. Шагыйрь Александр Яшин белән ике арадагы көчле яратышу, мөгаен, шагыйрәнең гомерен кыскарткандыр да. Чөнки Яшин гаиләсеннән китә алмый. Аларның соңгы күрешүе Вероника Тушнова онкология хастаханәсендә ятканда була. Яшин өч елдан соң үзе дә шул чир белән дөнья куя. Шагыйрәнең «Йөз сәгать бәхет» исемле китабы – шул мәхәббәт көндәлеге.

Кызыма

1

Бөркү төндә, айсыз төндә
Ятам тын гына.
Бу төнне мин бәби көтәм –
Уйда ул гына.

Малай сөям уйларымда,
Улга кызыгам.
Ак диварлы палатада
Хыяллар кыза.

Җәйнең җиләс җылы җиле
Тәрәзә какты.
Көн елмайган бер арада
Кызымны таптым.

«Хәерле сәгатьтә!» – дидем
Нәни кызыма.
Иреннәреңне охшаттым
Чәчәк таҗына.

Бөтен дөнья зәңгәр-зәңгәр –
Күзең зәңгәрдер.
Зәңгәр булмаса да ярый –
Миңа барыбер.

Синең беренче ал таңың
Тәрәзгә килде.
Шушы көннән без мәңгегә
Гел бергә инде!

Минем нәни йомарлагым,
Кайтырбыз өйгә.
Әле тыңла җырларымны
Йоклаган көйгә.

2

Син әле бик бәләкәйсең,
Саный белмисең.
Ике тулып өчкә киттең,
Уйнап туймыйсың.

Синең сабый йөрәгеңдә
Яшәми үпкә.
Хәтер калу күләгәсе
Зыянсыз үтә.

Бу дөньяның мәшәкате –
Ул сиңа түгел.
Иң авыр сүзләрне дә
Әйтәсең җиңел.

«Сугыш» диеп кул чабасың,
Уен дип уйлап.
Тыпыр-тыпыр син чабасың
Вагоннар буйлап.

3

Ә вагоннар ава-түнә
Алга ыргыла.
Вагонда инде беләләр:
Бу – башы гына.

Ерак офыклар артында
Сугыш учагы.
Мин – чарасыз, кысам синең
Нәни учыңны.

Ә аннары безнең өскә
Нурсыз төн ятты.
Хәтерлимсең син ул төнне?
Яхшысы – оныт!

Чәчәк һәм җырларга сөен,
Яшә һәм сөел.
Онытт кайгылы елларны!
Синең өчен хәтерләрмен
Үзем аларны.

4

Хат ташучы узып китә
Яхшы хәбәрсез.
Буран күмгән өйдә калдык
Хәбәр-хәтерсез.

Яшел күзле кызчык өйдә,
Күзе – тәрәздә.
Мәк иреннәр еламасын,
Әйтмим дөресен.

Кызым алдында еламам –
Яшем күрмәсен.
Кайгы барын бу дөньяда
Балам белмәсен.

Ул болай да аңлар мине,
Иңемдә – учы.
Нәни генә кызым минем,
Чын юатучы!

Ә мин аны юатырмын,
Рәсем ясармын.
Елмаермын, ә төн җиткәч
Елап ятармын.

5

Нәни кызымның дөньясы
Киңәя һаман.
Кешеләр, урман, шәһәрләр...
Сугышлы заман!

Булсын иде хәзер аңа
Төсле китаплар.
Зарланмый ул
минем кызым,
Килми ул елап.

Һич яратмый «ярамый»ны,
Ярата назны.
Миңа чын иптәш хәзер ул –
Зур үскән кызым.

Минем белән
салют тыңлый,
Флаг күчерә.
Фронт сызыгын таба ул
Минут эчендә.

Җавапсыз сорауларына
Җаваплар уйлый:
«Нигә, – ди, – әни, дөньяда
Сугышсыз булмый?»

Була, кызым, ник булмасын?
Яшәрбез әле!
Сугышлы еллар дәһшәтен
Үтәрбез әле!

Вероника ТУШНОВА
(Асия ЮНЫСОВА
тәрҗемәсе)





Лена
ШАГЫЙРЬҖАН

Туган ил, Ватан, Туган җир, Туган тел, Туган як... Шагыйрь Лена Шагыйрьҗан иҗатында әнә шул «бик таныш темалар» да бөтенләй көтелмәгән яктан ачыла, моңарчы беркем әйтмәгәнчә, үзенә бер яңалык табып тасвирлана. Лирика, милләтебезнең асылын тәшкил иткән төшенчәләр, һәр вакыйга һәм күренеш аның шигъри телендә кабатланмас яңгыраш таба. Аның шигырьләре ихлас, чын күңелдән... Шигърияте – затлы, үзе – искиткеч талантлы. Ул күпләрнең яраткан шагыйре. Лена Шагыйрьҗан шигырьләрен эзләп алып, юллап табып укыйлар, алар моңарчы ишетелмәгән, укылмаган кызыклы яңа рифмалары белән күңелне җәлеп итә.
Бу көннәрдә 70 яшьлеген бәйрәм итүче олы шагыйрәбезне – Г. Тукай премиясе лауреатын олы юбилее белән котлыйбыз! Аңа озын иҗат юлы телибез!

ҺАВАЛАРДАН ЙОЛДЫЗ ЯУГАН ЧАКТА...

Әнием хатлары

Ямансулап йөргәч көн буена,
Искә төшереп үткән чакларны,
Утырдым мин укып төн буена
Әнием миңа язган хатларны.

«Балам» диеп башлана да хатың,
Ике күзем тула яшемә.
Үзем инде менә җиткәнмен ич
Ул чактагы Әнием яшенә...

И Әнием, хатларыңда синең
Юлың саен көю, сызлану,
Хәрефләнеп төшкән хәвефләнү,
Өзелеп сагыну, сөю, кызгану:
«Уйлап йөрдем бүген иртәдән үк...»
«Күргән идем кичә төшемдә...»
«Ярый, кызым, сау-сәламәт яшә,
Уңыш теләп калам эшеңдә...»

И ул чаклар, и ул татлы хатлар,
«Күрешкәнче тиздән» диюләр...
Әти-әни җылысы сеңгән хатны
Алып куанудан биюләр...

Хәбәр-хат та, җавап-хат та алар,
Йөрәгеңнән чыккан вәгазь дә.
Үкси-үкси куям яңагымны
Әнием кулы тигән кәгазьгә.

Ачы сагыну

Сагыну уты өтә йөрәгемне,
Күрешү өмете чөнки өзелгән...
Бердәнберләр, алыштыргысызлар
Хәтер дисбесенә тезелгән...

Ишетәм күк кайчак дәшүләрен,
Тутыргандай бушлык сагышын.
Шул авазлар гына көйлидер күк
Гомерем елгасының агышын...

Үз көенә йөзми инде көймәм,
Хәтер ярларына тукталып.
Очып киталмыйсың хыялда да,
«Күреп кайтыйм» диеп укталып.

Һәр югалткан җанга «көтәм!» диеп
Хәбәр салалмыйсың талпынып.
Йөрәгеңне ут ялкыны сыман
Куырып ала юклык салкыны.

Ямансулап, гаҗизлеккә батам,
Бер чара юк – шунысы йөдәтә.
Бергә чаклардагы бәхетемә
Сагыну белән түлим йөзләтә...

Ах, юксыну!..
Өмет белән генә
Татлы икән бит син кешегә...
Җан күшегә... догалардан гайре
Бер дәва юк сагыну хисенә...

Туган илкәй бар дөньяда...

Бер ханга да, патшага да,
Башкага да карамастан,
Туган илкәй бар дөньяда –
Ыруг чәчәк аткан бөстан.

Туган Илкәй – исе таныш,
Төсе таныш, бишек – камыш...
Төнен – байгыш, көнен – аккош,
Иртә-кичен хуш ис аңкыш...

Тирәкләре, тупыллары,
Чыпчыклары, былбыллары,
Көчекләре, сыерлары –
Сиңа – җирдәш, якташ – бары.

Кышларын – ак бураннары,
Чеметеп ала торганнары, –
Үзеңнеке, сүзеңнеке –
Болын-кыры, урманнары...

Атлауларым шул җир буйлап,
Язлар киләсене уйлап,
Кышлар чыккач, язылып бер
Кинәнәсең – сабантуйлап.

Оҗмахларга эләксәң дә,
Туган Илкәй калыр җанда...
Ул ич сиңа өлеш биргән,
Барлыгыңны сугып санга.

Сусаганга теләк телим:
«Чишмәләрдән су алгыры!»
Яман теләк яный кемгә? –
«Илсез-ватансыз калгыры...»

«Глобальләшә дөнья» дип
Ишетсәк тә дошман-дустан,
Кече Җир бар Олы Җирдә –
Үзебез туган куыш, ыстан...

Шөкер итәм, әрнесәм дә
Тарих тулы үкенеч-зарга, –
Әткәм-әнкәм, әби-бабам
Гомер иткән Ил-җир барга...

Һавалардан йолдыз яуган чакта

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Тамчыларын җыйдым учыма.
Күңелкәем әллә шуннан бирле
Чиксезлеккә, күккә очына...

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Теләкләрем теләп өлгермим...
Ашкынукайларым шулай көчле,
Чүттән генә чыгып йөгермим...

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Инде күралмый да каламын.
Хыялымда җиргә төшкән берен
Учларыма җыеп барамын...

Челтәр шәл

Хисләремне үрәм,
Челтәр итеп «күз-күз»...
«Телле-телле» бизәк –
Күзәнәкле һәр сүз...

Пәрәвездәй нечкә,
Юка челтәр шәлем:
Үтә күренмәле
Әрфия күк хәлем...

Гомеркәйләр кире кайтканда...

Чыгып китим ерак сәфәрләргә,
Өйдә ятып, җаннар мүкләнде.
Йөрәк-йортның иске чардагына
Кошлар түгел, җеннәр төпләнде.

Ишек-тәрәзләрне шар ачыйм да,
Бикләп-нитеп тормый капкасын,
Чыгып китим әле... Көтмәсеннәр,
Белеп булмый кайчан кайтасын...

Кем белә бит, бәлки, бик еракта –
Кайтмас җирдә торып калырмын.
Ара-тирә мине җуйганнарга
Җилләр аша хәбәр салырмын...

Чыгып китим юлга үз җаема...
Җәяүләпме шунда, очыпмы...
Югалтмыйча Күңел кыйбласына
Юл күрсәтеп торган өч укны:

Берсе – атам-анам туфрагына,
Икенчесе – сөйгән ярыма...
Өченчесе – гомерем елгасының
Мине көткән ташлы ярына...

Һәм утырып шунда хәл алырмын,
Үткән гомерләрне сагынып...
Баш очымнан очар язлы-көзле
Кыр казлары, канат кагынып...

Үткән гомеркәйләр кире кайткач,
Кузгалырмын кызык сәфәргә...
Җанда җыелып калган
саф хисләрне
Ләйсән яңгыр итеп чәчәргә...

Ямь-яшел төсләргә зарыгам...

Ямь-яшел төсләргә зарыгам,
Яшелләрем уңар чак микән?..
Зәңгәр буяу салсаң сарыга,
Яшел чыга, диләр, хак микән?..

Сарылардан сары сагышларым,
Җете зәңгәр килеш хыялларым –
Ник аларны җилләр алмаган? –
Яшел буяуларым калмаган...

Айлы гомер

Оныттырды инде шәһәр төне
«Ай яктысы» дигән гүзәллекне...
Ай яктыларында очрашулар
Тик хәтердә генә эзәрлекли.

Ай сукмагы буйлап китте яшьлек,
Кая бара икән аның юлы?
Яшь кыз чагым чагыла күл өстендә,
Яшь күңелем тулган ай күк тулы...

Ай яктысы сыман – үткән гомер,
Үзе моңлы, үзе серле һаман.
Минеке дә, синеке дә түгел, –
Кемнеке соң икән ул яшь заман?..

Татар психологиясе

Үкенәбез кайчак, имеш,
Татар акылы төштән соң...
Төбенә төшсәң, дөресе:
Татар акылы хистән соң...

Изгелек инстинктын ул
Бик тиз генә басалмый.
Шартлы рефлексның «җимен»
Гүя һаман ачалмый...

Акылы җиткән җирдә дә
Җиңә ешрак хис-күңел.
Хисләр алдан йөрсә, әлбәт,
Яшәве җиңел түгел...

...Сынавын татар сынаган
«Сабыр төбе – алтын»ны...
Сары алтын – төбе салкын,
Сүрелтмәсме ялкынны?..

Сабантуйдан таралган күк...

Әллә яңгыр килә инде,
Күк читләре – кучкылт кара...
Дымга түгел, дуска сусап,
Сабантуйдан кайтып барам...

Никтер моңсу, һава – бөркү,
Бар да уза, бар да бетә...
Көтеп алган бәйрәмнәр дә,
Көтмәгәннәре дә – үтә...

Парлы-парлы, ялгыз-йолгыз,
Берән-сәрән, төркем-төркем –
Таралабыз Сабантуйдан,
Айрылабыз килеп бер көн...

Машиналар, атлар чаба,
Юл тузанын яра-яра...
Шаулап узган бәйрәмнән дә
Җанда кала моңсу яра...

Акыл белән хис

...Берсе әнә, шигырь язар өчен
Акыл кирәк түгел һич тә, ди.
Баш эшләтеп азапланасы юк,
Аның өчен җитә хис тә, ди...

Мин хисләргә батып йөрдем беркөн,
Мөмкин иде башны «җуярга»:
Ярый әле «тиле» акылым җитте
Шул хисләрне язып куярга...

Шулай, дустым, ил-көн учагында
Өмет пыскып янган төннәрдә –
Бер «акылсыз» шигырь язып утыра,
Мең «акыллы» йоклый мендәрдә.

Шагыйрь халкы сәер: акылларын
«Шигырь-шигырь» итеп җуялар.
Хис елгасы булып агалар да
Гакыл дәрьясына коялар...


Фоат САДРИЕВ

«Фоат Садриев – татарның Шолоховы ул...» Шагыйрь Зөлфәт Мөслимдә яшәп иҗат итүче язучы турында шулай әйткән иде. Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай премиясе лауреаты Фоат Садриев «Бәхетсезләр бәхете», «Таң җиле», «Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән», «Рәхмәт, әтием!», «Адәм әүлиясе» кебек роман-повестьлары, драма әсәрләре белән укучылар күңелен күптән яулады инде. Халыкчанлыгы, үзенчәлекле образлары, җылы лиризмы, тирән психологиясе, юморга бай теле аша Фоат Садриевны шундук танып аласың. Авылны, аның гади кешеләрен аеруча яратып тасвирлый ул. «Гөлчәчәк» хикәясен исә автор «Сөембикә» журналы өчен махсус язды.

ГӨЛЧӘЧӘК

(хикәя)

1

Кояш рәхимсез көйдерә. Вокзал алдындагы халык күләгәрәк урыннарга елышкан. Автобуслар тукталышы ягындагы киоск янында сары бөдрә чәчле хатын белән өч-дүрт яшьләр тирәсендәге кыз пәрәмәч ашап тора. Хатынның таушалган, вак җыерчыклар баскан йөзенә караганда, аңа илле яшьләр биреп булыр иде. Кызының чем-кара чәчләре чуалып беткән. Ул, шомырттай кара күзләрен күтәреп, әнисенә дәште:

– Эчәсем килә...

Әнисенең купшакланган иреннәре арасыннан кисәтүле тавышы яңгырады:

– Акча юк дип күпме әйтергә сиңа? Тагын сорасаң, берүзеңне шушында калдырам да китәм, Гөлчәчәк!

Кыз тып-тын булды, күзләрендәге өмет куркуга әйләнде. Шул вакыт базык гәүдәсенә ап-ак костюм-чалбар кигән кара мыеклы бер ирнең, кесә телефоныннан сөйләшә-сөйләшә, боларга таба килгәне күренде. Хатын «дерт» итеп куйды, аннары кызу адымнар белән ир каршысына атлады.

– Исәнме, Усман! – дип дәште хатын.

Ир, шып туктап, аларга төбәлде, кара мыегы сикереп куйды.

– Дорогая, вы меня с кем-то путаете! – дип, чаларган чәчле башын ялт кына уңга борды да читкә атлады. Хатын аның артыннан ташланып:

– Сания бит мин! – дип кычкырып та караган иде, ак костюм елкылдап торган кара машинага утырып юк булды...

«Йә Аллам! Үлгән кеше терелгән!» – дип гаҗәпләнде Сания. Ул арада аларның автобусы килеп туктады. Зур кызыл сумкасының озынча каешын арык иңбашына элгән Сания, билетын теш арасына кыстырып, Гөлчәчәкне җитәкләгән килеш автобуска ябырылган кешеләргә иярде...

Алар кайтып кергәндә, Рәйсә чәчәкләренә су сибеп йөри иде. Гөлчәчәк: «Әби, әби!» – дип аңа таба йөгерде. Әбисе аны күтәреп алгадай итте дә җиргә бастырды.

– Нык үскәнсең, балам, – дип, юеш куллары белән оныгының ике битеннән сөйде.

Әбисе белән әнисе дә кочаклашкандай иттеләр. Өйгә керүгә, Гөлчәчәк түр якта идәндә бөгәрләнеп йоклап яткан ала мәчегә таба йөгерде. Сания алган күчтәнәчләрен өстәлгә тезә башлады.

– Менә бу конфетларны Мәчтүрә әбигә бирерсең. Бусы – күзенә дару.

– Әбиең янына үзең бармыйсыңмыни?

– Сукыр кешене ник борчырга?

– Шул син дип елап бетте инде аның күзләре, – диде әнисе усал гына.

Сания, аның бу сүзләрен җавапсыз калдырып, кабат сумкасына иелде.

– Монда Гөлчәчәкнең кием-салымнары, уенчыклары.

Ул зәңгәр күзле, сары бөдрә чәчле зур курчакны чыгарып утыртты, аның астына шакмаклап бөкләнгән ниндидер чүпрәк кыстырды.

– Анысы нинди иске-москы тагын?

– Минем халат ул. Гөлчәчәк үтә яратып уйный аның белән.

– Тапкансың бала уйнатыр әйбер, – диде әнисе өнәмичә. – Әйтер идем инде...

Сания сумкасын чыжылдатып япты. Әнисе табын әзерли башлауга, мәчесен күтәреп Гөлчәчәк алгы якка чыкты.

– Әбием, песи мине онытмаган! – диде, шатлыгыннан нишләргә белмичә.

«И тәмле, и тәмле!» дия-дия итле бәрәңгене дә ашап куйды. Арыган иде бала, күзләре йомыла башлады. Сания, аны түр якка алып чыгып, урын җәяргә тотынды. Шунда Гөлчәчәкнең күзе биектә – стена уемында басып торган сынга төште. Курчагыннан да зуррак, үзе шоколад кәгазе төсле елкылдап тора. Гөлчәчәк сынның каршына ук килеп басты һәм башын артка ташлап:

– Бу кем? – дип сорады.

– Давыт исемле батыр егет ул, – дип җавап бирде әнисе. – Кил, ят, кызым.

Йомшак урынга яткач та карашын шуннан ала алмады, әллә ниләр сорыйсы килде:

– Әни, нишләп шәрә ул?

– Күлмәк-ыштан алырга акчасы булмаган, – диде әнисе, аның чәчләреннән сыпырып.

– Гел безнең кебек икән, – диде Гөлчәчәк һәм шундук йоклап та китте.

Сания алгы якка чыккач, сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Сәер иде аларның мөнәсәбәте. Тирәндә ята торган сәбәпләре бар иде...

– Миңа кузгалырга вакыт, – диде Сания, савыт-сабаны җыештырып куйгач. – Ашыгам...

– Утыр әле, – диде әнисе кырыс кына. – Син ичмасам, әни, баланы алып калмассың микән, дип шылтыратып та куймыйсың. Нинди кеше син? – Кызына озаклап карап торса да, тегесе дәшмәде. – Бала карарлык рәтем бармы? Җитмешкә җитеп киләм бит. Авыртмаган җирем юк...

– И әни! – диде Сания авыр сулап. – Син әле таш кебек. Менә мин ул...

– Яшәвеңнән нәтиҗәләр ясамадың шул... – Әнисенең тавышы уфтанулы иде.

– Һәркемнең үз тормышы, әни.

– Үз тормышың ни соң ул? Менә мин гомеремне балаларга бирдем. Өч катлы мәктәп төзедем. Мондый мәктәп республикада өчәү генә.

– Ул мәктәпнең нигезенә Рәшит абый белән минем дә йөрәк тибешләребез салынгандыр, – диде Сания башын читкә борып.

Әнисе дөртләп капты.

– Бу ни дигән сүз?! Әллә мин сезне рәнҗеттемме?!

– Юк, әни, рәнҗетмәдең син безне... – дип куйды кызы.

– Әллә ниләр төрттермәкче тагын үзең! – Әнисенең иреннәре калтырый башлады, күзләрендә зәһәр очкыннар күренде. – Син менә үгез мөгезендә чебен булып күпме яшәргә уйлавыңны әйт. Кайчан мондый тормышка чик куясың? Күзләремә туп-туры карап әйт!

Сания башын иеп, шактый вакыт дәшми торгач:

– Бусы соңгы китүем, әни. Эш таптым мин...

– Беләм мин синең нинди эш тапканыңны! Тагын чит илгәме?

– Үзебездә эш таптым...

– Аннары?

– Аннары... аннары... атар бәхет таңнары!..

Сания үз-үзен мыскыллап елмайды да ашыгып чыгып китте... Ул автобуска көч-хәл белән өлгерде. Яшел болын, аллы-гөлле чәчәкләре белән тәрәзгә кагылгандай, автобуска каршы йөгерә. Тәрәз пыяласын ике бармак сыярлык кына шудыруга, хуш исле һава бөркелеп кереп, аның йөзен, иңбашларын иркәләргә тотынды. Сания, шушы көтелмәгән рәхәтлектән ләззәтләнеп, күзләрен кысты. Автобуска каршы йөгерүче чәчәкләр гүя аны хәятнең барлык төсләре белән дулкынланучы тере яшеллек эченә, җырлы-моңлы туйларына чакыралар. Юк шул, бу чәчәкләрнең җәйге туена, бик теләсә дә, Сания кушыла алмый инде. Аның болынындагы чәчәкләр сулган, аның печәннәрен җиләкләре белән бергә чабып ташлаганнар... Усманны очрату әллә нишләтте. Күңеле урынына утыра башлаган иде бит инде.

...Усман кинәт юкка чыккач, шалтыратуларына җавап бирмәгәч, Сания аның офисына барды. Чит илгә озак командировкага китте, диделәр. Аннары, ул шунда калды, кабат килмә, диделәр. Ә ул һаман үҗәтләнеп, аны юллады. Соңгы баруында, ул үлгән, диделәр... Бүген Усманга таба атлаганда: «Менә синең кызың!» – дип кычкырасы килде. Әмма итәгенә ябышкан сабыеның нәни йөрәген яраларга теләмәде...

Күңелсез уйларыннан арыну өчен ул карашын офыкларга юнәлтте. Сыек зәңгәрсу пәрдә белән өртелгән офыклар шундый серле, аларның артында бәхетле дөнья бардыр, андагы адәм балаларының уй-хыяллары киртәләрсез тормышка ашадыр төсле тоелды. Ә бездә бер дә алай түгел, алай түгел шул! Алай булса, менә бүген үзенең иң яраткан кешесе – Мәчтүрә әбисеннән качып китеп барыр идемени ул?! Качмас иде, аның белән очрашырга ояла. Абыйсы Рәшит белән икесе Мәчтүрә әбиләре итәгендә үсте алар. Аның моңлы итеп укыган догалары, гел-гел иркәләп торучы берсеннән-берсе матур изге теләкләре оҗмах дөньясы булып хәзер дә күңелне җылытып тора. Фатир юнәтү белән үземә алам, дип әбисенә сүз биргән иде Сания. «Әниең чакыргач бармадым, ә менә сиңа барам, кызым», – дигән иде әбисе. Чөнки ул да Сания өчен үлеп тора, алтын бөртегем дип кенә йөртә иде. Сания балалар ярата иде, башлангыч сыйныфларда, ясле-бакчада эшләргә хыялланды. Тик әнисе, нишләптер, аның бу теләген өнәмәде. Өй ту-

тырып бала табу хыялы да барып чыкмады. Бер кыз тапты, аны да тәрбияли алмый менә.

* * *

Оныгы бик нык үзгәргән булып чыкты. Рәйсәне көннәр буе әле бакчага, әле инешкә, әле кибеткә сөйри, иртәдән кичкә кадәр бетмәс-төкәнмәс сораулары белән җәфалый. Тыңламасаң, көйсезләнә, елый. Бала артыннан йөгерә торгач, Рәйсә буынсыз кала, башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып, кич урынына тәгәри. Капка шыгырдаса: «Әни кайтты!» дип чыгып йөгерүләре болай да авырткан йөрәген парә-парә телгәли. «Әниемнең күлмәгеннән төшеп калган», – дип, тәрәзә төбендәге рәйхан, кына, яран гөлләренең чәчәкләрен инде өзеп бетерә язды. Бүген иртәдән бирле: «Мәчтүрә әбиемне сагындым, аның янына барыйк», – дип теңкәсен корытты. Унбиш чакрым арада киләп сарып йөреп булмаганын аңлатып кара син аңа. Тәмам түземе төкәнгәч, мәктәп директоры Илшаттан инде карт-коры гына яшәп яткан туган авылына илттерде. Алып килгән күчтәнәчләре белән әнисен сыйлагач, Рәйсә танышбелешләрен күрергә чыгып китте. Гөлчәчәк карт әбисе белән икәүдән-икәү калуына сөенеп туймады. Ул бит аңа көндез дә, төнлә дә исеннән чыкмаган сүзен әйтергә дип килде.

– Әбием, син теге чакта без килгәч, әниемне Аллаһ кайтарыр дигән идең. Нишләп һаман кайтармый? – дип башлады ул сүзен.

– Ә син сорадыңмы соң? – диде әбисе аны сөепсыйпап:

– Сорадым. Син кушканча, иртән дә, көндез дә, кич тә сорадым.

– Мин өйрәткән доганы укып сорадыңмы?

– Әйе. Бисмилләһ ир-рахмән иррахим, – дип башлады Гөлчәчәк. – Куль-һү аллаһу әхәд, аллаһуссамәд. Ләм йәлид үә ләм йүләд вә ләм йәкүл ләһү күфуән әхәд. Әмин!

– Бигрәк зиһенле бала булгансың инде, бәбекәччәем! – дип, әбисе аны алдына утыртты, битен Гөлчәчәкнең яңагына терәде. – Бер генә сүзен дә ялгышмыйсың, рәхмәт, бәбекәччәем!

Ләкин Гөлчәчәк тынычлана алмады, сораудан туктамады:

– Әбием, Аллаһ нишләп әнине кайтармады соң?

– Кайтарыр, кызым, кайтарыр. Соравыңнан туктама.

– Инде күп сорадым бит... Һаман кайтармый...

– Аллаһтан сораучылар бик күп бит, бәбекәччәем. Җир йөзе тулы сораучы халык. Догаларың аңа барып ирешү белән теләгеңне үтәр...

– Их, әбием! – диде Гөлчәчәк, әллә нинди шатлык белән аның алдыннан сикереп төшеп. – Әнием кайткач, сине үзем җитәкләп йөртермен әле.

– Рәхмәт, кызым, яхшы сүзең өчен, – диде әбисе күңеле булып.

Әбисе тәһарәт алып, намаз укыды. Гөлчәчәк тә аның янына тезләнеп теге догасын кабатлады, Аллаһка: «Тизрәк әниемне кайтар!» – дип ялварды.

Рәйсә әбисе кайтып аны киендерә башлауга, Гөлчәчәк:

– Мәчтүрә әби янында калыйм әле, – дип ялынырга тотынды.

– Булмаса, берәр көнгә калсын, – дип Мәчтүрә әбисе дә оныгы ягыннан сүз катты.

– Ни сөйлисең, әнкәй?! – дип туктатты аны Рәйсә. – Ул бит түшәмнән чаба! Газга шартлап очарсыз!

Гөлчәчәкнең бер дә түшәмнән чапканы юк инде. Калдырасы килмәгәнгә шулай ди.

Мәчтүрә әбисе капка төбендә таягына таянган килеш калды. Гөлчәчәк аның ак күлмәге күздән югалганчы машинаның арткы тәрәзәсеннән кул болгый-болгый карап барды. Калды карт әбисе капка төбендә берүзе...

2

Бүген яңгыр ява. Гөлчәчәк иртәдән бирле әбисен ишегалдына әйдәкли.

– Ярар, кызым, яңгыр гына туктасын, – дип юмалап, әбисе тавыкларга җим салырга кузгалды.

Гөлчәчәк курчагын каршына утыртты, җиңнәрен сызганды.

– Боргаланмыйча гына утыр әле! – диде ул йодрыгын селкеп. – Сабырсызланма! Хәзер юындырам дидем бит. Әле каршы әйтеп торасыңмыни?! Менә сиңа, менә! – ул курчакның аркасына шап-шоп сукты, суккан саен курчакның зәңгәр күзләре йомылып-йомылып алды. – Тукта елавыңнан! Болай да башым чатный. Синең тавышың гына җитмәгән иде миңа.

Курчагын бераз җилтерәтеп алганнан соң, уйга калды. Әнисенең кулы сукканда каты кебек. Ә менә аны юындырганда мамыкка әйләнә. Әнисе баш түбәсеннән аяк очына кадәр бөтен гәүдәсен сабынлап сыпырганда, шундый рәхәт була. Гөлчәчәк үзе дә күбекне тәннәренә чәп-чәп итеп чәбәкли, икәүләп көлешәләр. Әнисенең бит очлары аллана, җылы сулышы Гөлчәчәкнең бөтен гәүдәсен изрәтә. «Менә тәтәй булдың», – дип, гәүдәсен сөлге белән корыткач, әнисе кат-кат битләреннән үбә, озаклап аның чәчләрен исни, кайчакларда тавышсыз гына үксеп елый... Әнисе еласа, аның да күңеле тула, шулай да елаудан тыелып кала. Бәләкәй кешеләргә еларга ярамый, еласаң ачуланалар. Ә олылар үзләре кайчан телиләр – шул чакта рәхәтләнеп елыйлар.

– Тик кенә утыр, – диде Гөлчәчәк, курчагына бармак янап пышылдады. – Хәзер тагарак алып керәм дә юындырам.

Ул дәртләнеп өйалдына чыкканда, каршысына әбисе килеп керде. Ул бер кулына тавык күкәйләре тоткан иде.

Гөлчәчәк шарт борылды да ишектән кереп юк булды. «Бу чәтнәби, мөгаен, нидер майтарырга йөри», дип уйлады Рәйсә һәм, күкәйләрен верандага куеп та тормастан, аның артыннан керде.

– Кая бара идең? – диде як-ягына каранып.

– Бармадым... – дип куйды Гөлчәчәк курчагына иелгән килеш.

Ул-бу сизелмәгәч, Рәйсә чыгарга борылды. Ләкин ашыгудан кулындагы дүрт күкәйнең икесе бармакла-



Рәсем: Наталья Васильева

рыннан ычкынды да идәнгә төшеп ярылды. Матур бизәкле зәңгәрсу keләм өстенә җәелеп киткән күкәй сарыларын күргәч, Гөлчәчәк чыркылдап куллары тотынды һәм «эһ» иткәнче сикереп килеп күкәй сарысына имән бармагын тыкты. Рәйсә оныгының кулын алып, бармагын итәге белән сөртте дә:

– Көлеп торма, ичмасам! – дип аны читкә этте. – Барысы да синең аркада! Зиһенемне алып бетердең! Син дип ашыкмасам, келәмем пычранмый иде! – диде ул оныгын әрләп.

Гөлчәчәкнең кинәт кәефе төште. Курчагын алып олы якка чыкты. Киереп ачып куелган түр тәрәзә каршына килеп, яңгыр туктамый микән, дип карамакчы булган иде, күк күкрәп җибәрде, җил тагын да көчәйде. Юешләнгән яфракларның шыбырдашканы ишетелә. Алар нindидер күңелле әйберләр сөйләшәдер, шулай шыбырдаша-шыбырдаша җирдән күтәрелеп, очып китәргә җыенадыр шикелле. Их, Гөлчәчәкне дә үзләре белән очыртып алып китсеннәр дә әнисе янына китереп төшерсеннәр иде! Менә хәзер карт әби янында булсаң иде ул! Мәчтүрә әбисе нишләсәң дә тыймый, нәрсәгә үрелсәң дә, «ал, кызым» дип кенә тора. Ә Рәйсә әбисе беркая атлатмый, берни эшләргә ярамый. Тупны диванга куйсаң, «Ал тубыңны, диванны пычратасың!» – дип тавышын күтәрә. Ашаганда авызны чәпелдәтмәскә куша. Кашыкның савытка тиеп шакылдаганын да яратмый.

– Әйдә, кулларыңны юабыз да ашыйбыз, – диде әбисе, ишектә күренеп.

Кул юарга да кул юарга! Көне буе шулай. Түтәлдән кишер алсаң, кишерне дә, кулны да кат-кат юдыра. Әллә нинди микруб дигән әйберләр авызыңа кереп, эчеңә төшәр, чирләтер, дип котны ала. Аның әбисенә нидер әйтәсе килде, тик җайлы сүз таба алмады. Ачудан курчагын аягыннан тотып почмакка атты.

– Мин келәмне пычратмадым, – диде ул турсаеп.

Әбисе сүз әйтә алмыйча өнсез калды...

* * *

Ул көнне Гөлчәчәк иртәдән бирле йөгерде дә йөгерде, аяк басмаган җире, кермәгән тишеге, бирмәгән соравы калмады. Тәмам эт булып арыган әбисе төштән соң аның сорауларына яткан килеш кенә җавап бирергә тотынды. Тышта күке тавышы ишетелде: «Күккү! Күккү! Күккү!»

– Әби, нәрсә ул? – дип сорады колагын шомрайтып тыңлаган оныгы.

– Күке ул, кызым.

– Ватылган күкәй кычкырамыни?

– Күкәй түгел, күке, – диде әбисе аны төзәтеп. – Күке исемле кош.

– Аны очкылык тотамыни?

– Күкенең кычкыруы шулай. Күк-кү, ди.

– Ул ни дип кычкыра?

И алҗытып та куйды соң бу бала! Ул аның соңгы соравына җавап биреп тормады, йоклаганга салышып, күзләрен йомды һәм ничек оеп киткәнен сизми дә калды. Нәрсәдер шартлап ватылган, дөбердәгән тавышка коты очып сикереп торып, түр якка атылды һәм өнсез калды. Идәннең бер ягында чәлпәрәмә килгән Давыт сыны кыйпылчыклары чәчелгән, икенче якта ауган урындыгы белән Гөлчәчәк тәгәрәп ята иде! Йә Аллам! Ярты гасыр сандыгында саклаган Давыты харап булган! Мәскәүгә семинарга баргач, дус яһүде бүләк иткән иде иде бит аны...

Гөлчәчәк исә бәрелгән башы авыртудан елап җибәрергә әзер иде. Тик әбисенең калтыранып елавын күреп, авыртуын онытты, утырган килеш караватына таба шуышты, тиз генә менеп ятып, одеялын башыннан ук бөркәнде...

«Гомерем буе балалар явызлыгыннан интегергә язган икән миңа», – дип уфтанды Рәйсә. Мәктәбен мактап торсалар да, дәрәҗәле исемнәр бирсәләр дә, яшәү җиңел булмады аңа. «Син – директор, мин өйдә бала караучы», – дип, иң элек ире аерылып китте. Улы Рәшит университет тәмамлау белән акча эшләргә Себергә юнәлде. Шул китүдән кайта алмады. Инде ничә еллар өйләнергә акча, фатир алырга акча, дача салырга акча, балаларны институтта укытырга акча дип яши бирәләр. Саниясе сандугач булып сайрады, чикерткәдәй сикергәләде дә утка очкан күбәләк кебек шәһәргә китеп, тормышның төбенә үк чумды. Башта аны кызганган төсле булса да, соңрак елады Рәйсә. Мәктәп директоры кызы бит! Ни йөзең белән халыкка күренәсең, ни йөзең белән укытучыларыңны тәртипкә чакырасың? Гомер буе мәктәптә эшләп, ул бер нәрсәне аңлады: адәм баласын тәрбияләп булмый икән. Аны буып куйган су кебек тота алсаң – тотасың, тота алмасаң, буаңны җимерә дә үз юлы белән китә. Директор чакта аны «Корыч кул» дип йөртәләр иде. Кырыслык, корыч кыршаулар белән кысып кына кешене йөгәндә тотып була. Институтта педагогикадан лекция сөйләүче профессор һәр бала үзе бер цивилизация, ди иде. Җир йөзендә комсызлык, җәберзолым, кан коюлар торган саен арта бара. Аларны бит бүгенге балалардан үсеп чыккан затлар кыла. Моны цивилизация дип буламы соң?

Әнисен дә үз янына алып килә алмады Рәйсә. «Динсез, имансыз нигезгә бармыйм», – диде Мәчтүрә әби, ярым сукыр килеш ялгызы яшәүне хуп күрде. Ул сулкылдаган йөрәген кулы белән кыскан килеш изрәп китте... Йокысыннан күзен ачуга, беренче уе Гөлчәчәк булды. Өйдән чыгып киткәндер, әллә ниләр эшләгәндер дип, аның караваты янына йөгереп килде һәм йөрәге кысылудан туктап калды. Бала, бөгәрләнеп кырын яткан хәлдә, әнисенең теге иске халатын, суыра-суыра, имеп ята иде! Сул кулы белән халатны кысып кочаклаган, уңы белән имә торган турын бөтереп тоткан. Оныгының шул чүпрәкне ничек имүен күргәч, аның күзләреннән мөлдерәп яшь тамчылары тәгәрәде. Балалар дөньяның төмен-ямен авызлары белән татып үзләштергәнне белә иде Рәйсә. Әнә бит, йөзе рәхәтлектән яктырып киткән, бит очлары чокырайган. Саниясенең дә имгәндә бит очлары чокырая иде. Аның йөрәге сикерә башлады, бөтенләй хәле китте. Ул бала янына чүмәште. Төннәрен оныгының авыз чәпелдәткән шикелле тавышын ишеткәләгәне бар иде барын. Әмма мондый нәрсә уйга килерлекмени?! И бичара бала! Аны бит Сания бер ел да имезмәде. Канәгатьләндерелмәгән теләк саклана, күрәсең! Рәйсәнең бөтен калебен кузгатып, бер нечкә хис пелтләп кабынгандай булды. Бу – инде ничә дистә еллар бер генә мәртәбә дә тоймаган хис – бала назлау теләге иде. Ул Гөлчәчәкне иркәләмәкче булып кулын сузды да ялкынга пешкәндәй тартып алды. Оныгын бу илаһи халәтеннән бүлү зур шәфкатьсезлек булыр иде. Ул, тыела алмыйча, тавышын эченә йотып, үкседе дә үкседе.

И бичара бала! Бәләкәч бармаклары, тәпиләре әллә балчыкка, әллә башка берәр нәрсәгә буялып беткән. Рәйсә, иелеп, аның кулларын, аякларын иснәде... Үзе бәләкәй чакта авылдагы төп нигездә үскән шомырт, сәрби куакларының, алмагачларның исен тойды... Гөнаһсыз бала чакларның инде мәңге кайтмаячагын аңлаудан йөрәге сулкылдады... Кинәт бик тә, бик тә кадерлегә әйләнде бу бала аның өчен. Күңеле ярларыннан чыгып актарылды...

Саниянең Усманга сөяркә хәлендә яшәвен белә иде ул. Балага яшь ярым булгач, түзмәде, ныклап сөйләшергә дип, Усманның офисына барды. Кияү булырга тиеш кеше аның ник килгәнен аңлау белән авызын томалады:

– Матурлык бер генә кешенеке була алмый, – диде Усман, үгезнеке төсле кып-кызыл күзләрен аңа төбәп. – Булдыра алган, кулыннан килгән һәркем табигать бүләгеннән файдаланырга тиеш. Мин Соняны укыту өчен аз сумма түкмәдем. Так что квиты. Мин аны кемнәрнеңдер аяк астына салып тапталудан саклап торам. Теләсәгез, бүген үк араны өзәм. Хушыгыз!

Рәйсә төкереп чыгып китте...

Бала күзләрен ачты һәм куркулы тавыш белән:

– Әбием, син мине кыйнамыйсыңмы? – дип сорады.

– Юк, бәбекәччәем, юк, сине нишләп кыйныйм, – дип, Рәйсә оныгын кочагына алды.

Юындыргач, йомырка пешереп бирде. Йомырка Гөлчәчәкнең иң яраткан ризыгы иде. Ул аны бәләкәй бармаклары белән озаклап әрчи, озаклап, тәмләп ашый. Оныгы ашау белән мәшгуль булганда, ул аның урынын җыярга кереште һәм халатны күреп шаккатты. Халат күкрәк турларыннан алып биленә кадәр чәйнәлеп, тишкәләнеп беткән, бүген имгән юеш җире дә тишелеп чыккан иде... Ул халатны юарга дип ишеккә таба атлауга, Гөлчәчәк ашый торган җиреннән, халатка килеп ябышты: «Минеке!» – диде.

– Синеке, бәбекәччәем, синеке! – дип кабатлады әбисе. – Мин аны юып кына куймакчы идем.

– Юма! – дип халатны тагын да ныграк үзенә тартты оныгы.

Халатны бирүдән бүтән чара калмады. Бүген ул Гөлчәчәккә ни теләсә шуңа ирек куйды. Ә үзе исерек кеше кебек йөрде. Әле барып утырды, әле ишегалдыннан урап керде, әле нидер эшләгәндәй итте, әмма башындагы коточкыч уйлары тәмам биләп алып, ниндидер максатчан гамәл кылырга ирек бирмәде. Шушы бичара сабыен яратамы соң ул? Сания белән икесен шәһәргә озатып җибәргәндә, тагын кайтыгыз, дип каласы урында ул ни диде? «Яңадан эзегез булмасын!» – диде. Коточкыч хәл! Оныгын яратса, андый сүзне әйтә алмас иде. Ә үз балаларын яраттымы соң? Бу сорау аның өчен тагын да куркынычрак иде. Ул мәктәп дип чапты да чапты, Рәшит белән Санияне әбиләре тәрбияләде. Бервакыт телгә килгәч, әнисе аңа: «Хыянәтче

син!» – дигән иде. Шул сүзгә моңа кадәр гаҗәпләнеп, җавап таба алмыйча йөргән иде. Менә бүген тапты. Аның үз балаларына хыянәт итүен күздә тоткан икән әнисе! Әйе, ул ике баласына бирәсе назын, йөрәк җылысын мәктәп эшенә алмаштырган булып чыга. Вакыты булмады, чөнки ул ил өчен кирәкле бөек эшләр белән мәшгуль иде...

Мәктәбендәге балаларны яраттымы соң ул? Аларны кырыс таләпләр кысасында тәрбияләргә тырышты – бары шул гына. Бу аның үз гомерендә беренче мәртәбә үз кимчелеген тануы иде... Әйе, ул аларны яратмады! Ул артистларча уйнап, кыланып кына яшәгән булып чыга. Барысына да ул үзе гаепле!

Нишләргә соң? Һич югы менә шушы оныгын коткару өчен ул нишли ала? Ахырда бер нәтиҗәгә килде: баланы үзендә калдырырга! Сания моңа кадәр дә юньләп карамады, моннан соң да карамаячак. Тик оныгы калырмы соң? Ул бит әнә биредә дә шәһәрдәге әнисеннән аерылмыйча яшәп ята. Саниясе ни әйтер?

Аның уйларын шомлы тынлык бүлде. Гөлчәчәкнең «шылт» иткән тавышы да ишетелми иде. Тагын берәр нәрсә эшләгәндер дип, ике арадагы ишектән түр якка атлады. Бала идәннең нәкъ уртасында кыйблага карап утырган да уйга баткан. Аның гәүдәсе бераз иелгән, ирен читләре аска салынган. Сыңар керфеге дә селкенмәгән йөзенә олы хафа иңгән... әйтерсең лә галәм үзәгенә утырган да җиһан әйләнешен күзәтә, тыңлый... Аның каршында шаян оныгы түгел, иңнәренә дөнья гаме баскан олы кеше иде... Баланың эчендә ниләр кайнаганын ни әнисе, ни әбиләре, җир йөзендәге беркем дә белми иде... Бәлкем, ул туачак балаларына һәм үзенә төшәчәк газапларны ерак еллар аша күрәдер... Ни генә булмасын, бу бала явызлык кылу турында уйламый иде. Ул явызлык кылу турында уйлый алмый – бу аның бөтен кыяфәтенә язылган иде. Бусы – Рәйсәнең үз гомерендә икенче мәртәбә гаебен тануы булгандыр...

3

Сания, коточкыч алданганын аңлагач, Усманнан үч алу өчен ридикюлендә кислота йөртә башлады. Бер кичне ресторannан кәеф-сафа корып, машинага төялеп кайтканда, Усманның офис бүлмәсендә ут янганын күреп алды. Җәяү кайтам, күңелем болгана, дип төшеп калды да, офиска килде. Ике сакчы баскыч янында тәмәке тартып тора иде.

– Мине Усман чакырды, – дип алдашты ул.

– Босс исерек хатыннарны чакырмый, Соня. – Сакчылар хахылдашып куйды.

– Мин килгәнне әйтегез!

Сакчыларның берсе кереп чыкты да:

– Босс хәзер безнең арттан киләчәк, әйдә машинага утыр, – диде.

Сүз әйтергә дә ирек бирмичә, машина эченә этеп керттеләр. Саниянең янауларына игътибар да итмәделәр. Бик озак баргач, машина куе куаклыклар каплаган караңгы ташлыкка килеп туктады. Берсе машинадан Санияне сөйрәп алды да сугып җибәрде. Ул ниндидер очлы ташлар өстенә барып төште.

– Әгәр босска тагын берәр шалтыратсаң, шушында мәңге калачаксың!

Сания үзенә суккан сакчыга ташланды, әмма ул аның чәченнән эләктереп алды да дөп итеп йөзе белән ташка бәрде. Сания җылы кан тәмен тойды, һәм барысы да юкка чыкты... Ул больницада операциядән соң гына аңына килде. Алгы тешләренең нибары өчесе калган иде. Усманга якын килү түгел, телефоннан да шалтыратырга ярамаганын хастаханәдә уйлана-уйлана тәмам аңлап бетерде.

...Сания сатучы иде. Яхшы эшләгәч, склад мөдире итеп куйдылар. Кичләрен үзешчәннәр белән моңлы итеп җырлады, ут өертеп биеде. Артыннан егетләр һушсыз булып чапты. Аларның берсенә дә артык сәлам бирмичә, шаярып-үртәп йөргәндә, бер миллион өстенә чыкты. Үлем белән бер иде бу. Саниянең күз яшьләре диңгез булып акты, йокыдан, ашаудан калды. Сәүдә комплексы директоры урынбасары Усман да аның мәхәббәтен яуларга шашынып йөрүчеләр арасында иде. «Бурычыңны түлим, миңа гына бул!» – дип ялынды. Күпкә өлкән булса да, бөтенләй яратмаса да, ризалашырга туры килде. Яши башлагач, Усманның гаиләсе барлыгы беленде. Син сәнгать кешесе, дип, сөяркә аны музыка училищесына кертте. Күп тә үтмәде, дусларының бердәм алкышлары астында Усман аны даһи биюче дип игълан итте һәм сәнгать университетының хореография бүлегенә урнаштырды. Тик аңа укуын тәмамлау насыйп булмады. Кызып китеп, бер профессорга ничек итеп үзенә кул сузуы турында студентлар каршында әйтеп салгач, аны университеттан да, тулай тораклан да куды-лар. Усман бу чакта үз бизнесын ачкан иде, аны ике бүлмәле, бөтен җиһазлары булган фатирга кертте. «Синнән бөтен дөньяга билгеле йолдыз ясаячакмын», – диде. Тормыш тоташ бәйрәмгә әйләнде. Бу фатирдан Усманның дуслары өзелеп тормады, үзе еш кына командировкаларга китеп югалды. Мәхәббәт уеннары ничектер җиңел төс алды. Чөнки һәркайсы ирекле иде... Саниягә тагын бер яңалык ачылды: ул Усманның мәхәббәт агачында сайраган исәпсез-хисапсыз былбылларның берсе генә икән! Бу хакта аңа Усманның дуслары сөйләде. Сания йөккә дә узган булып чыкты. Куркып, Усманнан яшерде. Чөнки ул бернинди бала булырга тиеш түгел, дип, башта ук кисәтте. Аңа әйткәндә, соң иде инде. Усман имчеләргә барырга кыстаса да, Сания курыкты. Балага ике яшь тулганда Усман юкка чыкты. Ниндидер рәсми затлар фатирның офисныкы икәнен раслаучы документларны күрсәтеп, аны баласы белән урамга куып чыгардылар. Сания элегрәк Усманда сак хезмәтендә торган Петрга барып егылды. Ул Санияне чит илгә барып акча эшләүчеләр белән таныштырды. Бөтен тәне татуировка белән тулган Петр егерме елга якын төрмәдә утырган куркыныч кеше булып чыкты. Аңардан качып китеп, ул кемнәрдә генә торып карамады, барыбер шуңа кайтып егылды. Чөнки Сания инде эчмичә тора алмый иде. Ә Петрда эчәргә дә, ашарга да

һәрвакыт бар. Хастаханәдән чыккач та ул шунда юнәлде, аның өченче каттагы фатирына күтәрелгәндә, баскычта туктап калды. Гөлчәчәк белән әнисе күз алдына килде. Аның үтәлмәгән вәгъдәләрен һаман өметләнеп көтүче Мәчтүрә әбисенең моңлы догалары колагында яңгырагандай булды. Юк! Әгәр шушы ишекне ачып керсә, аңа бу якты дөньяга чыгу юлы мәңге ябылачак. Ике әбисен югалтканнан соң, Гөлчәчәге япа-ялгыз калачак... Сания йөгерә-йөгерә баскычтан төште дә, подъезд ишеген ачып, якты дөньяга атлады...

* * *

Капка шыгырдауга, Гөлчәчәк ашап утырган җиреннән сикереп торды да тәрәзәгә капланды һәм әллә нинди сөенечле тавышлар чыгарып ишеккә йөгерде:

– Әни кайтты!

Саниянең йөзен күргәч, Рәйсә имәнеп китте: бу ул да, ул түгел дә иде! Уң як күзеннән иягенә кадәр тирән яра эзе сузылган, күз кабагы йомылып тора. «Кызым!» дип дәшкәндә, Саниянең алгы тешләренең өчесе генә калганлыгын чамалады.

Гөлчәчәк йөгереп барып әнисенең кочагына атылды, битләреннән үпте.

– Исәнме, әни! – диде Сания, Гөлчәчәген коча-үбә.

– Әлегә бер көе, – диде Рәйсә коры гына.

Гөлчәчәк әнисе янында бөтерелә. Аның йөзе шатлыктан балкый, иреннәре туктаусыз елмая иде. Ашап-эчкәч, Сания, арыдым дип, чишенеп тә тормыйча, мендәргә башын салды. Гөлчәчәге дә аның янында тирән сулап йоклап китте.

Айныган, димәк, баланы алып китәргә дип кайткан. Ничек алып калырга соң бу бичара сабыйны? Һава җитмәгәндәй, Рәйсәнең йөрәге кысылып куйды. Кабаланып ишеккә атлады. Инде караңгы төшкән, күктә йолдызлар җемелди, шулай да кояш баешында алсу шәфәкъ әле сүрелеп бетмәгән иде. Салкынча һава сарылудан ул дерелдәп куйды. Ничек алып калырга соң газиз оныгын? Салкын күк йөзе аның эчендә кайнаган утка битараф иде.

Өйгә керсә – Гөлчәчәк, өстәл түрендә туңдырма ялап утыра, Сания мыш-мыш йоклый иде. Рәйсә оныгы янына утырып, акрын гына сүз башлады:

– Кызым, иртән әниең китә торгандыр, син минем янда калырсың бит, әйеме?

Гөлчәчәкнең керфекләре дерелдәп куйды, йөзенә хафалану билгеләре чыкты.

– Ә әни?!

– Әниең тагын кайтыр...

– Ул мине алырга кайткан.

Рәйсә, күңелендәгесен балага әйтергә ярамаганын белсә дә, әйтмичә кала алмады:

– Ул бит сине карамаячак, ашатмаячак. Үзең бит әллә нинди әшәке абыйлар белән чыгып китә дип сөйләдең. Шулай түгелмени?

Бала уйга баткан иде, дәшмәде. Рәйсә, баланы ымсындырып, үз янында калдырырга өметләнә иде:

– Мәчтүрә әбиеңне дә монда алып килербез...

Гөлчәчәкнең йөзеннән якты шәүлә йөгереп үтте дә шундук сүнде.

– Карале, әниең ничек ямьсезләнгән! Авызында теше дә калмаган...

Бу соңгы сүзләрен Рәйсә, нишләптер, иң көчле дәлил дип уйлаган иде. Әмма оныгының йөзенә ярсу билгеләре чыкты. Ул рәнҗешле карашын әбисенә төбәп:

– Минем әнием иң матуры! – дип кычкырды.

Әбисенә телен чыгарып күрсәтте дә, әнисе янына капланып ятты. Аның иңбашлары дерелди башлады, бала тавышсыз гына елый иде...

«Картаеп акыл кермәгән ахмак! – дип сүкте үзен Рәйсә. – Ничек җир күтәрә мине?!» – дип өзгәләнде. Ул үзенә урын тапмады, даруларын эчте, аннары чыгып ишегалдында йөреп карады, әмма иңбашлары дерелдәгән бала күз алдыннан китмәде. Ул елатты аны, ул нәни йөрәген җәрәхәтләде. Өйгә керүенә, Гөлчәчәкнең йоклап китүен күргәч, өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды, урынына барып ятты...

Ул таң белән уянды. Мул итеп табын әзерләде. Санияне ничек тә үзен генә тизрәк автобуска озату иде нияте. Әле вакыт шактый булса да, кызының колагына пышылдады:

– Автобуска соңарасың...

Сания ашык-пошык юынды да, өстәл янына килеп утырды. Йөзендәге яралар тагын да кызарып, иреннәре күкшелләнеп калган иде. Рәйсә кызы кайтканнан бирле башын бораулаган соравын бирде:

– Ни булды сиңа?

– Усманның егетләре кыйнады.

– Ул хәшәрәтнең үзен түгел, исемен онытырга кирәк! – диде Рәйсә, ачуы кайный башлавын тоеп. – Күзең шушылай каламыни инде?!

– Бер-ике айдан ачылачак, диделәр...

Сүз шуның белән бетте. Рәйсә кабат дәшәргә курыкты.

– Уятырга вакыт, – дип кызы кузгалуга, Рәйсә каршына килеп басты.

– Баланы бирмим! – диде ул, гәүдәсе белән калтыранып. – Кая алып китәсең син аны? Үзең кебек имгәтергәме? Бирмим!

Сания туктап калды. Аннары башын аска иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Әни... әгәр кайтсам... пропискага кертер идеңме? – диде.

Рәйсәнең тез буыннары йомшап китте, гәүдәсе чайкалып куйды.

– И кы-ы-зы-ым! – дип сузды ул ниндидер зур музыка коралы кылыннан өзгәләнә-өзгәләнә тибрәлгән моңга охшаш тавыш белән. – Кайта гына күр! Күпме вакытлар көттем мин бу сүзеңне!

Әллә кызын ул кочаклады, әллә Саниясе аның аварга торган гәүдәсен күкрәгенә кысты – кызының күз яшьләре ачысы белән кушылган газиз сулышы ананың колак яфракларына татлы дулкын булып бәрелде. Ишек тупсасына яланаяк баскан Гөлчәчәк, шомырттай күзләрен төбәп, елмаер-елмаймас аларга карап тора иде...

Асия
ЮНЫСОВА

СУГЫШ ЯЗМЫШЛАР БЕЛӘН, БИШТАШ УЕНЫНДАГЫ СЫМАН, АЯУСЫЗ УЙНАДЫ. СУГЫШ ТӘМАМ БУЛГАННАН СОҢ ДА ӘЛЕ КЕШЕЛӘР, ТОРМЫШ КӘРӘЗЕНДӘГЕ ОЯЛАРЫН ТАБА АЛМЫЙЧА, БИК ОЗАК ЙӨДӘДЕ.

БЕЗ ТУГАННАР БУГАЙ...

Татар кызларын сугыш елларында окоп казырга, оборона заводларында эшләргә, торф чыгарырга күпләп алып китеп торганнар. Алар анда тәмам сәламәтлекләрен югалткач кына авылларына кайтып егыла торган булганнар. Бик сирәкләре генә шунда бәхетләрен табып, авылга парлашып яки бәбәй күтәреп кайтканнар.

Гөлчәчәкнең әнисе дә оборона заводында эшләгәндә Башкортстан егете Хәлил белән очраша. Очраша да яратыша. Авылына бәбиләргә кайтканда аны Хәлил озата кайта. «Ярый әле кайтты, йөземне ак итеп калдырды», – дип, Бану аңа гомер буе рәхмәтле булды. Чөнки Хәлил китәр көнне генә Башкортстанда хатыны, улы барлыгын таныган: «Сине бик яратам. Анда хәлне сөйләп аңлатам да кире әйләнеп киләм», – дигән ул. Тик менә килмәгән. Бану аның исәнлеген дә белмичә гомер кичерә.

Күрше урыс авылындагы Марфаны да шундыйрак язмыш сагалаган икән. Аның Николае да, улы Викторны кулына алып бер сөйгән дә, әниләрне кайтып күрәм, дип, Уфасына китеп барган. Һәм кире килмәгән. Карьерда бергә эшләгәндә охшаш язмышлы яшь хатыннар дуслашып китә. Аларның дуслыгы балаларга күчә. Гөлчәчәк белән Виктор өйләнешә. Аларның ике уллары туа.



Өлкән уллары уңган, булдыклы булып чыга. 90 нчы еллар шаукымында ару гына мантып, бизнесын башлап җибәрә. Фабрикалар, кибетләр ача. Кемгә дә таяныч булырлык Задорнов инде ул хәзер.

Бервакыт шул Задорновның ишегеннән бер егет шакый. Кыюсыз гына елмайгалап торганнан соң, егет әйтеп сала:

– Без туганнар бугай.

– Нидән алай уйлыйсыз? – дип сорый Задорнов, шактый кырыс кына. Чөнки акчалы кешеләрнең туганнары табылу гадәтен ишеткәне була аның.

– Мин Задорнов Алексей Вадимович. Ә Сез Задорнов Аркадий Викторович... Әтиләрнең исемнәре дә якын димме. Мин Сезнең сайлау алды листокларын күрдем. Минем бабай Задорнов Вадим Николаевич, Сезнеке Задорнов Виктор Николаевич. Минекеләр Уфада яшәделәр. Сез – Татарстаннан. Ниндидер уртак тамырлар бар шикелле. Бабай вафат инде. Бәлки, безнең ул бабай уртак булгандыр?.. Татарстанда хатыны калган дигән сүзләр ишеткәнем бар иде.

Сәер «кардәш» чыгып киткәч, Аркадий Викторович, әтисе сөйләгәннәрне исенә төшереп утырды. Ятим үскән балачагын тыныч кына сөйли алмый иде ул. Уртак бабай, имеш. Аның бабасы, тиз генә кайтып киләм, дип, Уфасына киткәч, әбекәе аны озак көткән.

Әбисе Марфа таш карьерында таш чыгарган – имеш, улын җитеш тормышта үстерә, тәмле ашата, матур киендерә. Беркөнне ул эшкә барышлый Витюгына матур ботинкалар сатып ала да, карьер куышындагы таш артына яшереп куя. Өйгә кайтырга чыккач, улының ботинкаларын онытып калдырганын исенә төшереп, кире куышка йөгереп керә һәм... шул мизгелдә карьер ишелә. Яшь хатынны таш баса...

Викторны карт әбекәе үстерә. Юклыкта, мохтаҗлыкта. Әбекәй, әлбәттә, булыр-булмас киявен эзләтә белмәгән. Ата тиешле кеше үзе дә эзләп килмәгән.

Бәлки, бу сәер кеше чыннан да Аркадий Викторовичның туганыдыр, Бәлки... Әмма Аркадий Викторович тук тормышта үскән Алексейны хәтта уртак бабай хакына да туган итә алмасын аңлады. Әтисенең ятим балачагы өчен...

Сарман вальсы

Тыңларсыңмы яшьлек хисләремне,
Сарман көйләренә җырласам?
Каршы төшмәссеңме, йөрәгеңне
Мәхәббәтем белән чорнасам?

Минем белән тормыш сукмагыннан
Риза булырсыңмы үтәргә?
Аерылганда вәгъдә бирерсеңме
Кабат кайтуымны көтәргә?

Ашкынулы йөрәк көтә көн дә
Уртак таңның сызылып атканын.
Яшьлегемне җырга салган чакта
Кушылып җырларсыңмы, аппагым?

Кайткан чакта Сарман буйларына
Яннарыңда мәңге калырга,
Кырык эшең ташлап кырык якка,
Чыгарсыңмы каршы алырга?



Чыгар
Тыңлар
Сарман
Каршы
Мәхәбб

Минем
Риза бу
Аерылга
Кабат

Ашкын
Уртак
Яшьлегемне җырга салган ча
Кушылып җырларсыңмы, апп

Кайткан чакта Сарман буйла
Яннарыңда мәңге калырга,
Кырык эшең ташлап кырык я
Чыгарсыңмы каршы алырга?





ЧЫГАРСЫҢМЫ КАРШЫ АЛЫРГА?

Вәзилә, китап сорап килгән соңгы кешене җибәрә дә, тәрәзәгә күз төшереп ала. Инде кич тә җитеп килә, бүген, мөгаен, иптәш кызларында гына кунар, авылга кайтып тормас. Ул монда әле беркемне дә юньләп белми, практикага кайтуына берничә генә атна. Тик беркөнне авылына кайтканда ят егеткә күзе төшә. Сарманнан Яхшыбай чатына кадәр – 12 чакрымлап. Машиналар сирәк йөри. Әрҗәлесенә дә төяләп кайткан чаклары була. Яшь вакытлары бит, егетләр-кызлар уен-көлке сөйләшә, җырлап та җибәрәләр. Арадан берсе җор теле белән аерылып тора. Дамир исемле бу егет белән алар Яхшыбайда төшеп калалар. Аның авылы олы юлга терәлеп кенә тора, ә Вәзиләгә әле байтак кына йә җәяүләп, ат туры килсә, ат белән Салкын Аланга кадәр кайтасы.

Вәзиләнең Дамирны Сарман клубында да күргәне бар. Бер очрашкач, ныклап танышып та китәләр. Егет, укып бетереп, район Башкарма комитетында эшли икән. Кызык, тапкыр сүзле, уен-көлке ярата торган яңа танышы Вәзилә янына үткәндә дә, сүткәндә дә керә торган була. Әлмәт районыннан китапханәгә практикага килгән кызга, шушы егет белән танышкач, Сарман тагын да якынрак булып китә. Дамир бөтен нәрсә белән кызыксынучан егет. Вәзиләгә аның тагын бер ягы ошый: ул шигырьләр дә яза. Язганнары район газетасында да басыла икән. Дамир бер килүендә шул шигырьләрен дә ала. Бергәләп, озак итеп укып утыралар.

Кызның практика вакыты инде бетеп тә килә. Аерылышыр көннәр якынлаша. Кап-кара күзле, кыйгач кашлы, озын чәчләрен артка үреп, матур итеп җыеп куйган бу кыз Дамирга бик ошый. Ләкин бит әле аның армиягә китәсе бар. Салкын Алан кызы аны өч ел буе көтәрме? Алар хатлар язышып торырга вәгъдәләр бирешеп хушлашалар. Дамир чик буе гаскәрләренә эләгә. Ике арада хатлар йөри башлый. Солдат егет күп кенә хатларын шигырь белән дә язып, кызның сагыну тулы йөрәк утларын баса. Май башында, Вәзиләнең туган көне алдыннан, Дамирдан хат килеп төшә. Ачып караса – шигырь. Башына «Чыгарсыңмы каршы алырга?» дип язып та куйган. Вәзилә аны бик ошатып, альбом эченә салып куя. Сүзләре генә ни тора бит:

Тыңларсыңмы яшьлек хисләремне,
Сарман көйләренә җырласам?
Каршы килмәссеңме йөрәгеңне
Мәхәббәтем белән чорнасам?

Бу – 1959 нчы еллар. Вәзилә, практикасын бетереп, укырга китә. Аннан яшь белгечне Нурлат районына эшкә билгелиләр. Язмышыдыр инде, шунда Госман исемле егет белән танышып, кияүгә дә чыгып куя. Ике кызлары туа.

Йөрәген Дамир мәхәббәте белән чорнап яшәргә туры килми килүен, ләкин Вәзилә бу Сарман егетен оныт-мый. Әйе, Кара диңгез ярында чик буйларын саклаганда туган шигырь юллары алга таба мәхәббәтле еллар белән үрелеп дәвам итәргә тиеш булгандыр да бит, ләкин язмышлар без дигәнчә генәме? «Кырык эшең кырык якка ташлап, чыгарсыңмы каршы алырга?» дип сорау куйган Дамирга җавап таба алмаса да, бу шигырьне блокнот битләреннән югалтмый. Җырның, озын гомерле булып, татарның үзенчә бер гимны булып китәсе башына да, күңеленә дә килмәгәндер...

Дамир Гарифуллин Сарман егете Валерий Әхмәтшин *(сулдагы фотода)* белән дус була. Валерий Ленинградта мәдәният институтында укып йөри. Каникулга бер кайтуында ул дустына: «Карале, Дамир, мин әзрәк көйләр дә язгалыйм. Шигырьләрең булса, җибәр», – ди. Дамир аңа бер кочак шигырьләрен сала. Соңыннан булачак композитор бу елларны искә алып: «Безнең тулай торакта килгән почтаны куя торган ящик аскы катта иде. Дамирның шигырьләрен алдым. Арадан берсе шунда ук күңелемә керде. Аны укый-укый, үземчә көй шыңшый-шыңшый, үзебезнең бишенче катка күтәреләм. Менеп җиткәндә, бу көй инде туган иде». Шулай итеп, 1963 елда «Сарман вальсы» дигән җыр дөньяга килә. Аны иң беренче итеп якташлары, Яңа Бүләк авылы егете Илһам Шакиров башкара. Җырчы кайда гына чыгыш ясамасын, аны репертуарыннан төшерми.

Бу җыр белән бәйле тагын бер вакыйга истә калган.

Бер елны Әлмәткә конкурска барган идек. Дамир абый Гарифуллин ул чакта – «Сарман» дип йөртелә торган район газетасы редакторы, мин – җаваплы секретарь. Соңыннан каләм осталары, типография кызлары, биеп-җырлап, рәхәтләнеп күңел ачтылар. Безнең яратып җырлый торган «Сарман вальсы»на да чират җитте (аннан башка нинди мәҗлес булсын инде!). Дамир абый үзе кушылып җырламады, елмаеп, тыңлап кына торды. Шулай да ахырда янда утырган бер кызга: «Бу бит минем җыр», – дип әйтеп куйды. Теге кыз, гаҗәпләнеп, моны иптәшенә әйтте. Бөтен республикадан килгән яшь-җилкенчәк, җыр авторының үзләре арасында утыруын белгәч, «Сарман вальсы»н дәррәү күтәреп алды.

Шулай итеп, Дамир-Вәзилә мәхәббәте, дәртле-өметле моңга күчеп, күпме еллардан бирле җыр дөньясын әйләнеп йөри. Дамир абый белән бер очрашканда, Вәзилә турында да сорадым. Ул озак еллар ире белән Себердә эшләп кайта. «Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемне алып, лаеклы ялга чыга. Хәзер Лениногорск шәһәрендә яши икән. Беренче ире вафат булгач, икенче тапкыр кияүгә чыга. Наил исемле бу кеше белән дә озак яшәргә туры килми, ул вафат була. Дамир абый, күп еллар үткәч, Вәзилә апа белән очраша. Хәзер дә телефоннан сөйләшеп, хәл белешеп торалар. «Ике ирем дә, Аллага шөкер, әйбәт, сабыр кеше булдылар, – дип сөйләгән аңа Вәзилә апа. – Тик өйдә мин берәр нәрсәдән ризасызлык белдерсәм, икесе дә: «Дамирыңа чыгасың калган», – дип әйтәләр иде. Алар безнең мәхәббәт турында каян белгәннәрдер, әйтә алмыйм. Бәлки, бу җырның миңа аталып язылуын үземнән ишеткәннәрдер».

Рәйхана МИРСӘЕТОВА.
Сарман.

СУГЫШ. КҮПМЕ КАЙГЫ-ХӘСРӘТ, АЧЫ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ, НӘФРӘТ БЕЛӘН СУГАРЫЛГАН БУ СҮЗ. СУГЫШ КИТЕРГӘН БӘЛА-КАЗАЛАР МӘҢГЕ ОНЫТЫЛМАСЛЫК!

Сөйгәннәрне парларыннан аерды, хатыннарны тол калдырды, гөнаһсыз сабыйларны ятим итте ул! Инде менә сугыш беткәнгә дә 70 ел вакыт узып киткән, ә хатирәләр һаман истә.



ОНЫТМА, КЕШЕЛЕК!

Мин 1941 елның июнендә Каенсар урманындагы колхоз лагерендә идем. Ул вакытта Каенсарда ике лагерь эшләде. Берсе – районныкы, икенчесе колхозчы балалары өчен иде. Сугыш башлану турындагы хәбәрне ишеткәч, әтине сугышка алып китсәләр, күрми калырмын дип, лагерьдан качып кайтып киттем. Дөрес, артымнан ук лагерьның ул вакыттагы хуҗалык мөдире Хәйруллин Кәрим абый килеп, мине кире Каенсарга алып төшеп китте. Мин карышып тормадым, чөнки әтигә әле сугышка алыну турында хәбәр килмәгән иде. Шул вакыттагы сөенгәнемне бер үзем генә беләм!

Тик ул сөенеч әллә ни озакка бармады шул. Сугыш башланып озак та үтмәде, Мөнәвәрә исемле 5 яшьлек сеңлемне җир куенына салдык, ә 7 айдан соң әтиебезне сугышка алдылар. Моңарчы гаиләбездәге тугыз баланың дүртесен җирләгән идек инде.

1942 елның 15 гыйнвары. Бу көнне мәңге онытасым юк. Урамда тешне сындырырлык салкын иде. Ә безнең өйдә җылы. Әти мичкә яккан, әни тыныч кына кичке ашны хәстәрләп йөри. Мин урын өстендә авырып яткан Гыйлемхан абыем янында утырам, 3 яшьлек энем Камил гел әти янында мәш килә. Өйдә авыр тынлык. Әни, тамып төшкән күз яшьләрен безгә күрсәтмәскә тырышып, алъяпкыч чите белән күзләрен сөрткәләп ала. Абый белән без барысын да аңлыйбыз – иртәгә әтиебез сугышка китә. Әнине борчымас өчен еламаска тырышып карыйбыз, тик күзебездән бертуктаусыз яшь ага да ага. Энебез Камил генә берни аңламый дисәк, ул да нәрсәдер сизенгән кебек, бер дә әти яныннан китми. Әти ниләр кичерде икән ул көнне? Ара-тирә әнигә күз ташлап, безнең күңелне күтәрергә теләп, нидер сөйләгән, шаярткан булды. Уен-көлкеле кеше иде шул. Әти, әти... Үзе белде микән гаиләсе белән соңгы тапкыр бергә булуын? Әллә эчтән генә безнең белән хушлашып утырды микән? Шул кичне безгә сөеп караган күзләрендә күпме моң-зар иде аның... Аерылу ачысыннан өзгәләнгән күңеле барыбер үзенекен итте, түзмәде, кулына тальянын алып, җырлап җибәрде:

Аклы ситсы күлмәгеңне
Көн дә киеп каралтма.
Мин китте дә бетте диеп,
Балаларны таратма...

Бу вакытта әни ничек түзде икән?! Тугыз баладан исән калган өч газизе һәм туачак сабые белән ялгыз каласын күңеле сизенде микән...

Иртән-иртүк әти безнең белән хушлашып, сугышка китте. Аны озатырга әни берүзе генә барды. Мин бик теләсәм дә, әтине озатырга бара алмадым – авыру абыем һәм кечкенә энемнең үзләрен генә калдырасым кил-

Фото интернеттан алынды

мәде. Әти белән әни өйдән чыгып киткәч, абый белән икебез тыела алмыйча, үксеп-үксеп еладык. Шул көннән соң әтиебезне башка күрмәдек. «Әти» дип дәшәр кешебез калмады. 1942 елның 16 гыйнвары безне яраткан әтиебездән аерды. Без әтисез яшәргә өйрәнә башладык.

Һәр гаилә үзе булдыра алганча яшәргә тырышты. Бераүгә дә җиңел булмады. Тешне кысып түздек. Фронттагыларга безгә караганда да авыррак икәнен һәркем аңлый иде. Фронт өчен, җиңү өчен диеп тырыштык. Әтиләребез, туганнарыбыз исән-сау әйләнеп кайтсыннар дигән теләк безне көчле итте.

Яңа көн туган саен әтидән хәбәр көттек. Тик бер генә хаты да килмәде шул. Иң курыкканыбыз рас килде. Безнең өй бусагасын да кара кайгы атлап керде – 1942 елның март аенда әтинең үлеме турында хәбәр алдык. Шул көнне дөньяның асты өскә килгәндәй булды, өй эчен шомлы бушлык биләп алды. Әниемнең үксеп-үксеп елавы бүгенгедәй күз алдымда. Үзе елый, ә үзе, инде толлык ачысы кереп урнашырга өлгергән куенына кысып, мине юатмакчы була: «Түзәргә кирәк, балам, түзәргә кирәк», – дип башымнан сыйпый. Ничек түзәргә соң?! Әти бит бүтән беркайчан да елмаеп кайтып кермәячәк, беркайчан да тезләренә утыртып безне сөймәячәк... Күңелдәге бу уйларны ничек итеп әнигә аңлатасың инде, аның йөрәге болай да яралы бит.

Әни белән икебезне ярсып елаудан бишектә яткан бер айлык Фәрит энемнең шыңшып-шыңшып алуы гына бераз айнытып җибәргәндәй булды. Әти сугышка киткәч туган сабый да иң якын кешесен югалтуын аңлаган, күрәсең. Шул гөнаһсыз бала хакына яшәргә көч таптык. Тик кыска гомерле булды шул ул да. 1 нче сыйныфка керәсе елны якты дөньядан китеп барды.

Әтинең үлгән хәбәрен алган көннән, кайгыларны эчкә йотып, әни белән сабыр гына авыр тормыш йөген тарта башладык. Язмышның безгә тагын бер сынау әзерләгәнен белми идек әле. Кара кайгы алып килгән март аен ачы сагыш тулы апрель алыштырды. Каты авырудан соң, 16 яшьлек абыем мәңгелеккә күзләрен йомды. Кайгы өстенә кайгы, хәсрәт өстенә хәсрәт өстәлде. Сындырып сынады язмыш, әмма сабыр булдык, чыдадык. Түзде әнием, бирешмәде. Безне, исән калган өч баласын, кеше арасында ким-хур итмичә, аякка бастырды.

Еллар уза торды, сугыш дип тормыш тукталмады. Яшисе бар бит. Мин дә, әнигә булышу өчен, 12 яшьтән колхоз эшенә чыккалый башладым. Эшче-крестьяннар мәктәбе (РКШ) янында «Пищепром» дигән оешма бар иде. Анда төрле ризыклар пешереп саттылар. Шул оешма карамагындагы басуларда олы апалар белән бергә җир казу эшләрендә катнашып йөрдем. 14 яшем тулгач, мине өшәнгән атлар карарга куйдылар. Ничек ышанып тапшырганнардыр ул 24 атны, әле дә исем китә. Аларга Кизләү чишмәсеннән су ташып эчерә идем, атны Җаббаров Шакир абый җигеп бирә иде. Башта су эчермәсәң, атларга якын да киләм димә. Әмма якын килмичә булмый, аларның корчаңгы баскан тәннәренә гел дару сөртеп торырга кирәк. Авыру атларны караган шул вакытлар исемә төшсә, әллә нишләп китәм. Үзем кечкенә, атларга дару сөртү өчен буем җитми. Шулай азапланганымны күргәч, Шакир абый бүкәннәр әмәлләп бирде. Шул бүкәннәргә басып, атларны майлый идем. Бер елга якын атлар караганнан соң, мине башка эшкә күчерделәр. Моңа ул вакыттагы милиция начальнигы Хөснетдинов Абдулла абый сәбәпче булды. Ат җигеп, чишмәгә суга килгәнемне күргән иде ул. Шул очрашудан соң күп тә үтмәде, мине әвен сугуга күчерделәр. Шунда эшләгән җирдән 1944 елда Казанга ФЗУга җибәрделәр. Җитен комбинатында киндер сугу станогында эшләдем. Сугыш бетү турындагы хәбәрне комбинатның Кызыл почмагында ишеттем. Ул вакыттагы хисләрне сүз белән генә әйтеп, аңлатып буламы соң?!

1946 елның җәендә туган авылым Олы Әтнәгә әнием янына кайтып, 1947 елның декабрендә почта бүлекчәсенә эшкә урнаштым. 4 ел хат ташучы булдым, 15 ел «Союзпечать» киоскында эшләдем. 1966 елда аралау бүлегенә күчеп, 1991 елга кадәр шунда хезмәт куйдым.

Балалар кайгысыннан айнып та бетмәгән әниемне каһәр суккан сугыш сөекле иреннән, безне кадерле әтиебездән аерды.

Сугыштан соңгы еллар да бик авыр иде. Әмма иң авыры сугыш калдырган күңел җәрәхәтләре булгандыр, мөгаен. Гомеребезнең иң матур чорында без әти яклавына тилмереп үстек. Әтине төштә күреп уянсак та, шатлана идек. Әниләребез исә җиләк кебек чакларында тол калып, ялгыз тормышның бар ачысын татып яшәделәр. Күбесе газиз ирләренең кайда ятып калганын да белмичә, якты дөньядан китеп барды.

Без дә бик озак еллар әтинең кайда җирләнгәнен белә алмадык. Төрле җирләргә яза торгач, ниһаять, 1990 еллар башында Казан шәһәренең 79 нчы мәктәбе каршындагы «Поиск» группасыннан хат алдым. Анда әтинең 445 нче медсанбатта хезмәт иткәнлеге һәм яу кырында алган тән җәрәхәтләреннән вафат булганлыгы турында язылган иде. Әтинең каберен дә эзләп тапканнар. Әтием Сәфәргалиев Әхмәтхан Сәфәргали улы Смоленск шәһәрендәге мемориаль комплексның 2 нче туганнар каберлегендә җирләнгән. Шул хатны алгач, әти белән очрашкандай булдым. Ничә еллар күңелемә тынгы бирмәгән сорауларга җавап тапканыма да куандым. Газиз әтиемнең исеме Туганнар каберлегенә куелган истәлек тактасында мәңгеләштерелгән.

Фатыйма БӘШИРОВА.
Биектау.

Игътибар! Сугыш кырларында хәбәрсез югалган туганнарыгыз турында мәгълүмат табарга теләсәгез, сайтыбызга (www.syuyumbike.ru) мөрәҗәгать итегез. Андагы махсус тәрәзә аша Бөек Ватан сугышы мемориалына кереп, якыннарыгызны эзли аласыз.



Асия СӘГЫЙТОВА

Кулына кичә генә өлгергәнлек аттестаты алган 18 яшьлек кызның уенда уку иде. Университетка керү! Сирень чәчәк аткан бакчаларда сер сөйләшкәндә хәйләсез кыз бала егетенә күңелдәге уйларын, хыялларын ачмый каламыни инде? Егет аны сабыр гына тыңлый торган иде. Үзе һаман уйлана...

Фото интернеттан алынды

СИН КИРӘК МИҢА

Айсылу елап уянды.

Рәсәф аны үзе белән алып китмәде. Югыйсә Айсылу инәлеп-инәлеп ялварды бит аңа төшендә: «Мин дә синең белән барам. Калмыйм синнән. Бер киткәч, кайтмыйсың син», – дип тезде генә.

Рәсәф Айсылуга җавап бирмәде. Алып та китмәде. Фәкать моңсу елмаеп кына торды. Айсылу аның җитен төсендәге чәч дулкыннарын сыйпамакчы булып үрелгән генә иде, уянып китте. Елый икән.

Уянгач та әле озак үзенә урын таба алмады. Аерылу ачысына гарьләнү тойгысы кушылды. Аннары боларның бөтенесен үпкәләү кебек кызлар өчен аеруча хас булган самими кичерешләр алыштырды.

Кырык ел узганнан соң үткәндәге мәхәббәтеңә нинди үпкәләү ди инде?! Айсылу да, Рәсәф төсле үк итеп, моңсу елмаеп куйды. Кара син аны, алып китмәде, ияртмәде бит! Себердәге алтын рудникларына китәргә җыенган Рәсәфкә ияреп китү югыйсә ул чакта да кызның уенда юк иде.

Айсылуның максатын яхшы белгән һәм бу максатка ирешү юлында аңа комачау итәргә теләмәгән Рәсәф үз ниятен кызга тагарга базмады да бугай. Нияте исә кинәт кенә беленде. Өйдә плащын салганда караса, кесәсеннән язу чыкты. Рәсәф аның белән шул язу ярдәмендә аңлаша икән. «Якутиягә китәм. Ә син укырга кер. Мин бер елдан кайтырмын. Иртәгә мине озатырга кил. Көтәм!» Язу русча иде. Чөнки бала вакыттан ятим калган Рәсәф Волгоградта ятимнәр йортында үскән. Шәһәр тәрбиясе алган. Авылдагы йорт нигезләре исән иде әле. Исән генә түгел, шул нигездә аның абзый тиешле кешесе гаиләсе белән яшәп ята.

Армияләрдә хезмәт иткән, олыгаеп баручы егеткә абый белән җиңги янында яшәү бик уңайлы булмагандыр инде. Үз оясын кору, үз нигезен булдыру турында хыяллангандыр Рәсәф. Айсылу менә хәзер – кырык елдан соң шулай акыллы итеп уйлый.

Ул чагында фәкать бертөсле генә уйлады: китә!

Озатырга килде, әлбәттә.

Автобус тукталышында торган кешеләрнең йөз күзе карап торган җирдә нинди озатышу ди инде ул! Куллар

кысыштылар да – шул! Хат алышырбыз, диештеләр. Кыз егетнең маршрутын сорады. «Волгоград аша», – диде. Шушы: «Волгоград аша» дигән җөмләнең шул кадәр мөһим булырын ул чагында кем белгән?!

Китте.

Элек тә кайтканы да, киткәне дә булган Рәсәфнең. Бер кайтуында Айсылуны – үсмер кызны хәтерләп тә калган икән. Егетнең үзен исенә төшерә алмаса да, вакыйгасын Айсылу да хәтерли. Район Сабан туена барырга җыенганнар иде. Авылга кечкенә автобус килгән булып чыкты – ярты халык сыймады. Айсылу да утыра алмый таптана. Шул вакыт кемнеңдер көчле куллары кызыкайны күтәрде дә ачык тәрәзәдән автобус эченә утыртып куйды. Менә шул куллар Рәсәфнеке булган икән. Менә шул куллар Айсылуга гомер буе җитмәде...

Җитмәгән нәрсәләр күп булган икән. Әйтик, Себергә китәргә җыенган Рәсәфкә, төшендә инәлгән кебек үк итеп булмаса да, бер сүз әйтү җитмәгән. Нибары бер сүз: «Китмә!» Нишләгән булыр иде икән? Югыйсә егет тә Казанга килеп укырга яки эшкә урнаша алган булыр иде. Иде, иде, иде... Булмый калган шул инде.

Айсылуның җәе хат көтеп үтте. Хат кышкы имтиханнар вакытында гына килде. Барып урнашканчы, «Адреслар өстәле» аша кызның адресын тапканчы ярты ел вакыт үтеп киткән. Ник китү белән язмаган хатны? Ник авылдашын «Адреслар өстәле» аша эзләтеп вакыт әрәм иткән. Адрес юнәтүнең ансатрак юлы да бар бит югыйсә: дус кызлар, сыйныфташлар... Хәер, авыл кызының оялчанлыгын аягандыр инде. Бервакыт киногa кергәндә егет, шәһәр гадәтенчә, икесенә дә билет алгач, кыз коелып төшкән иде. Янәсе, хәзер аларның серен бөтен кеше белә бит инде. Авылда кем кызының кем малае белән очрашып йөрүен белүдән дә кызык яңалык юк лабаса. Озатканда кул кысышудан уза алмауның да сәбәбе шул – авыл әдәбе.

Хат озын иде, әйбәт иде. Рәсәф Җир шарының иң салкын ноктасына барып эшкә урнашкан икән. «Сине үзем укытырмын. Акча җибәреп торырмын», дигән сүзләре хәзер булса, бик тә кирәкле, мәгънәле, өметле сүзләр кебек тоелыр иде. Әмма Айсылу университетта укыган елларда «акча мәсьәләсе», гомумән акча турында сүз куерту ваклык кебек тоела иде. Айсылуга нигә акча? Ул бит стипендия ала! Аның өчен мөһим мәсьәлә бүтән: Рәсәф Волгоград аша китте. Ә аның анда армиягә киткәнче очрашып йөргән Галинасы бар. Җавап хатында беренче мәхәббәте уңа төшкән Айсылу, кыюланып, Галинаны егетнең исенә төшерде.

Рәсәфнең икенче хаты да әйбәт иде. Әмма ул кызның шикләнүләрен раславы белән Себер белән Казан арасында йөрергә тиешле хатлар юлын кисеп куйды. Айсылу икенче хатын кыска тотты: «Егетем бар!» Югыйсә егете юк иде әле.

Инде менә кырык елдан соң төшендә күреп, елап уяна!

Көне буе алгысаган йөрәгенә урын таба алмады Айсылу. Еракта калган җәй үзәген өзеп сагындырды. Капка төбендәге эскәмиядә утырып таң каршылаганда икәү әкрен генә җырлаган җырларны исенә төшереп көйләп йөрде:

Җылы яклардан җилләр иссәләр,
Тәрәзәмне ачып куярмын.
Сагынмый ул, кайтмый дисәләр,
Мин җилләрне кире куармын...

Китте. Кайтмады. Җилләрне кире куганмындыр, күрәсең. Көне буе кинәт уянган хисләреннән иләсләнеп йөргән Айсылуның кинәт кенә зиһене яктырып китте.

Рәсәф дөньяда юк ич инде!

«Рәсәф үлгән икән... Озак авырган». Моннан биш еллап элек Сабан туена кайткач ишетеп килгән хәбәр иде бу. Исән түгел ләбаса аның Рәсәфе. Димәк, төшендә Айсылуны үзе белән ияртмәве, «Син яшә әле!» – диюе. Ярый әле ияртмәгән. Оныклар үстереп яткан Айсылуга һич тә үләргә ярамый. Рәхмәт Рәсәфкә. Ияртмәгән, үзе белән китәргә чакырмаган өчен. Миһербанлы, бик тә юньле кеше иде шул. Айсылуның юлында очраган ир затлары арасында аны кадерле, саклый белгәне, ир-атларга тиешле сыйфатларга ия булганы ул иде. Аның белән гомер кичергән хатын бәхетле булгандыр. Урыны оҗмахта була күрсен.

Тора-бара төш уяткан сагыш басылды.

Сабан туйларына соңгы кайтуларда да Айсылу ханым яшьлектәге ахирәт дуслары белән дә Рәсәф хакында сүз кузгатмады. Өлкән яшьтә яшьлектәге мәхәббәтләрне сөйләшеп утыру килешми дә торгандыр инде ул.

Менә тагын авылына кайтып бара. Авылда тагын Сабан туе. Кайтучылар күп булыр. Менә янәшәсендә утырган кызыкай да Сабан туена дип кайтып киләдер. Юлдашларның сүзе тиз ялгана. Кем кызы икән бу? Күзләре бик тә таныш кебек. Авылга сирәк кайтылгач, шәһәрдә яши башлавына да күп еллар узгач, Айсылу авылдашларын танып бетерми. Ярый әле кызыкай сүзчән булып чыкты. Кем кызы, кем нәселе икәнлеге дә беленде. Рәсәфнең абзасының кече кызы икән бит бу инде ханым булган кызыкай.

Айсылу тәки сүз җаен тапты. Тегене-моны сораштырган булды. Абзаларының язмышын белеште. Һәм үзе өчен бөтенләй көтелмәгән яңа хәбәр ишетте. Алтын руднигында эшләүчеләр алтын бөртеге табылганда тәгаен шулай шатланалар булыр. Рәсәф үлмәгән икән бит! Сәламәт булмаса да, исән икән. Исән бит ул! Исән генә була күрсен!

Күңел дәрьясы тагын чайпалды.

Биш кенә минутка булса да, бер күрешәсе иде. Эх, исән икәнлеген теге төшне күргән вакытта ук белгән булсамы? Ун ел элек! Ун ел гомер бит ул. Ун ел буе дөньяда Рәсәф бар дип яшәгән булыр иде Айсылу.

Бер күрешеп сөйләшергә, хәл белешергә, бергә-бергә яшьлекне сагынырга инде соңмы?

Мөгаен, соңдыр. Аннары ул бит Волгоград аша киткән иде...

16+

КАРАШЫҢ СИХЕРЛЕ, СӨЙКЕМЛЕ...



Җәүдәт СӨЛӘЙМАН, шагыйрь һәм галим, техник фәннәр докторы, профессор, «Сәләт» проекты җитәкчесе; өйләнгән; гаилә стажы — 34 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күз карашына!

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Син «ә» дигәндә «җә» дип тормавын.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Авыр сорау: әмма җавабы гади – алдавын.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Минем өчен ул бер зат – минем хатыным. Дөрес, икегә дә бүлеп карый алам, әмма андый берьяклы хатын белән озак тора алмас идем.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Кайчан, кайда, ничек, нинди шартларда, нинди сүзләр белән булуына кадәр хәтерлим... Казан дәүләт университетының 6 нчы тулай торагы янында булды бу. 1981 ел, апрель ахыры. Венера мехматның IV курсын тәмамлап килә, мин – аспирант. Инде дүртенче ел мәхәббәт ялкынында янам... Көн саен шигырьләр язам, күңелемдә дә, телемдә дә, өнемдә дә, төшемдә дә ул гына. Ә Венера... уйлап та карамый кебек тоела. Шул ук вакытта өметне өзәрлек итеп, катгый кистереп «юк» дип тә әйтми. 1 Майга әтисенең туган көненә Уфага кайтырга җыена иде ул. Кич җитеп килә, тирә-юнь инде яшеллеккә күмелгән, кошлар сайрый... Мин бөтен ихтыяр көчемне җыйдым да, һөҗүмгә күчтем: «Мин сине яратам, синнән башка яши алмыйм... Күрәсең бит, көннәрем сине уйлап, сине көтеп уза. Фән турында уйлый да алмыйм – аспирантурам җәһәннәмгә оча бугай. Синнән башка миңа бернәрсә, беркем кирәк түгел! Кияүгә чык миңа! Уфага кайткач, әти-әниең белән сөйләшеп кил, аларның ризалыгын сора». Бу мәлдә аның мондый көтелмәгән һөҗүмнән аптырап, югалып калганын күреп, авыр артиллериямне эшкә җиктем: «Әгәр ризалашмыйсың икән, бөтен ихтыяр көчемне җигеп, синнән китәчәкмен, әлбәттә. Хәзер минеке булмасаң, мәңге минеке булмаячаксың инде син – бишенче курсны тәмамлагач, китеп барачаксың. Ә мин ярык тагарак янында утырып калачакмын. Биш ел гомерем юкка чыгачак дигән сүз... Әмма белеп тор, синең ялгышуыңны исбатлау өчен бөтен гомеремне багышлаячакмын!» Әле куркытып та куйдым: «Махсус эзләп, эзәрлекләп йөрмәм, әмма синең ирең минем кул астында эшләсә, үпкәләмә – мәрхәмәт күрмәячәк». Белмим, кайсы дәлилем көчлерәк булгандыр, әмма августта без инде матур гына гаилә корып җибәрдек.

Әгәр бүген шул вакытка кайтып, яңадан тәкъдим ясап булса, мондый эгоист булмас идем. «Мин сине бәхетле итү өчен бөтен гомеремне багышлармын», – дияр идем... Әмма ул чакта бу сүзләр үтемле булып яңгырар иде микән дә, туйларга барып җитеп булыр идеме икән? Монысы икеле...

6 Ир кеше, хатын итеп, әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...

– Мин дә шул фикердә. Дөрес, мәхәббәт килгәндә ул хакта уйламыйсың. Әмма күп очракта, аеруча бәхетле гаилә корып яшәүчеләрдә, бу үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Әни безнең туй карточкасын бер очрашуда курсташларына күрсәткән. Аңардан: «Кызың – нәкъ үзеңнең яшьлегең, ә киявең (ягъни мин – улы) кайсы яклардан соң?» – дип сораганнар. Монда психология дигән нәрсә дә үз ролен уйныйдыр. Үзенә, үз туганнарына охшаган киленне кайнана да, туганнар да якынрак кабул итә, күрәсең.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Хатынына ярдәм итәргә, өйдәге эшләрдән йөз чөермәскә – гаиләне кемдер алып барырга тиеш бит. Әмма бу бик нечкә, четерекле вариант. Хатын бу очракта бик әйбәт психолог булырга тиеш: эштәге гадәтләрен өйдә чыгармаска, иренә ихтирамын гел күрсәтеп торырга кирәк аңа. Ә читтә исә үзенең ир хатыны икәнлеген онытмаска, ире турында сүз чыга калса, аның абруен югары тотарга тиеш ул. Югыйсә мондый гаилә озак яши алмас. Аеруча безнең татар гаиләләре. Гасырлардан килгән традицияләрне бер-ике буында гына үзгәртеп булмыйдыр.

8 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бик үк хупламыйм. Башта егеттән әйттерергә кирәк дип саныйм. Алай гына да түгел, гаилә коргач та, «яратам»ның күбрәк ирдән чыгуын, ә хатыннан сирәгрәк ишетелүен хуплыйм: күп-күп «яратам»нарга җавап итеп, әллә нигә бер генә, сагындырып кына әйтсен ул аны.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

– Хатын-кызның да төрлесе бар: берәүләрен акча, икенчеләрен буй-сын, өченчеләрен, бәлки, хәтта машина, кием дә җәлеп итәдер. Әмма күбесен, минемчә, егәрлек җәлеп итә. Ягъни энергияле, көче ташып торган, мескен булып утырмаган, нык, сәламәт яңа буын тудырырлык егетләр дип уйлыйсы килә.

10 Хатын-кызның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Ир-егеткә хас сыйфатларыма. Дөрес, хәзер инде андый игътибар кирәк тә түгелдер. Әмма үз вакытында, әле генә әйтеп киткән егәрлек миндә дә юк түгел иде кебек.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр.

– Бәлки, кемнедер куркытадыр, әмма бу миңа карата әйтелгән сүз түгел.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.

– Мантыйк дигәндә, ул берүктер инде, әмма хатын-кыз, минемчә, күбрәк мантыйк белән түгел, хис белән яши, шуңа да кайчакларда мантыйгы чуалгалыйдыр. «Беренчедән, мин ул әйберне алмадым; икенчедән, аны урынына кайтарып куйдым». Менә бу сүзләрне күп очракта хатын-кыз логикасына мисал итеп күрсәтәләр. Бу мисалны искә төшергән очракларга мин дә тап булгалыйм.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Мин дә ир-ат белән хатын-кыз икесе ике планетадан дип беләм – үзара аңлаша алмау еш килеп чыгып тормас иде... Әмма ник шулай килеп чыкканын аңламыйм дип әйтә алмыйм. Ул күп очракта җенескә түгел, холыкка бәйле. Шулай ук ир белән хатын өчен берсенең – авылда, икенчесенең шәһәр мохитендә үсүе дә гаилә тормышында үзен нык сиздереп торучы фактор дип күрәм. Хатын-кыз белән эш бүлешү дигәндә бу аеруча сизелә. Әйтик, савыт-саба юу, өйне җыештыру кебек эшләр, миңа, авыл малаена, ераграк гамәлләр. Венера моны хәзергәчә аңламый. Мин аның чисталыкпөхтәлеккә табынуын аңлый алмаган кебек. Мин, мәсәлән, носкиларның диван янында – салган җирдә ятуларын җайлы саныйм. Дөрес, моның белән ул беркадәр инде килеште кебек. Әмма эш бүлмәмдә, аның күзлегеннән караганда, тәртип гел юк. Моның ахыры минем яктан һәрвакыт күк күкрәтүләр белән бетәсен белсә дә, нигәдер, анда вакыт-вакыт барыбер үзенчә тәртип урнаштырып чыга. «Тәртипсезлекнең дә үз тәртибе була», дигән кагыйдә аның планетасында, күрәсең, гомумән, юк бугай.

14 Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?

– Бүген, 34 ел бергә яшәгәннән соң, күбрәк юл куямдыр. Элегрәк төрлечә булды, хатынның туксанына үз туксанымны кушып булышкан чаклар да бар иде. Туксанга туксан каршы чыкмаганда бу куркыныч түгел, үтә дә китә. Ә тора-бара, башта килешеп, аннары бераздан үзеңнекен исбатларга тырышканда җилләр йомшаграк булуын аңлап эш итәсең.

15 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин ардым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Бу безнең гаилә өчен табигый түгел. Әмма фаразлап карасак, мин кафега чыгып китү яки пиццага заказ бирү вариантын сайлар идем. Хәер, ни дәрәҗәдә ачыккан булуыма карап инде, чөнки үзем дә йомырка тәбәсе генә кыздыра беләм.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Бу мәсьәләдә безнең гаиләдә хәлләр киресенчә: Венера әллә кайчан әзер була, мине көтә, ә мин ахырга кадәр нәрсәдер эшлим, язам-укыйм... Алдан барып куярга яратмыйм, хәтта аэропортка да.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Минем беркайчан да бүләк алганда ул күзлектән караганым юк. Нәрсә бирсәләр дә ошый. Хикмәт бүләктә түгел, игътибар күрсәтүдә дип саныйм. Иң зур бүләк – китап дигән гыйбарә белән 100 процент килешәм.

ХАШИМИД ПАТШАЛЫГЫ





Рәмзия КАШАПОВА

КАРТЛЫК ХӨРМӘТКӘ ЛАЕК! ӨЛКӘН КЕШЕЛӘРНЕ МИН НИНДИДЕР ҮЗГӘ БЕР ЯРАТУ БЕЛӘН ЯРАТАМ.

Әнием инде бик күптәннән бирле Мисырдагы пирамидаларны барып күрергә хыяллана иде. Кайвакыт кешеләрнең хыялларын тормышка ашырырга яратам мин – үзеңне тылсымчыдай хис итәсең. Бу сәяхәтебез бик тә үзенчәлекле булды әле безнең. Үзебез белән әниемнең дус «кызларын» да иярттек. Алар файдалы белән күңеллене бергә бәйләп, үзләре кызыксынган белән кызыксынучылар төркеменә берләштеләр.

Күз күрмәгән җирләр һәм андагы тарихи ядкарьләр ымсындыра безне. Алар саклаган серләр кызыктыра. Африка илләрендә күп тапкырлар булганым бар: Мисыр, Тунис, Марокко... Шулай булса да, һәр барганымда үзем өчен яңалык ачып кайтам. Бер баруда барысына да җитешү өчен, без Мисырга барышлый юл уңае башка илләргә дә сугылып чыгарга ниятләп, юлламаның шундыен алдык. Һавага Казанның үзеннән күтәрелдек.

Мисыр безне, гадәттәгечә, кайнар кояшы, һава аланында ыгы-зыгы килгән гарәпләре һәм кунакханәдәге ачык йөзле хезмәткәрләре белән каршы алды. Безне тиз һәм уңайлы итеп урнаштырдылар. Без тукталган отельнең тирә-юне, һәрвакыттагыча, тәртипле һәм чиста, яшеллеккә чумып утыра. Ашау-эчү дә юлдаш ханымнарымның таләпләренә туры килердәй. Әнием һәм аның дус «кызлары» – дин кануннары белән яшәүчеләр. Мисыр, Төркия, Тунис кебек илләрдә хәләл ризык белән бәйле проблемалар туганы юк әле. Сәяхәттән үземә дә яңалык һәм рухи канәгатьлек алу өчен, күңелләрне сихерли торган Кызыл диңгездән тыш, Петра белән Иорданияне дә күреп кайтырга ниятләдем.


Иордания, дөресрәге, Иордан Хашимид Корольлеге Мисырның күршесендә генә урнашкан ил. Бу гаҗәеп илдә бик борынгы Петра шәһәре бар. Ул инде югалган шәһәрләрдән санала. Петра диңгез өсте тигезлегеннән 800–1340 метр югарыда, Вади-Араба үзәнлеге төбәгендә урнашкан. Вади-Араба үзәнлеге Африкада җир катламы чатнаган урында барлыкка килгән. Ул Иорданияне башка дәүләтләрдән аерып торучы табигый чик ролен үти.

Петра грекчадан «таш» дип тәрҗемә ителә. Галимнәр бүгенгәчә бу шәһәрнең яңадан-яңа серләрен ача торалар.



■ Өлкән кешеләр белән сәяхәткә чыкканда, иренмәгез: икеләтә иминият сатып алыгыз. Бу артык кыйммәт түгел, ә сезне күп кенә күңелсезлекләрдән коткарачак. Кайсы гына илгә барсагыз да, һәркайда өлкән кешегә хөрмәт белән карыйлар. Алар өчен иң яхшы шартларны тудырырга тырышалар.

■ Гидыбыз кыя ташыннан вакыт, җил һәм яңгыр дигән осталар уйган берничә сын күрсәтте. Аларның берсе «Алла Пугачева» дип атала. «Нигә Пугачева?» дигәнебезгә, гид: «Бары Пугачеваның гына авызы шулай зур һәм тавышы шулай гайрәтле», – дип җавап бирде.



Петра кеше күзеннән читтә, кыяларга сыенып утырганлыктан, ул серләр бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Әнә шулай итеп, шәһәр гасырлар шаукымына каршы тора алган.

Юлыбыз Кызыл диңгездәге тар гына Акаба култыгы аша уза. Таң беленеп килгәндә без инде паромга төялеп, култыкны кичә идек. Каршы ярда безне гидлар һәм озатып йөрүчеләр көтә. Төркемдәшләрем килешкилбәтләре белән башкалардан бик нык аерылып тора. Шуңамы, безне күрүгә үк кайдан килүебез, кемнәр булуыбыз турында сорауларга күмеп ташладылар. Ак яулык ябынган озынча ак йөзле, зәңгәр күзле апаларны гомерләрендә тәүге күрүләре иде, күрәмсең.

Шатланып, барыбыз бер тавыштан дигәндәй, сөрән салдык: «Без Татарстаннан!» Гидыбыз Хәсәннең ничек куанганын күрсәгез. Ул элек фәнни хезмәткәр булып эшләгән һәм Казанга фәнни симпозиумнарга килгәне булган икән. Пенсиягә чыккач, гид булып, Россиядән килгән туристларга хезмәт күрсәтә башлаган. Русча гаҗәеп яхшы сөйләшә ул, Советлар Союзында укыганлыгы күренеп тора. Гадәти булмаган төркемебезне Хәсән үзе җитәкләде.


Уңайлы автобусларга күчеп утырып, корольләр йөри торган юлдан Петрага кузгалабыз. Юл буе сораулар тынып тормый. Яңа эрага кадәрге алтынчы гасырда Петра тауларында набатейлар яшәгән (борынгы семитлар). Кызганыч, набатейларның тарихы әлегәчә өйрәнелмәгән, алар хакында бер генә чыганак та сакланмаган. Ул чорларның күп серләрен белмибез әле без. Борынгы кульязмалар Бөек Александр хакимлек иткән чорда (б. э. к. дүртенче гасырда) табылган булган. Алардагы мәгълүмат та бик аз. Тарихчылар бу халыкны Гарәб ярымутравыннан килгән сәяхәтчеләр булырга тиеш дип фаразлый. Алар белемле, талантлы, көчле халык булган. Уйлап табарга хирыс набатейлар кыяны кисеп, каналлар, дамбалар ясаган. Эссе җирдә сусыз яшәп булмаганлыгы мәгълүм. Набатейлар суны саклау һәм дөрес куллану өчен әкәмәт корылмалар уйлап тапкан. Ул чорда Петра аша Йәмәннән Урта диңгез портларына илтүче кәрван юлы узган. Кулларында кәтмәннән башка эш коралы булмаган бу халык ничек итеп кыяларны чокып шәһәр сала алган, билгесез.

Гидның хикәятен тыңлый-тыңлый, тауга менеп җиткәнебезне сизми дә калганбыз. Ярты юлда бик шәп туктау урыны бар икән. Хозурыбызда искиткеч матурлык! Халык «шалт та шолт» фотога төшерә башлады. Бераз сулу алгач, юлыбызны дәвам иттек. Ял итәргә туктагач, бер нәрсәгә игътибар иттем: таулар төрле төстә иде. Юл буйлап җирле халык тезелешкән, үзләре үстергән җиләк-җимеш саталар.

Ничә яшьтә булсагыз да, сәяхәткә чыгудан курыкмагыз. Ышаныгыз, бу бер дә куркыныч түгел.

Минем чал чәчле юлдашларым юл буе дога укып, тирә-юньнең матурлыгына сокланып бардылар. Петра безнең алда көтмәгәндә пәйда булды. Борылыштан узуга, кыя куенына сыенган бәләкәй генә авыл һәм биш йолдызлы кунакханә күренде. Алга таба без инде башка гид карамагына күчәсе идек. Аның исеме хәтердә калмаган, ә менә хатынының рус милләтеннән булуын яхшы хәтерлим. Яңа гидыбыз да Советлар Союзында укыган икән. Шунда рус кызына гашыйк булып, гаилә корган. Кайчандыр рус кызы булса да, ул хатын күптәннән руслыгын югалткан инде. Советлар Союзында югары белем алган иорданлылар безнең илне яхшы белә һәм безгә хөрмәт белән карый.

Алга таба юлыбыз кыялар арасындагы тар сукмак аша уза. Ташлы урыннары да бар. Ак юл ташы кояш нурында көзгә кебек ялтырый, күзләр авырта хәтта. (Көньякка сәяхәт итсәгез, үзегез белән баш киеме, кара



■ Гомумән, Петрада набатейлардан башлап, грек, мисыр, гарәп төзүчеләреннән калган һәр корылма – архитектура казанышы. Дэвид Робертс сурәтләрендә биналар әле яхшы сакланган булган – бүген алар инде төп бизәкләрен югалткан. Күп нәрсәне инде кабат торгызып булмаячак.

күзлек, су алырга онытмагыз. Киемегез уңайлы, иркен булсын. Гади тукымадан тегелгәне яхшы, муен һәм иңбашларын капласын. Югыйсә кояшта пешәчәксез.)

Җәяүле юлны чал юлдашларым егетләрчә узды, гәрчә арыганлыклары йөзләренә чыкса да. Ниндидер бер тылсымлы көч аларны алга әйди иде булса кирәк. Алар, гидның һәр сүзен «йотып», акрын гына атлады да атлады. Чуар төсләр белән балкыган гаҗәеп кыяларга әкияти бер могҗизага караган кебек карый иде алар.

Юлга үзем белән татар халкының милли уен коралы булган кубызны алган идем. Цивилизациядән ерак кайсы да булса берәр храмның бусагасына утырып, кубыз чиртү иде хыялым.

Петра – Иордания һәм Якын Көнчыгыштагы иң матур урын.

Кыялар арасындагы арбалы ат кына уза алырлык тар сукмактан атлыйбыз. Шәһәргә илтүче бу юл гарәпчә Сик дип атала. Аның озынлыгы 1200 метр. Сукмакка авып торган кыяларның биеклеге 40 метрдан алып, урыны-урыны белән 110 метрга кадәр җитә. Ташларның төсе карадан алып кызылгача, сары һәм хәтта зәңгәр ташлар да очрый. Кыя ташларының төрле төстәге бу катламнары миңа, никтер, хәлвәне хәтерләтте. Аеруча арасында шоколад һәм чикләвекләре булган төрек хәлвәсен. Ул да бит шулай катлам-катлам булып киселә.

Кинәт борылыш артында тирә-юнен текә кыялар әйләндереп алган киң генә мәйдан һәм шул мәйдан каршында кыяны кисеп кереп ясалган кызыл кирпеч төсендәге «Хәзинә» мәгарәсе пәйда булды. Ул матурлыкны сурәтләргә сүз юк. Мәгарә үзенең архитектур бизәлеше белән таң калырлык. Тылсым дими, ни дисең. Таш кыялар арасыннан барасың барасың да, кинәт кенә алдыңда «Мең дә бер кичә» әкиятендәге сыман серле шәһәр ачыла. «Хәзинә» мәгарәсе набатейларның архитектура мирасының гүзәл бер үрнәге. Ничә гасырлардан соң да бу халыкның таланты һаман сокландыра. Храмның алгы ягы һәр яктан җентекләп уйланылган. Кая саласын да белгән бит борынгылар. Шәһәрдән керү-чыгу юлына салганнар. Җилләрдән ышык урында, туфрак убылу куркынычы янамаган җирдә ул. Храмның атамасын бәдәвиләр биргән. Алар мәгарә эчендә алтын саклана дип уйлаганнар. Башка бер фаразы да бар. Беркөн иртән таң нурында храм алтын нурлар белән балкый башлаган. Бәдәвиләр аны алтыннан коелган дип уйлаган. Кич белән храм янына килсәләр, иртән җемелдәгән нурлар юкка чыккан. Бәдәвиләр алтынны кайсысыдыр алып китте дип фаразлаганнар.

Петрада каберлекләр бик күп. Алар арасында патшалар җирләнгәне дә бихисап. Иң зур каберлекнең биеклеге 46 метр, озынлыгы 49 метр. Алар барысы да кыяга чукып эшләнгән. Петрада Византия чиркәвен, антик театрны, Византия чорыннан ук сакланып калган искитмәле мозаикаларны күрерга була.

Җиденче гасырда ислам дине барлыкка килү набатейлар өчен дә. Петра өчен дә хәлиткеч чор булган. Мәккәгә бару юлыннан читтә урнашканлыктан, шәһәрнең әһәмияте кимегән. Шул сәбәпле, кешеләр акрынлап Петрадан китә башлаган. Сигезенче гасырда булган көчле җир тетрәү дә Петрага зур зыян салган. Уникенче гасырда шәһәр бөтенләй дә бушап калган.

Петраны кабаттан бөтен кешелеккә XIX гасырда танылган рәссам Дэвид Робертс ача. Шотланд рәссамы Якын Көнчыгыш, Мисыр, Фәләстин буйлап сәяхәт кыла. Җирле бәдәвиләрдән югалган шәһәргә юл күрсәтүләрен үтенә. Шунда ул берничә атна буена яшәп, Петраны сурәткә төшерә. Андагы сурәтләр бүгенге чынбарлыктан бик нык аерыла. Дэвидка юл күрсәтә килгән бәдәвиләр антик сыннарга уктан атып ярышканнар. Исламда кеше йөзләрен сурәтләү гаеп санала. Шуңа да алар тамчы да вөҗдан газабы кичерми, барлык тарихи ядкарьләрне кырыпмы кырган...

Без гидыбызның һәр сүзен игътибар белән тыңладык. Ул безгә яши торган йортларын искитмәле итеп бизи белгән, берничә мең еллар буена дөнья тоткан, эшләгән, шәһәрләр төзегән набатейлар атлы бөек халык хакында сөйләде. Алар борынгы мәдәниятнең нигезендә торучылар булган. Петра – башка кыйтгаларда яшәүчеләр әле җәнлек тиресе ябынып йөргән, тамакларын аучылык белән генә туйдырган чорда ук төзелгән шәһәр.

Без храм каршына утырыштык. Кесәмнән кубызымны чыгарып, иреннәремә китердем. Борынгы Петра урамнарына татар моңы агылды. Чал чәчле юлдашларым да яныма тезелешкән. Кояш зәүвәлдә, һавада челлә эссесе, әмма шушы мизгелдә болар берсе дә мөһим түгел иде инде. Һәркем үз уена чумган, тын гына татар көе агыла, якында гына йөргән туристлар барысы да безнең янга өелешкән. Кызык, нәкъ шул мизгелдә күңелемә бер уй килеп төште: «Әле ярый әнине алып килдем». Әни исә бу вакытта Коръән укый иде...



ГАТАУЛЛИНА Гөлүсә

Казан дәүләт педагогика университеты (2002)

Кияүдә. Өч бала әнисе.

Карьера:
Балигъ булмаган балалар белән эшләү бүлеге инспекторы.

Тормыш шигаре: «Тормышта ак һәм кара төсләр гел чиратлаша».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Өстемнән тау төште...



Икенче кызымның теле авыррак ачылды. Узган ел, балага биш яшь тулгач, логопедлар чаң сукты: «Белгечләргә барырга соңга калгансыз! Кызыгызны махсус мәктәпкә бирергә туры килер». Ә аңарчы гел «иртә әле, көйләнер» дип килделәр... И-и, борчылганнарым!.. Вакытны да, акчаны да жәлләмәдек – Аделина белән ел буе логопед шөгыльләнде, әтисе белән без дә читтә калмадык. Кызым хәзер бөтен хәрефне белә, укый, ачык итеп сөйләшә. Яңа гына тәрбиячеләре: «Быел мәктәпкә бирмисезме? Ул инде әзер», – диделәр. Бу хәбәр сөендерсә дә, баш тарттым, алты яшьтән парта артына утырырга иртәрәк...

Хөкүмәт балалар турында онытмый


Тәрәзә каршына гына балалар өчен мәйданчык ясап куйдылар: волейбол да, футбол да, баскетбол да уйнарга була анда, бәләкәйләр өчен дә почмак бар. Бала-чага көне буе шунда мәш килә хәзер. Кинәнәләр! Авыр гаиләләрдә үскән, исерек ата-анадан башканы күрмәгән балалар өчен бигрәк сөенәм. Яшьтәшләре кебек, акча түләп ниндидер түгәрәкләргә йөрү мөмкинлекләре юк аларның. Ә бу мәйданчыкта бөтен балалар бертигез.
Спорт – баланы ялгыш юлга кереп китүдән саклауның иң дөрес юлы ул.


Ә безнең җан тыныч...


Әлфия исемле бер дустым Англиядә, Лондон шәһәрендә яши. Шунда инглиз кешесенә кияүгә чыкты, бер кыз үстерәләр. Миңа һәм үзенең дүрт балалы апасына кызыгуы турында шалтыраткан саен болай дип кабатлый ул: «Сез – бәхетле, икегездә дә бер кочак бала!» Аннан, уфтанып: «Без шушы бер бөртекне саклап үстереп бетерә алсак ярый инде», – ди. Минем унбер яшьлек кызымның мәктәпкә үзе генә баруына, кайтуына Әлфиянең ире шакката. Мондый хәлне алар күз алдына да китерә алмый икән. «Бездә бала урлау, аны сату очраклары адым саен», – диләр. Бөтен нәрсә чагыштырып караганда күренә.

сөендерде 

көендерде 

сөендерде 

көендерде 

сөендерде 

көендерде 

Авырмас сөяк булмый да...

Салкын тиде дип кенә кергән идек сырхауханәгә. Атна буе балага диагноз куя алмадылар. Илданым күз алдымда сула барды... Реанимациядә үткәргән ике көн һәм бер төн миңа гомер озынлыгы булып тоелды... Ашау-эчү, йокы онытылды. Белгән догаларымны искә төшердем, бертуктаусыз Ходайга ялвардым. Мондый хәлләргә калуны берәүгә дә теләмим... Табибларга мең рәхмәт: коткардылар. Байлыкның – иң кечкенә, ә саулыкның дөньяда иң зур бәхет икәнен шундый чакларда аңлыйсың...

Бәла – аяк астында

Йөрәк өзгеч хәл: Түбән Новгород янында Татарстан балалары утырган автобус һәлакәткә очрады. Каратэ буенча ярышка барулары булган. Үлүчеләр бар... Авылдашыбыз Фоат абыйның оныгын, 12 яшьлек Эльвинаны Юртышка алып кайтып җирләделәр. Күршеңә килгән хәсрәт синеке дә инде ул... Үзеңне шул әтиәни урынына куеп карасаң... Безнең балалар да гел йөреп тора: әле олимпиадага, әле музейга баралар. Күрмәгәнгә мондый хәсрәтне күрсәтмәсен, күргәннәргә сабырлык бирсен инде...

Ачның хәлен тук белми...

Очы-кырые күренмәгән гражданнар сугышыннан соң, Сомали республикасында хәзер хөкүмәт тә юк, мәктәпләр дә, элемтә дә, эчәргә су да, дарулар да, эш тә... Андагы бүгенге ачлык кешелек тарихындагы иң зур фаҗига дип санала. Көн саен меңәрләгән кеше үлә. Шуларның дүрттән бере – балалар, ди. Телевизор карыйм: ире сугышта үлгән, 5 баласының өчесен инде җирләгән, менәменә җан тәслим кылачак дүртенче сабыен кочагына кыскан хатынны күрсәтәләр. И-и, күзләрендәге хәсрәт, сагыш, моң... Баласына ярдәм итә алмаган әни кешенең хәл, халәтен без аңлый алабызмы икән?!



ЧӘЧӘКЛЕ БЕРЕТ




«Сөембикә» журналын даими укып баручыларыбыз Ания ГАТАУЛЛИНАның кул эшләре белән таныш инде. Бу юлы Ания безне җәйге берет бәйләргә өйрәтә. Бәләкәй кызларга да, олыларга да бик килешәчәк ул. Береткага иш итеп, җәйге букча да бәйләргә була.



Кирәк:

- нечкә бәйләм җебе. 50 г/240 м (100% мерсирланган киҗе-мамык);
- 2 нче номерлы ыргак.

Берет аерым-аерым чәчәкләрдән үрелгән. Аларны төрле төсле итеп тә, бер генә төстән дә бәйләргә була.



Эш барышы:

■ 1 нче рәт. 10 күздән чылбыр үреп, боҗрага тоташтырабыз.







■ 2 нче рәт. 3 күзле күтәрү баганасы бәйлибез (петли подъема). Боҗра тирәли чалулы багана белән (столбик с накидом) 19 багана бәйләп чыгабыз.

■ 3 нче рәт. 6 күздән торган чылбыр үреп, икенче рәттәге ике күзне калдырып, өченче күз аша бәйләп алабыз. Шул рәвешле дәвам итеп, алты чәчәк таҗы үрәбез.

■ 4 нче рәт. 3 күзле күтәрү баганасы бәйлибез. Аннан соң ике ярымбагана (полустолбик) һәм ике чалулы биш багана бәйлибез. Тагын ике ярымбагана һәм 3 күзле чылбыр бәйләп, беренче таҗны тәмамлыйбыз.

■ Чәчәкнең алты таҗы да шулай бәйләнә. Бер берет өчен 31 чәчәк бәйләргә кирәк.



Беретны җыю

■ Чәчәкләрне түбә өлешеннән тоташтыра башлыйбыз. Эшкә керешкәнче, аларны яхшылап үтүклибез.


■ Уртада – 1 чәчәк, 2 нче рәттә аның тирәли – 5 чәчәк.

3 нче һәм 4 нче рәтләрдә – уникешәр чәчәк. Беретны 5 рәтле итеп тә бәйләргә була.

■ Чәчәкләрнең бер-берсенә орынып торган урыннарын чәчәк төсенә туры килә торган җеп белән, күренмәслек итеп тегеп куябыз.

■ Чәчәкләрне тоташтырып бетергәч, аскы итәктәге һәр таҗ арасына 5 күзле чылбыр үреп, аркалар бәйләп чыгабыз (олылар өчен чылбырны 6 күздән үрәләр).

■ Беретның маңгай өлешен ярымбагана белән 6 рәт бәйләп, бәйләмне төгәллибез.



бер чалулы багана | ике чалулы багана | ярымбагана | күзәнәк

РЕКЛАМА



Чтим традиции, улучшая качество!

Оренбургские Пуховницы

Фирменные магазины

- г. Оренбург, пр. Победы 5 фирменный музей-магазин
- ул. Туркестанская 45, ТЦ Мелодия, 2 этаж
- г. Орск, пр. Ленина 47, фирменный музей-магазин
- г. Бузулук, ул. Чапаева 40,
- Интернет магазин: shal56.ru

РЕЖИМ РАБОТЫ С 9:00-19:00 БЕЗ ВЫХОДНЫХ

тел. 8(3532) 60-41-48
8-922-627-42-08, 8-922-829-99-14

Филүс Башкортстанның Бүздәк районы Килем авылында туып-үскән егет. Аш-су әзерләү серләренә студент елларында өйрәнгән. Моңарчы авыз итмәгән ят ризыклар пешерергә, башка халыкларның кухняларына күз салырга ярата ул. Филүснең бүген безгә тәкъдим итә торган ризыгы да, Франция, Испания якларында яратып әзерләнә икән. Сез дә пешереп, авыз итеп карагыз әле, сезгә дә ошар ул.



БАСКЧА ПЕШЕРЕЛГӘН ТАВЫК







Кирәк:

- 4 тавык боты;
- 1 зур болгар борычы;
- 2-3 зур помидор;
- 1 баш суган;
- 1 кишер;
- тоз-борыч.

Эш барышы:

■ тавыкның бот өлешен урталайга бүлеп (артык зур булмаса, бүлмәсәң дә ярый), үсемлек мае салынган табада һәр ягын да кыздырып алабыз.

■ Икенче бер табада ярым бөҗралап туралган суганны алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Шуның янына саламлап туралган кишер салабыз. Кишер йомшаргач, озынча итеп туралган болгар борычын өстибез.



■ Кызган яшелчәләр янына кабыгы салдырылган помидорларны турап салабыз, тоз-борыч сибәбез. Капкач белән каплап, сүрән утта 10 минут томалап тотабыз.



■ Яшелчәләрне тавык ботлары янына кушып, янә 10-15 минут чамасы пешерәбез.
Тавык янына өстенә сыр сибелгән бәрәңге әзерлик.





Кирәк:

7-8 бәрәңге (яшь бәрәңге булса, бигрәк тә яхшы);
100–150 г кибет каймагы;
1 тырнак сарымсак;
100 г каты сыр;
тоз-борыч.

Эш барышы:

■ Бәрәңгене юып, кабыгы белән яртылаш әзер булганчы пешерәбез.
■ Сарымсакны вак угычтан уып, каймакка кушабыз. Төменчә тоз белән борыч сибәбез, яхшылап туглыйбыз.
■ Бәрәңгене бераз суытып, кабыгын әрчибез (яшь бәрәңгенекен әрчемәсәң дә була) һәм урталай бүләбез.
■ Төбенә аз гына май тамызылган табага бәрәңгеләрне кискән ягы белән өскә каратып тезеп, өстеннән сарымсаклы каймакны ягабыз.
■ Аның өстенә уылган сыр сибеп, 10-15 минутка 200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.
■ Сыр кызаргач, сыебыз әзер.



Филүс КАҺИРОВ уздырган мастер-классның видеоязмасын сайтыбызда карый аласыз. www.syuyumbike.ru



АНАНАСЛЫ МЕДАЛЬОННАР

Мин гаиләм белән Арчада яшим. Аш-су әзерләргә бик яратам. Берәр яңа рецепт күрсәм, тизрәк пешереп карыйсым килә. Сезгә тәкъдим итәсе рецептны да күптән түгел генә өйрәндем. Безгә ошады ул. Сез дә пешереп карагыз әле.

Кирәк:

• 500 г тавык түше;
• 450 г консервланган ананас;
• 200 г каты сыр;
• 150 г майонез;
• тоз-борыч, тәмләткечләр.

Эш барышы:

■ Тавык түшен берничә кисәккә бүлеп, һәр кисәкне яхшылап төпәлибез.
■ Тоз-борыч һәм тәмләткечләр сибәбез.
■ Майлы табага тезеп, өстеннән майонез ягабыз.
■ Һәр кисәк өстенә ананас телемнәре куеп чыгабыз, сыр уып сибәбез һәм 200 градус кызулыктагы мичкә тыгып, 30-35 минут пешерәбез.

Ләйсән ГӘРӘЕВА

Искәртәбез: бәйгегә тәкъдим ителгән ризыкларда «Пестречинка» ҖЧҖ продукциясе файдаланылырга тиеш.



Кан тамырларындагы варикоз күпләрне борчый. Варикоз нилектән барлыкка килә, ул җитди авырумы, нәселдән дә киләме, аны ничек итеп дәвалап була — болар хакында аерым сөйләшербез. Әлегә укучыларыбызны борчыган күпсанлы сорауларның кайберләрен ачыклап үтик.

Әйе, варикозның нәселдән килү үзлеге бар. Әгәр тиешле саклану чаралары күрелсә, ягъни озак-озак утырмасаң, басып тормасаң, спортның хәрәкәтле төрләре белән шөгыльләнсәң, кичләрен салкынча душ кереп чыгарга иренмәсәң, сездә варикоз авыруы килеп чыкмаска да мөмкин. Ә кан тамырларында инде проблемалары булган кешеләргә эссе җәй көннәрендә нишләргә?

ВАРИКОЗ һӘМ ҖӘЙ

Кызынырга ярыймы?

Варикоз булганда, ультра-шәмәхә нурлардан бигрәк, җылыту зарарлы. Югары температуралар кан тамырларында «йолдызчыклар» ясалуны тизләтә. Эссе кояш нурлары варикозлы кан тамырларында тромблар китереп чыгарырга да сәләтле. Ләкин кояшта кызынудан гел дә баш тартырга да кирәкмәс. Кояш сүрелгәч, көн – сезнеке. Кызынганда сузылып ятып кызыну дөресрәк булыр. Шулай иткәндә, аякларга көч килмәс; кояшта кызынганнан соң, салкынча душ керап чыгыгыз. Аякларны күтәртеп бераз ятып торыгыз. Җәйге айларга әзерлекне веналарның эшчәнлеген яхшырта торган дарулар белән дәваланудан башлагыз.

Йөзәргә ярыймы?

Спорт – яхшы нәрсә. Варикозлы кешеләр велосипедны сайласын. Велосипедта йөргәндә кеше актив сулый, балтыр мускуллары актив хәрәкәттә була. Болар бөтенесе кан тамырларының насос сыман эшчәнлеген көйли, вена канының әйләнешен яхшырта. Бердәнбер кимчелек – аякларның, басып торгандагы кебек, салынып торуы. Шуңа күрә варикозлы кешеләр өчен иң әйбәте – йөзү. Йөзгән вакытта веналарда кан йөреше өчен кирәкле бөтен хәрәкәтләр дә үтәлә. Варикозлы кешеләргә һич тә авыр атлетика белән шөгыльләнергә ярамый. Авыр әйберләр күтәрүдән дә тыелырга кирәк.

Халык ысуллары

- сарымсаклы май белән компресс. Бер өлеш сарымсак ике өлеш ак май белән аралаштырыла да төнгә компресс ябыла;
- әремле катык белән компресс. Төелгән әрем салынган катыктан компрессны аякка ябып, төн буена тотарга кирәк. Биш көн шулай эшләгәннән соң, берничә көн туктап торасы да тагын кабатлыйсы;
- кычыткан төнәтмәсе. Ике аш кашыгы кычытканны, өстенә кайнар су коеп төнәтергә кирәк. Шуны көнгә өч мәртәбә чирек стаканлап ай буена эчәргә кирәк. Ике атна ял иткәч, процедураны кабатлыйсы;
- мөшкәт чикләвегеннән эчемлек. Яшь чикләвек өстенә кайнар су салып төнәтеп, шуңа бер аш кашыгы бал кушып, иртәнге аш алдыннан бер сәгать кала берәр стакан эчеп куегыз. Ашагач ике сәгатьтән соң тагын бер стакан эчәсе;
- яшел помидор сихәте. Авыру веналарга төнгә яшел помидор телемнәрен ябып куегыз.
- аякларда варикоз вакытында сирень төнәтмәсе да кулланыла. Моның өчен төнгә варикозлы урыннарга, аякны умыйча гына, компресс куярга кирәк.
- сирень чәчәгеннән әзерләнгән төнәтмә ревматизмнан, артриттан, радикулиттан, буыннарга тоз утырудан булыша. Моның өчен пыяла банкага сирень чәчәген дыңгычламыйча гына тутыралар. Өстенә аракы салып, өч атнага караңгы урынга куялар. Сөзеп куйган сыеклыкны көнгә өч мәртәбә 30 ар тамчы эчәләр. Дәвалану вакыты – өч ай.
Шул ук төнәтмә белән сөртенергә һәм компресслар куярга мөмкин.
Сирень төнәтмәсе үкчәдәге шпораларны да бетерә.

Шунысы кызык: варикозга халык ысуллары белән дәвалау бик килешә.


КУЧКАР. Үзегезне гаиләгә, йорт мәшәкатьләренә багышлау өчен яхшы вакыт. Күптән күрешмәгән туганнарыгыз белән очрашырсыз. Әллә кайчаннан бирле уйлап йөреп тә, тормышка ашыра алмаган эшләрегезне башкарырсыз.


ҮГЕЗБОЗАУ. Юкка-барга күңелегезне төшерүдән арынырга вакыт. Көтмәгәндә эшлекле тәкъдим булыр, аннан баш тартмагыз. Бу айда уңыш сезнең яклы. Нинди генә максат куйсагыз да, ирешерсез.


ИГЕЗӘКЛӘР. Тормышыгызда зур үзгәрешләр көтелми. Бар да үз җаена барачак. Яңа үрләр яуларга ниятләсәгез, бу айда сабыр итегез. Элеккедән кала килгән эшләрегездән арынырга җай чыгар. Ял итү, сәяхәтләр өчен яхшы вакыт.


КЫСЛА. Үзегез өчен иң беренче урында нәрсә торуын дөрес ачыкларга кирәк булыр. Эш урынын алыштыру, яңа тормыш башлау өчен уңышсыз вакыт. Сөйләшкәндә сак булыгыз, авыздан ычкынган һәрбер ялгыш сүз үзегезгә үк зыян салмагае.


АРЫСЛАН. Бер яктан уңышлы булса, икенче яктан мәшәкатьле ай. Көтелмәгән вакыйгалар килеп чыгар. Акчасын һәм көчен моңа кадәр саклабрак килгәннәргә хафаланырга урын юк. Үз фикерегезне үзегездә тотсагыз, бик тә отарсыз.


СӨМБЕЛӘ. Үзгәрешләр ае. Бу айда киләчәктәге эшләрегезгә нигез салына, «ни чәчсәң, шуны урырсың» дигән мәкаль нәкъ сезгә карата әйтелгән. Ниятләрегезне башкаларга белгертми торыгыз. Яңа йорт, фатир сатып алу өчен уңай вакыт.


БИЗМӘН. Шактый киеренке ай, иркенәергә җай чыкмас. Сайлау алдында калырсыз. Низаглардан сакланыгыз. Җитәкчелек алдында фикерегезне белдерүдән тыелыгыз, сезне дөрес аңламаулары ихтимал. Ай ахырында уңыш елмаячак.


ЧАЯН. Тышкы кыяфәтегезгә игътибарны бик нык арттырыгыз. Киләчәктәге уңыш килеш-килбәтегезгә бәйле. Айның беренче яртысы бик уңышлы. Ай урталарына таба низаглардан сакланыгыз. Кредит, ипотека алу өчен яхшы вакыт түгел.


УКЧЫ. Ниһаять, сезгә дә ял итү мөмкинлеге туар. Күптән уйлап йөргәннәрне тормышка ашыру ихтималы бар. Хәтта уйламаган җирдән ярдәм дә итәрләр. Ай башында эшлекле сәфәр чыга икән, ризалашыгыз. Ул сезгә файдалы булачак.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Эшегездә четерекле мәсьәләләр килеп чыгуы бар. Кечкенә генә бәхәснең дә зурга китүе мөмкин. Киңәш шул – тиз арада ялга китегез. Әҗәткә зур акчалар алмый торыгыз. Сәламәтлекне ныгыту өчен кулай вакыт.


СУКОЯР. Эшләргә, эшләргә, эшләргә! Айның соңгы атнасында гына ял итә алырсыз. Эш алыштыру, һөнәр үзгәртү өчен җайсыз вакыт. Зур әйберләр сатып алу өчен башка айны сайлагыз. Ә менә буй-сынны зифаландыру өчен моннан да яхшырак вакыт булмаячак.


БАЛЫК. Киләчәктәге уңышларга нигез булырдай вакыйгалар көтелә. Кечкенә генә бәхәстән дә ерак торыгыз. Көтелмәгән җирдән акча керү ихтималы бик зур. Документларга кул куйганда игътибарлы булыгыз.

ИЮНЬдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Мәрзия ФӘЙЗУЛЛИНА (11.06.1930) – **балалар язучысы, шагыйрә. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.**
Арча районы Шушмабаш авылында туа. 16 яшендә үк Казанга килеп, төрле оешмаларда эшли. Иҗаты узган гасырның илленче елларында күренә башлый. 1955 елда балалар өчен «Салават күпере» җыентыгы басылып чыга. Урта мәктәпне читтән торып тәмамлап, 1958–1964 елларда Мәскәүдәге Әдәбият институтында укый. 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Рус телендә «Цветочные часы», «Стихи», «Пропала кошка» исемле өч китабы дөнья күрә. Олылар өчен язылган «Алмагачлар күләгәсендә» поэмасы, «Сугыш юлларының тузаны», «Чиккән яулык» җыентыклары, көндәлек матбугатта басылган публицистик мәкаләләре дә бар. 2004 елда Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләгенә лаек була.

Россия



Наталья Селезнева (19.06.1945) – **РСФСРның атказанган, Россиянең халык артисты.**
Мәскәүдә туа. Әтисе Игорь Николаевич – танылган фотограф, әнисе Елена Семеновна – рәссам. 1966 елда Б. В. Щукин исемендәге театр училищесын тәмамлый. Халык мәхәббәтен Леонид Гайдайның «Операция «Ы» фильмында уйнаганнан соң казана. Лида исемле студент кызны хәтерлисезме? Гайдайның комедияләрендә аннан соң да уйный әле ул. «13 стульев» телевизион тапшыруыннан соң актрисаның популярлыгы тагын да арта.
«Дуслык» ордены иясе.

Чит илләр



Элизабет Херли (10.06.1965) – **актриса.**
Англиянең Басингсток шәһәрендә туа. Әтисе хәрби кеше булганлыктан, кечкенәдән каты тәртипкә өйрәнеп үсә. Әнисе кызының биюче булуын тели һәм, бернигә дә карамый, аны «London Studio Centre» көллиятенә укырга бирә. Элизабетның һич кенә дә биюче буласы килми. Көллияттән куып чыгарсыннар өчен, ул бик зур тырышлык куя. Әмма юкка... Актерлык карьерасын 1987 елда «Ария» фильмы белән башлап җибәрә. 1992 елда аны Голливудка – «Пассажир- 57» фильмында уйнарга чакыралар. Тик бу роль актрисага зур уңыш китерми. Танылу аңа 2000 елда төшкән «Теләкләр тозагында» («Ослепленная желаниями») фильмыннан соң гына килә.







ҖӘЙНЕҢ ҖЕТЕ ТӨСЛӘРЕ

Рәссам Александр Шадрин ике меңнән артык сәнгать әсәре иҗат иткән оста. Яз – аның иң сөйгән фасылы. Иҗатта гына түгел, гаиләсендә дә бәхет тапкан бу кешенең өч баласы бар. Алар барысы да бик сәләтлеләр. Рәссамның иң яраткан санәме (модель) исә төпчек кызы – 11 яшьлек Аврелия. «Мин аны шулкадәр күп һәм тиз ясыйм. Бер көн эчендә портрет әзер була!» – ди үзе рәссам Александр Шадрин.



«Минем әбиемдә башкорт каны да бар иде, ә әтием һәм аның ир туганнары, татар булмасалар да, саф татарча сөйләштеләр», – ди рәссам үз нәселе хакында. Нәсел җәһәтеннән шулай. Иҗат җәһәтеннән сөйләсәк, Александр яшьлегендә авангардизм белән мавыгып алган. Бу – ул заман өчен гадәти күренеш. Александр Шадрин иҗатка сәнгать мәктәпләре аша килмәгән. Ижау дәүләт университетының сынлы сәнгать факультеты аның өчен бары тик «А» пунктыннан «Б» пунктына җитү белән бер. Ул иҗади эзләнүләрен XIX гасыр классикларының әсәрләреннән күчермәләр язып караудан башлый.

Иҗатының башлангыч чорында графика жанры белән җәмгыятьтә киң танылу ала алган рәссам Александр Шадрин хәзер тулысынча диярлек фәкать майлы буяулар белән генә яза. Үз язу рәвеше өчен үз атамасын да уйлап тапты – перцептуаль (образлы – хиссиятле) юнәлеш. Аның иҗат тематикасы: пейзажлар, фауна дөньясы, портретлар. Соңгысында күбесенчә кырыс һәм горур ирләр, этник киемле Идел буе хатын-кызлары, көләч йөзле балалар. Хәтта картиналарның атамаларында да күпме нур бар: «Эреп югалучы офыклар», «Кояшка гашыйк җаннар», «Хисләрдән каушау», «Иртәнге яңгыр белән юынганнар», «Ай җиле», «Кояшны тоткан ятьмәләр», «Тыйнак гүзәлләр», «Кичке зәбәрҗәтләр», «Гәрәбә сулар», «Кояштан яралганнар»...

Башкаларга яктылык илтүче рәссам инде 20 дән артык шәхси күргәзмәсен ачып, Казан, Ижау, Мәскәү, Нью-Йорк тамашачыларын шатландырды. Александр үз иҗади дәртенә һәм сәнгатьне үзенчә аңлавына тәңгәл килгән юнәлештә генә калмыйча, 2010 елны «Маша әбисе янында яшәргә кала» халыкара күчмә сәнгать проектын оештырды! Бу проектның максаты: бар кыенлыкларны җиңеп, үз иҗади үзенчәлекләрен саклап кала алган яшьтәш рәссамнарны берләштерү. Көнбатыш калыпларына исләре китмәүче, Россия халыкларының күптөрле мәдәниятен, үз тамырларын яратучы, рухи ныклыкка ия, үз мәдәни-милли мирасларының кыйммәтен аңлатучы рәссамнарны җыеп, ул инде Пермь, Красноярск, Иркутск, Ростов-на-Дону, Төмән, Түбән Варта, Екатеринбург шәһәрләрендә шушы проектның күргәзмәләрен зур уңыш белән уздырды. Рәссам Шадрин 2012 елның Россия сынлы сәнгать академиясенең көмеш медаленә һәм академик сынлы сәнгатьтәге пластика дәрәҗәләре өчен Н. Фешин исемендәге премиясенә лаек булды. Ул халыкара «Арт-салон»нарда, «Мәскәү–Санкт-Петербург», «Россия», «Классика һәм бүгенге заман», «Россия сынлы сәнгать академиясенә – 250 ел» күргәзмәләрендә катнашты, ил күләмендәге һәм халыкара сынлы сәнгать конкурсларында җиңеп чыкты.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА




АЛЕКСАНДР ШАДРИН

ҮЗЕМӘ ҮЗЕМ ДИЗАЙНЕР

«МОДА ҮЗГӘРӘ, СТИЛЬ КАЛА». Габриэль Шанельнең инде канатлы сүзгә әйләнгән бу гыйбарәсен без үзебезгә шигарь итеп алырга тиеш. Дөреслектә, мода артыннан куа-куа, үз йөзеңне югалту куркынычы да бар – анысын да онытырга ярамый.





«Сөембикә» журналы 2009 елдан бирле дизайнерларның халыкара «Internacional fashion» милли кием конкурсын оештыручыларның берсе булып тора.

Шушы вакыт эчендә без бер нәрсәгә инандык: талантлар бик күп. Нәкъ менә шуның өчен дә үз абунәчеләребез арасында конкурс игълан итәргә булдык.

Беркайчан да модадан чыкмый торган киемнәргә игътибар юнәлтү, андый киемсалымны үзебезгә уйлап табу сәгате сукты.

Сез алтын куллы һәм креативмы? Шулай булса, бу бәйге нәкъ менә сезнең өчен. Сездән фәкать аз гына кыюлык һәм җитезлек сорала. Ә инде сезнең иҗат эшегез конкурста катнашсын һәм лаеклы бәяләнсен өчен «Сөембикә» журналы кулыннан килгәннең барысын да эшләр.

Конкурска үзегез теккән әзер киемнең фотосы һәм эш барышын тасвирлаган фотолар кабул ителә. Алар моңарчы бер җирдә дә басылмаган булырга тиеш.



Эшләрегезне түбәндәге адреска җибәрегез:

420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
e-mail: ssuum@yandex.ru
(дизайнерлар конкурсына дип тамгалагыз)

Конкурста катнашуыгыз турында гариза җибәргәндә, хатыгызга «Сөембикә» журналының икенче яртыеллыгына язылуыгызны раслаган квитанцияне дә салырга онытмагыз.

Конкурсның шартлары белән «Сөембикә» журналының сайтында таныша аласыз:
www.syuyumbike.ru



Конкурсның иганәчеләре:

«Алмаз-Холдинг» ҖЧҖ | «Алмаз» ювелир заводы